# Казан утлары

август
№ 8
1966

1

# КАЗАН УТЛАРЫ

АЙЛЫК ӘДӘБИ ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ

ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫ СОЮЗЫ ОРГАНЫ

*КЫРЫК БИШЕНЧЕ ЕЛ ЧЫГА*

## Бу санда:

ПОВЕСТЬ, ХИКӘЯЛӘР, ШИГЫРЬЛӘР

**Хәсән Сарьян. Әткәм һөнәре.** Повесть . . . . 3
**Гамил Афзал.** Шигырьләр . . . . . . . . . . 54
**Газиз Мөхәммәтшин. Хөсәен абзый.** Хикәя . 57
**Самат Шакир.** Шигырьләр . . . . . . . . . . 67
**Радик Фәизов. Әнием ең куллары.** Хикәя . . . 68
**Галимҗан Насыйров.** Шигырьләр . . . . . . 70
**Гомәр Хәйям.** Шигырьләр . . . . . . . . . . 72
**Хәлил Аппаз.** Шигырьләр . . . . . . . . . . 76

ЯШЬЛӘР ИҖАТЫ

**Фәнис Яруллин.** Шигырьләр . . . . . . . . . 78
**Рөстәм Мингалимов.** Шигырьләр . . . . . . . 80
**Гәрәй Рәхим.** Шигырьләр . . . . . . . . . . 81
**Дифгать Сирай.** Шигырьләр . . . . . . . . . 82

ЗАМАНДАШЛАРЫБЫЗ

**Фаик Мостафин. Бәхетле кеше.** Очерк . . . . 83
**Җәмил Мостафин. Кечкенә булса да...** Очерк . 88

ПУБЛИЦИСТИКА

**Фаяз Дунай. Экранда күрсәк икән** . . . . . . 96

БӨЕК ОКТЯБРЬНЫҢ 50 ЕЛЛЫГЫНА

**Локман Антов. Артистның тормыш юлы** . . . . 102

ӘДӘБИ МИРАС

**Г. Биги (Килачәккә өмет белән)** . . . . . . . 116

8

АВГУСТ

1966

КПССның
ТАТАРСТАН ӨЛКӘ
КОМИТЕТЫНЫҢ
ГАЗЕТА ҺӘМ
ЖУРНАЛЛАР
НӘШРИЯТЫ
КАЗАН

ФИКЕР АЛЫШУ, БӘХӘСЛӘР

**Р. Нәфигов.** Г. Тукай биографиясен өйрәнүнең кайбер мәсьәләләре . . . . . . . . . . . . . . 119

СӘНГАТЬ

**Ф. Вәлиев.** Халкыбызның чигү сәнгате . . . . . . 129

ТӨРЛЕСЕННӘН

**Р. Мозаффаров, Б. Гафаров.** Халык тарихы — фольклорда . . . . . . . . . . . . . . . . 134
**Ә. Булатов.** Ибраһим хан ярлыгын укуга карата кайбер фикерләр . . . . . . . . . . . . . . 135
Истәлекләр . . . . . . . . . . . . . . . . . 136

«АЗАТ ХАТЫН» ЖУРНАЛЫНА 40 ЕЛ

**А. Хәсәнова.** Безгә — кырык яшь . . . . . . . 139

КИТАП КҮЗӘТҮ

**Г. Киекбаев.** Гарәпчә-татарча-русча алынмалар сүзлеге . . . . . . . . . . . . . . . . . . 142

ӘДӘБИЯТ ТАРИХЫНА МАТЕРИАЛЛАР

**А. Шмаков.** Көньяк Уралның әдәби үткәне . . . . 144

САТИРА ҺӘМ ЮМОР

**Касыйм Хәмзин.** Проблемалы дәрес. Хикәя . . 150

УКУЧЫЛАР ИҖАТЫ

**Р. Димская.** Шигырь . . . . . . . . . . . . . 153
Укучылар сүзе . . . . . . . . . . . . . . . . 155
Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары . . . . . . . . . 157

*Редакциягә килгән кульъязмалар кире кайтарылмый.*

Редакциянең адресы: *Казань, ул. Баумана, 19. Дом печати, 2 этаж.*
Телефоннар: җаваплы редактор — 2-68-21, җаваплы секретарь — 2-68-21, бүлекләр — 2-39-52.
Хатлар өчен: *Казань, почтамт, почтовый ящик 63. Редакция «Казан утлары».*

ХӘСӘН САРЬЯН



# ӘТКӘМ ҺӨНӘРЕ

С. КУЛЬБАКА рәсемнәре.

*Повесть*

> Әткәй! Мин сине чак кына хәтерлим. Төштә генә күргән сыман. Ләкин мине сиңа охшаган диләр. Хәтта балта һөнәрең дә миңа күчкән.
> Әткәй, Хәсән улы Салихҗан! Синең рухыңа багышлап яздым бу әсәремне.
>
> *Автор.*

## Беренче бүлек

Гаяз уянгач, тегеләрнең дә сыңар күзлесе торып утырды. Күзле ягы белән Гаязга борылып:

— Сәгать ничә? — диде.

— Сигез тула.

— Буфет ачык микән, белмисеңме?

— Буфет унда гына ачыла.

— Чатный гына! — диде сыңар күзлесе һәм аптырау хәлдә идәнгә төште. Башын тавык кебек кыегайта биреп, буш шешәләрне күтәреп-күтәреп карый башлады. Шешә тавышына икенчесе — юаны да уянды.

— Нәрсә эзлисең инде аннан? — диде ул. — Кичә тамчысын да калдырмадың бит.

Ләкин тегесе каравында-тикшерүендә булды.

— Вот дурак, ышанмый бит! — диде юаны. — Бар, буфетчица янына төшеп мен.

— Буфет ачылмаган әле.

— Буфетчица янына дип әйтәм.
— Унда гына ачыла ди бит.
— Башың эшләмимени соң синең?
— Чатный гына!
— Әнә кранга тот.

Сыңар күзлесе умывальник янына килде, сибелеп аккан саргылт суны учына җыеп, битен чылатып алды. Икенче күзенең, авызы шикелле, ачылып торган буш урынын җентекләп сөрткәч, каешланып беткән кара чүпрәк бәйләп куйды.

— Кая мин дә төшим әле, — диде юаны. — Җә буфетчицаны йокысыннан уятып, йөрәген алырсың. Кичә дә сине күргәч шытыр җибәрде.

Менә анысы да торды. Бу бер арба гәүдә кузгалып киткәч, төн буе томаланып яткан һава да хәрәкәткә килде.

— Тәрәзәне ачарга иде, — диде Гаяз.

— Без чыккач ачып, җилләтеп ал әле, — диде юаны. Аның да үз хәле хәл иде.

Алар аңгыраешып чыгып киттеләр. Гаяз торып, тәрәзәне ачып җибәрде. Тәрәзә шартлап ачылуга, стеналарына хәтле авыр ис сеңгән каютага Агыйдел һавасы бәреп керде. Инде ничә көн бер бөртек тә нур күрми күнеккән күзләр чагылып китте — бүген көн кояшлы иде.

Нәкъ тәрәзә каршысында, палуба читендә, шлюпка тора иде; каплап куйган брезенты лычма булып эченә асылынып төшкән, өстенә яңгыр суы җыелган. Моны күргәч, Гаязның исенә җан өшетеп узган кичәге көн килеп төште. Кичә тегеләр озын көн буена эчтеләр. Уфадан чыккач тотынганнар иде — төнсез туктамадылар. Һавасы да эчеп утыра торган гына — палубага чыгарлык та түгел иде. Салкын. Яңгыр. Яңгыры исә атна буена туктый алмый интегә иде инде. Җитмәсә, көндез рашкы явып үтте — борчак-борчак бозларының шакылдап палубага бәрелүе хәтта эчтән ишетелеп торды.

Алар бер каютада өчәү кайталар. Гаяз кичә үзен аерым каютага күчерүләрен сорап карады. Бу вакытта пароходта кеше аз, беренче, икенче класслар бөтенләй диярлек буш иде. Ләкин Гаязны күчермәделәр: проводницаның, бер урынына ике каюта җыештырасы килми иде. Һәм Гаяз, бикләүле тотылган кеше сыман, тәүлек ярым вакытын юлдашларының эчкәнен карап үткәрде.

Ул юынып-киенүгә, ишектә тегеләр күренде. Юллары уңган. Бүтәннәрнең уңмас иде. Боларның уңган. Бер буш кесәләре дә калмаган — һәркайсыннан, «күрәсезме!» дигәндәй, башын чыгарып, берәр шешә карап тора иде.

Алар каютага тавышсыз-өнсез кайтып керсәләр дә, ишекне ябып куйгач, бер мактанып алмыйча түзә алмадылар.

— Пажалыста! дип кенә торамы?
— Акча әйттерә-ә, акча-а!..
— Ул хәтле бирмәсәң дә була иде.

— Яңа акча бәласе. Мондый чакта искесе галәмәт шәп була торган иде. Унлыгы да бияләй чаклы иде. Чыгарып кына сала торган идек. Хәзер йөзлекне дә чыгарып салып булмый. Төртергә генә туры килә...
— Ире дә булмаган икән каһәрнең...

Юаны — хуҗа сыманрак кеше ахры — сүзне озайтмады:
— Бар, тәрәзәне яп әле, — диде.

Сыңар күзлесе йөгереп барып тәрәзәне япты. Пәрдәсен үк тартып куйды. Юаны аңа ярты стакан чамасы аракы салып бирде. Тегесе аны сөзеп кенә эчеп җибәрде дә, бер мыскал ризык капмыйча, башына менгәнне көтеп утырды.

— Җә ничек? — диде юаны. — Төзәлгәндәй булдымы?

— Төзәя башлады,— диде сыңар күз һәм, ата каздай, муенын сузып куйды.

Гаяз палубага чыкты.

Кояш таудан шактый күтәрелгән. Күтәрелгән дә, Агыйделне күреп, тик туктап калган — менә-менә сикереп төшәр дә йомшак су өстеннән тәгәрәп китәр сыман тора иде. Әле кичә генә кояшлы көннәр булуга инде өмет өзгән, яңгырга изелеп яткан күңелне бүгенге кояш тыеп булмас көч белән җилкендереп җибәрде. Күңелне генә түгел — Агыйдел буйлары да, бер талпынып, яшәреп киткәндәй булды. Юкса кичә — инде шаулап яфрак ярыр, чәчәк атар бер заманда — вакытсыз салкыннан гаҗиз калган агачлар катып-бөрешеп утыралар иде.

Кинәт ярдан Гаязның күзенә ап-ак нәрсә чалынып китте. «Әллә кар да эремәгәнме?» дип төбәп караса — күрче! — тау битендә бер оя шомырт агачы чәчәк атып утыра иде. Гүя алар, шомырт агачлары, «Җылы көн, бәлки, булмас та, аңа карап без чәчәк атмаска тиешмени?» дигән төсле, кышын посып яткан, ә яз җиткәч, килеп чыккан салкын көннәргә үч итеп, шулай эшләгәннәр иде. Әле яфракланып кына килгән башка агачлар арасында фәкать шомыртның, уйлап та бирмичә, шау чәчәктә утыруында Гаяз язның бөек көчен күрде: бу — башкаларга өндәү иде, бу — яз җиттеме, безне бернәрсә дә туктата алмас! дигән аваз иде.

Инде су шактый кайткан — Агыйдел, итәкләрен җыеп, үз ярына төшә башлаган. Ихтимал, төшеп тә беткән булыр иде, ләкин бер атна яуган яңгырдан соң ул тагын мөлдерәмә тулган — тугай җирләрдәге таллар бил тиңентен суда утыра иде әле. Шулай да быел Агыйдел рәхәтләнеп җәелеп китә алмаган: күрәсең, кыш карсыз килгән. Су күп елны Агыйдел болай гына булмый, болыннар гына түгел, авылларны да су баса. Шуңа күрә бу төбәк халкы Агыйделнең биек ягын «Кыр ягы» дип, ә язларын су эчендә кала торган ягын «Идел эче» дип йөртә.

Инде башка пассажирлар да уяна башлады. Уянганы бере палубага чыгып баса иде. Пароход исә, Гаяз күңеледәй ашкынып, чапкан ат тизлеге белән алдыра гына. Менә Агыйдел, калын урман үсеп утырган тауга килеп төртелү белән, аңа тибеп кенә җибәрде дә борылып әрәмә эченә кереп китте. Бу инде — соңгы борылма. Бу инде — туган як, һәр җире татлы хатирә уяткан туган туфрак... Әнә Күгәрчен болыны. Анда Гаязның бөрлегәнгә барганы бар — ашаганнан калганын күп күрсәтер өчен, чиләк тутырып яфрак алып кайтканы бар... Әнә Шәяхмәт бакены. Болын күлләреннән сөзеп-сөзеп тә тота алмагач, Гаязның балыкны Шәяхмәт карттан сорап алып кайтканы бар... Өзелеп сагындырган җирләр!..

Гаязның әтисе бу җирләр турында күп нәрсә белә иде. Әткәй сөйләр иде: монда Җылан җире бетә, Гәрәй дачасы [1] башлана дип күрсәтер иде. Гәрәй — безнең җиденче буын бабабыз. Ә Гәрәйнең бабалары болгар булган, Масрадан [2] күчеп килгәннәр, соңыннан ак патшага баш иеп барып, күп җир алганнар — шуннан башкорт булып киткәнбез...» дип сөйләргә ярата иде әтисе. Нииндидер шәҗәрә буенча үзен уникенче буынга чыгара торган иде. Димәк, Гаяз — ниндидер болгар бабайларның унөченче буыны. Димәк, унөч буын буена аларның канына шушы җир һавасы сеңгән. Һәм менә, туып-үскән якларны яңадан күрү белән, аның һавасын яңадан иснәү белән, Гаязның йөрәге сагыштан бер кысылып куйды да ләззәт белән тибәргә тотынды: каны, язгы Агыйделдәй, тамырларына тулып ага башлады.

Кояшка гына кызынып, тирә-якны берниндн уйсыз-хиссез карап барган бер пассажирның:

— Хәзер нинди пристань була? — дип соравы Гаязны айнытып җибәрде.

---

[1] Дача — башкорт җирләренең элекке ыруг-географик бүленеше.

[2] Татарстанның Арча районында Масра дигән авыл бар, бәлки шул күздә тотылгандыр. *(Искәрмәләрнең барысы да авторныкы.)*

— Хәзер безнең пристань! — диде ул һәм каютага кереп китте.

Күз тышта калганлыктан, каюта эче баздай караңгы иде, шушы караңгылыкта тегеләрнең генә йөзе балкып тора иде.

— Җитәбез! Соңгы борылма!

— Чәнчелеп кенә китсен икән! — диде сыңар күз.— Баш төзәтә торгач, исерә генә башлаган идем.

Юаны дәшмәде. Эчкәч ул үз дәрәҗәсен аеруча белә торган кеше иде. Артыгын сөйләнми. Боларның икесе дә артыгын сөйләмиләр иде. Хәтта кичә, дуңгыз урынына эчкәндә дә, артыгын сөйләнмәделәр. Авызларында җыен тузга язмаган сүз генә булды. Ичмасам, ялгыш та кайда эшләүләрен, кем булуларын ычкындырмадылар, хәтта бер-берсенә исемнәре белән дә дәшмәделәр. Менә шулай эчәләр иде алар. Аракыны, акыл бутамыйча, үзен генә эчәләр иде.

Ишеккә җиңел генә шакып, татар апасы — проводница килеп керде.

— Пастилләрегезне здавайт итегез, — диде ул.

Шулай диде дә, тегеләр астыннан одеал, җәймәләрен тартып алып, үзе үк җыя башлады.

Юан абзый шешәләргә ымлап күрсәтте:

— Җыеп алырсыз инде, — диде.

Апа дәшмәде.

Гаяз, урын-җирен тапшырып, билетын алды да төшәргә чыгып китте.

Пароход пристаньга җитеп килә иде инде. Пароход килер алдыннан катыктыр, күкәйдер сатарга төшкән апалар, бала-чагалар, пароходтан сыра эчеп чыгарга җиң сызганып торган агайлар күренде.

«Телеграмманы алдылар микән?» — дип уйлады Гаяз.

Пароход сузып бер кычкыртты да, агымга каршы туктар өчен, кыегая төшеп борыла башлады. Ун-унбиш минуттан инде ул, пристаньга каерып бәйләнгән килеш, пассажирларның төшеп-утырып беткәнен юаш кына көтеп тора иде.

Пристаньдагы бөтен халык бер авыздан «Гаяз!» дигән кебек булды. Кемдер аның кулыннан чемоданын алды. Гаяз берәүгә дә карамыйча, әнисенә таба атлады. Ике якка аерылып, ана юл бирделәр. Әнисе, бәләкәй генә булып, иң артта басып тора иде.

Әнисенең кайгы шикелле карт йөзен күргәч, Гаязга әллә ничек булып китте. Ул, ни әйтергә дә белмичә:

— Исәнме, инәй? — дип күрешергә кул сузды. Үзе елап җибәрмәс өчен: — Әллә елап торасың инде, инәй? — дигән булды.

Әнисе, гаепле кешедәй, тиз генә күзен сыпырып карады. Күзләре коры иде. Ул хәзер еламый — ул бая елаган иде. «Атасы мәрхүм каршы алалмады бит...» дип, кайгыдан елаган иде. Хәзер еламый. Хәзер аннан да бәхетле кеше юк. Бәхеттән кеше елыймыни!

Кифая әби улын, ике-өч яшьлек чагындагы төсле, күкрәгенә кысып сөярдәй булып торган иде, ләкин каршысына улы килеп баскач, кайсы жиреннән тотынырга да белмичә аптырап калды. Төпчек улы шулхәтле зур иде — бер көндә генә сөеп бетерерлек түгел иде. Шулай да ана, үрелеп булса да, аның битләреннән сыйпап, иңсәләреннән сөеп алды.

Апасы Җаннәт көлеп җибәрде.

— Инәйнең буе җитмәгәч, Әбел-Гаяз да риза булып, иелеп тора тагын.

Җизнәсе Гандәлиф тә килгән икән. Ул:

— Җә инде, әби, кайнышны безгә дә бир, без дә тотып карыйк,— диде.

Күрешү бик озакка китте. Һич күрмәгән кешеләр,— хәтта пристань буенда трай тибеп йөргән бала-чагасына хәтле, — «Исәнме...» дип,

Гаязның кулын тотып ала иде. Ләкин каршы алучылар арасында иң якын ике кеше — әтисе белән абыйсы юк иде.

Үзләре генә калгач, Гаяз:

— Бәлкабзый[1] нишләп төшмәде? — диде.

— Аламаланып тора, — диде әнисе. — Кан төкерүеннән бик курыккан идек, ярый әле, ходай үзе саклап, үтте ахры. Язы да бик алама килде бит.

Таһир турында сүз чыккач, әле генә кичергән шатлык янына егетләнеп кайгы килеп басты. Шулай инде ул. Таһир авырып киткәннән бирле шулай: шатлык әле чаттан гына күренгән була, ә кайгы инде аны, мәйдан тоткан батыр шикелле, бөеренә үк таянып кәтеп тора — имгәтеп ташламаса да, бер-бер хәл ясый.

— Врачлар нәрсә ди соң? — диде Гаяз.

— Мондагы брачлар нәмә әйтсен инде? Тиберкулиз дип әйтәләр. Мин яшь чакта безнең авыл Әскәр абзый да шуның белән чирләгәние. Мәгәр аның бит алмалары алсуланып торырие. Абдулла муллага баргач, француз чихуткәсе дип җибәргән. Җитен тастымалны чылатырие дә Әскәр абзый, аркасына ябарие, чылатырие дә ябарие. Шулай терелде. Әле дә исән. Таһирҗанның дәвасын белүче юк. Тын өрдерәләр дә тын өрдерәләр.

Җаннәт коры гына:

— Юкны сөйләмәле син, инәй, — диде. — Шул Абдулла мулла дип авыз суларыңны корытасың инде. Нәрсә белгән соң ул синең Абдулла муллаң?

— Брачлар бик белә инде! — диде әнисе.

— Врачлар белә: алар шуңа укыган. Таһирҗан былтыр җәй бик әйбәтләнгән иде әле. Әткәйнең үлеме генә бетерде аны...

Әткәй дигәч, Гаяз туктап Агыйделгә карады. Пароход инде кузгалып киткән, баягыдай кыегая төшеп, борылып маташа иде. Пристаньдагы халык ярга чыгып баскан. Пристань тирәсендә буталып йөрүчеләр дә, озатучылар да үшән генә тик басып торалар. Гаязлар киткәндә дә, яр буе шулай, тойгыларын белдермичә, татарча озатып калган иде. Тик әтисе мәрхүм генә, тагын куелган шикелле, пароход артыннан иярел бара-бара, менә шушы җирдә «өзелеп» калган иде...

Гаяз машина тавышына артына әйләнде. Яңа гына буяудан чыккан шикелле, ялтырап торган «Победа» белән тегеләр килә иде — сыңар күзлесе шофер янында, юаны берүзе артка бүселеп утырган иде.

— Болар кемнәр? — диде Гаяз.

Җизнәсе, сорауны аңламыйча:

— Кая кемнәр? — дип әйтүгә, «Победа» узып китеп, заготзерно ягына борылды, артын гына күрсәтеп, таудан менә башлады.

— Райсоюзныкылар... — диде Гандәлиф. — Берсе районда ашханә директоры шикелле, икенчесе — мондагы завсклад. Пароходтан төшкәннәрдер.

Гаяз елмаеп:

— Без бер каютада кайттык, — диде.

## Икенче бүлек

Алар Агыйделгә коя торган Миңеште тамагына килеп туктадылар. Пристань белән заготзерно Миңештенең бу ягында, авыл теге ягында булып, җәй көне тезгә җитмәгән бу елганы хәзер көймәсез кичеп булмый иде.

Кифая әби белән Җаннәт, житәкләшеп, көймәгә керделәр. Гандәлиф,

[1] «Бәләкәй абзый»дан үзгәргән.

аунакламасын дип, көймә борынын тотып торды, инде Гаязның гына кереп утыруын көтә иде.

— Әйдә кер, кайныш.

— Мин көсмән кагам[1], — диде Гаяз. — Син бар, койрыкка утыр, жизни.

Гандәлиф каршы килмәде, койрыкка кереп утырды. Шулай да:

— Көсмәннәр кагып торасы да юк инде монда, кайныш. Нык кына бер этеп җибәрсәң, чыгып җитү түгел. Олы урамга ук менеп китәрбез, — диде.

Гаязлар өе авылның югары очында иде, шунлыктан, әгәр Миңештәне бу урыннан кистереп чыксаң, җәйге шикелле, ындыр артлап кына кайтып булмый, урамга менеп кайтырга кирәк иде.

— Урам буйлап йөргәнче, Миңеште белән генә кайтыйк әле, — дип, Гаяз ишкәккә утырды.

Бот буе гына малай чагыннан ук көсмән тотып кул кабарткан Гаязның, кабаттан да ишкәкне кулында сизү белән, беләк мускуллары уйнап, күңеленә читтә чакта онытылып торган бер хис йөгерде. Башына киткән шушы хискә бирелеп, ул үкчәләрен аркылы җепсәгә җәйлап терәде, ишкәкнең берсен алга, икенчесен артка ишеп, көймәне Миңеште үренә борды. Башын артка ташлый биреп, кулларын алга сузды һәм талпынып ишә башлады. Су үзле балчыктай тыгыз, төскә дә болганчык-кызгылт, мәгәр чәчрәп калган тамчыларында салават күпере төсләре уйный иде. Бер мәлгә Гаяз шушы тамчылардан күзен ала алмый барды, аннан:

— Йөргән җирләремдә бар да бар — суы гына юк иде, шунысы үтерә иде, — диде.

— Агыйделе юк идемени, кайныш?

— Кая! Инеше бар идеме дип сора.

— Балакаем... — диде Кифая әби һәм күзен күтәреп улына карады.

Ул, бүгенге кояш, бүгенге шатлык җылысына изрәп, кайнарлатып баскан тамгадай, күңелен уеп төшкән хатирәләренә чумып бара иде. Болай да ул әнә шул хатирәләр белән яши, чөнки аның үз тормышы юк, үзе дә бүген бар, иртәгә юк. Чын мәгънәсендә авыз тутырып әйтә торган үз тормышыннан — шул тормышның үзеннән дә ямьлерәк хатирәләр генә торып калган. Әле менә шулардан айнып, күзен күтәреп карагач, бер хатирәне икенчесе алмаштырды — йөрәген «Аһ!» дип истән аварлык сагыш алды... Гаязларның әтисе Сөләйман белән кушылганның беренче язында булса кирәк, Сөләйман аны көймә белән йөртергә алып чыккан иде. Агыйдел быелгы белән чагыштыргысыз киң, Миңеште тамагы да моның ише генә түгел — читәннәрне егып, бакчаларга хәтле кергән иде. Аның бу тикле суны гомердә күргәне юк — ул кыз булып үскән авылның карап торган елгасы — каз-үрдәк пычтырдап яткан бер инеш иде; аның Миңеште тамагына җиткән саен йөрәге алына барды: су зур — көймә кечкенә! Тормыш шулай башланган иде. Хәзер үтеп тә киткән. Каялар гына китеп югалды соң бу гомер?! Кичә генә булган кебек иде бит юкса. Агыйделе дә шул ук. Миңештесе дә. Кояшы да шулай ук кыздыра. Тик ул вакытта аның яшьлеге бар, Сөләйманы бар иде. Хәзер — юк. Хәзер янында утырган кызы бар да, каршында утырган улы бар. Ул вакытта алар юк иде. Ул вакытта аңардан күзен алмаган Сөләйманы гына бар иде...

Ана тагын күзен күтәреп улына карады. Улы гәүдәсе белән генә әтисенә охшаган, төсе белән охшамаган. Төсе белән беркемгә дә охшамаган. Үзенә башка төс иде.

Гаяз да әнисенә карап алды һәм малай чактагы шикелле оялып кына елмаеп куйды.

«Кичү» дип аталган төшкә җиткәч, Гандәлиф жизнәсе телгә килде:

---

[1] Ишкәк ишәм. Көсмән — ишкәк. Борынгы болгар теленнән калган.

— Өченче көн шушында, көймәләре капланып, өч кеше суга төште.

Гаяз жизнәсенә карады. Жизнәсенең сүзләре аны гажәпләндермәде: ул белә-белгәннән бирле, яз саен, Миңеште тамагында суга төшми калмыйлар иде.

— Үлүчеләр юкмы? — диде ул.

— Була! — диде апасы. — Эчәргә сылтау эзләп йөрүчеләргә житә калган. Хатыннарыннан акча сорар өчен юри чыланып менгәннәр. Аннан кире, салкын тимәсен дип, төн буе эчкәннәр.

— Их, шунда мин дә булсам! — диде Гандәлиф.

— Ачуымны китереп утырма, яме! — диде Жаннәт. — Суга төшмәсәң дә, син дә чыланып кайтасың.

— Шул исерекләрне сөйләмәгез әле, — диде Кифая әби.

Кыелып төшкән текә яр бетеп, су читеннән үк чирәмлек башланды; елга тибүе дә жәелеп киңәеп китте. Гаяз ишүдән туктап, ишкәкләрен күтәреп куйды — көймә килеп төртелү белән, жиргә сикереп төште. Аяк астында үз туфрагы, үзләренең ындыр арты иде. Бәбкә үләне дә ул басасы жиргә палас булып яткан иде.

Ындыр артыннан бәрәңге бакчасына керделәр. Гаяз туктап, читән буендагы тирәкләргә карады. Акман бабасы утырткан тирәкләр болар. Акман бабасы үзе инде күптән юк. Кырык ел инде юк. Акман бабасыннан хәзер бернәрсә дә калмаган — менә шушы тирәкләр генә калган. «Үзең үлгәч, карап искә алсыннар дисәң, агач утырт — төсең булып калыр», дип әйтә торган булган Акман бабасы. Гаязның бәләкәйдән үк исендә: атасы мәрхүм, үткәндә-сүткәндә, шушы тирәкләргә озаклап карап тора торган иде. Хәзер әтисе дә юк. Хәзер менә ул карап тора...

Ул бер тирәкнең янына ук килде, менәргә чамалагандай, өскә карады. Агач башларына оялаган каргалар, аны танагандай, дәррәү кубып, колак тондыргыч тавыш күтәрделәр.

— Ай, шуларның бөтенесен бер юлы атып бетерергә! — диде Гандәлиф.

— Атасы мәрхүм балалардан таш та аттырмас иде, — диде Кифая әби.

Әнисе сүзеннән Гаяз күңеленә берьюлы, моңсу булып, ваемсыз бала чагы калкып чыкты, күз алдына әтисе килеп басты. Сагыш өстенә юксыну килеп кушылды. Үткәндәге күп нәрсә инде табылмаска югалган, кире кайтмас жирдә калган икән. Аңа кинәт ямансу булып китте.

Ул тиз генә апасы белән жизнәсе янына килде. Әнисе аларны көтеп тормаган, киткән, лапас янындагы кече капкага житеп бара иде. Гаяз сукмакка төште. Аның артыннан Жаннәтләр дә иярде. Һәм алар озын бакчаны сөйләшмичә генә үтеп, ишек алдына кайтып керделәр. Янгырдан карайган болдыр өстендә елмаеп Таһир басып тора иде.

Быелгы яз аны бик йончытты. Яз аны болай да йончыта. Мәгәр быелгысы бөтенләй аяктан екты. Шулай да бүген, — әллә һаваның кинәт ачылып корыга китүеннән, әллә инде энесе кайту шатлыгыннан, — иртәдән үк каефләнеп аягына басты. Ләкин пристаньга төшәрлек хәле юк иде.

Ул әкрен генә баскычтан төште. Аның сөлектәй озын гәүдәсен, күлмәгедәй ак йөзен күргәч, Гаязның сагынуы да, кызгануы да бергә кушылып, йөрәк турысыннан нидер чәнчеп алды. Күзләренә кинәт ачыттырып дару салгандай булдылар. Моңысы кирәкмәс иде, бу кадәр жебемәскә иде, диде ул. Абыйсы күргәнче дип, тиз-тиз генә күзен йомгалап алды. Ике туган бер-берсен кочакларына алдылар. Гаяз, абыйсының ябык гәүдәсен күкрәгенә кыскан килеш, үзен-үзе тыя алмыйча:

— Шушы көннәргә калдыңмыни, бәлкабзый?.. — диде.

Таһир һаман елмая иде, гүяки энесенең ташып торган тазалыгы аңа да күчкән иде.

— Солдат әпие килешкән сиңа, апай[1], — диде ул. — Күкрәкләрең куна тактасыдай булган.

— Их, бәлкабзый! — диде Гаяз.

Кичкә туган-тумачаны ашка чакырдылар. Сәгать алтыга диелгән иде, ләкин һәркайсы, кешедән алда чабып бару килешмәс дип, татар гадәте белән иң азактан килергә тырыша торгач, сәгать җидегә көчкә җыелдылар. Инде Саһира җиңги белән Локман гына юк иде. Гаязларның әтисе Сөләйманнан кала, нәселдә иң өлкәне Локман булганлыктан, ул кермичә табын ачуны килештермәделәр.

— Бар, тагын кереп чык әле, Гандәлиф, — диде Җаннәт. — Кайтып та, керми ятмый микән?

— Кайтмагандыр, — диде аңа Кави. — Кайтса керер иде. Безнең әткәй, аш дигәндә, арттан йөрми торган иде алай.

— Кая киткән соң ул? — диде кемдер.

Аңа Гандәлиф җавап бирде:

— Кая түгел. Монда гына. Теге, Нух пәйгамбәр алып чыгып киткән.

— Ул сыңар күзне Караиделгә салга киткән дип әйткәннәр иде бит?

— Кайтты. Бүген кайнышы белән бергә кайттылар.

Шул вакыт Саһирә җиңги белән Локман килеп керде.

— Гомерегез озын булыр әле, төпчек абзый. Сөйләп кенә тора идек, — диде Җаннәт.

— Ата-бабаларыбыз озак яшәгән, — диде Локман. — Сөләйман абзый гына менә вакытсыз китте.

Локман, алтмыш өстендә булса да, йөрәккә таза, беләккә нык; тешләре белән шешәләрдәге калай капкачны гына каерып ача иде әле. Ул, галошларын ишек төбенә салып, түргә узды.

Өстәлгә утырыштылар. Кифая әби генә утырмады. Эчкән табынга утырмыйм, диде. Җаннәт зур табактан аш бүлә башлады. Гандәлиф ирләргә кирәген карады. Локман, моны күргәч, мыегын сыйпап куйды.

— Мыегыңны төзәткәләп утырма, — диде аңа Саһирә җиңги. — Тәүбәгә килергә дә бик вакыт инде.

— Тәүбәсенә килербез әле, кортка, — диде Локман. — Түлке бүген түгел. Бүген Әбел-Гаязыбыз кайтты. Җәгез әле, туганнар, Әбел-Гаязыбыз хөрмәтенә, авыр булса да, күтәрик әле. Тәүбәсен анысын капнибудь тә игәрбез. Үлем түшәгенә егылганчы итсәң — кабул ул. Әйдәгез.

— Тоталмыйм мин бу нәстәне, — диде шунда Кави. — Салып бирчәле, жизнәй, учлабрак тотарлык савытка. Башка сорамам.

— Жизнәңне дә котыртып стакан сорап утырма, җәмә, — диде аңа Җаннәт. — Рюмкадан эчсәм исермәм дип куркасыңмыни?

— Тоталмыйм бит, Җаннәт апа. Бармакларым нечкә биленә якын да килми. Менә!..

Гаяз да аның кулына карады — бармаклары гына да берсе-берсе рюмка юанлык бар һәм рюмкага якын да килмиләр иде. Гаяз көлеп:

— Синең ул кулга, абзый, стаканы да бәләкәй булыр әле, — диде.

— Нишлисең бит, апай. Балта сабыннан да нәзекне тоталмыйм. Менә балта эшенә кер әле, синең дә шулай булыр.

Гандәлиф аңа стаканга салып бирде дә:

— Кайнышны мин үземнең янга димләргә итеп торам әле, — диде. Локман авызына китергән кашыгын кире куйды.

— РТСкамы? — диде.

[1] Минзәлә — Уфа — Әгерже арасында яшәүче татарлар үзләреннән кече һәркемгә «апай» диләр. Шул ук вакытта «энем», «сеңелем» сүзе дә бар, ләкин алар азрак кулланыла. Башкорт телендә һәм татарның кайбер сөйләшендә «апай» дип апага әйтәләр.

— Нигә? Кәкрәс шофер кирәк. Андый урын гелән булып тормый ул.
— Кешенең урынысы үзе белән, — диде Локман.
Кави да сүзгә кушылды:
— Колхозда да эш житәрлек!
— Машина эшеме? — диде Гандәлиф.
— Машина гына димәгән. Күпме төзиләр хәзер колхозда.
— Балта эшендәме? — диде Гандәлиф.
— Балта эшенә ни булган? — диде Кави.
— Кайныш солдатта балта тотмаган. Руль тоткан.
— Солдатта без дә кое-што тоттык. Ә хәзер балта тотабыз.
— Хәзер балта заманы түгел. Хәзер техника заманы.
— Техника безнең нәселгә төс түгел. Килешмәде ул безгә. Әнә Таһиржан...
Кави әйтеп бетермәде. Башламаска ук кирәк иде, диде ул.
Таһиржан таза чакта тракторда эшләгән иде. Ләкин, Гаяз армиягә киткән көзне, печән ташыганда боз ватылып, тракторы-ние белән Агыйделгә төште. Күргән кешеләр: башта бүреге калыкты, бик озак торгач, үзе килеп чыкты, диделәр.
— Андый хәлнең теләсә кемгә килүе мөмкин, — диде Гандәлиф.
— Теләсә кемгә килмәгән бит. Тәчиб кортка малаена әнә — килмәгән. Чыгып өлгергән. Нигә ул да төшмәгән?..
— Кулыңны бик селтәмә, ашыңны түгәсең, — диде аңа хатыны. Кави кулын селтәвендә булды.
— Кыскасы шул: безгә техника төс түгел. Безгә балта төс. Акман нәселе балта тотарга тиеш!..
— Акча да тотарга тиеш! — диде Локман.
— Анысы миннән булмады инде, әткәй. Акчасын тота алмадык.
— Минем киңәшне тотмадың. Шуңа акча да тоталмадың. Колхозда эт сугарып йөрдең. Колхозда семьядан ике кеше эшләгәч житәдерие. Сиңа, мин әйткәч тә, заготзернога күчәргәе.
— Анда да көрәп бирмиләр. Менә бер ел эшлим — артканым юк. Шагалиев барда тоже ничава иде әле. Мамлиев килгәч бигрәк кысты.
— Мамлиев монда нипочем. Югарыдан кыстылар аны. Такыр баш кысты. Тазы — мин, кырчыны да булсын, дигәндер инде.
— Ярар, — диде Кави. — Акчасының майт якасына! Әйдә, тарт әле, Таһиржан апай, гармуныңны! Өз әле үзәгемне!
Ул сандык өстендә торган баянны үрелеп кенә алды да Таһирга сузды.
— Уйнале, апай!..
Бөтенесе дә ашаудан туктап Таһирга текәлделәр. Таһир монсу гына кыяфәт белән баян каешларын иңбашына киде. Күрек тартырга иркенрәк булсын өчен уң як читкәрәк шуышты. Башын кырын салгандай итте дә, йөзен сулга бора төшеп, бармакларын сәдәфкә тигезде — өзмичә-йолыкмыйча, өф итеп тоткан нәрсәдәй кадерләп кенә, «Гөлжамал» көен уйный башлады. Дөньясы онытылды: гүя аның көннәр начарлыктан көчәйгән сырхавы беткән, күкрәге дә чәнечми, үпкәсе дә саф һаваны бөтен күзәнәкләре белән сулый иде; Таһир гүя үзе дә моңга әверелгән, ә уйнаган көеннән үләргә яткан кешене дә терелтерлек көч-сихәт агыла иде...
Көйне бер тапкыр уйнап чыкканчы, аңа беркем дә кушылмады. Икенче тапкырында гына Жаннәт көр тавыш белән күтәреп алды:

Шәмдәлләрдә генә утлар яна, Гөлжамал...

Гадәттә башын гел уен-көлкегә салып, «шалтырабрак» йөргән Жаннәт, жыр башлау белән, бөтенләй үзгәрде: язгы көн кисүдән караеп тупасланган бите йомшарып, мөлаемланып китте. Ул, жыр гына житкән

хыялый ераклыкларга текәлгән дә, Гөлҗамал атлы кызның үзедәй, сагышланган иде. Аның гәүдәсендә бернинди боргалану юк, бернинди интегү юк — тын алганы да беленми иде. Ул тынны да шул тикле озын көй уртасында бер генә кабат ала иде. Авызы бер илле генә ачылган, иреннәре бөтенләй кыймылдамый кебек, әгәр авызын ялгыш зур ачып җибәрсә, көйнең бар моңы түгелер сыман: күкрәгеннән ургылып чыккан тавышы аны берьюлы өреп чыгарыр кебек иде. Аның тавышы һаман көчәя, һаман көчәя барып, тоташ бер агымга, дәрьяга әйләнде, язгы Агыйделдәй җәелеп, бөтен тарафны күмеп ташлады...

Көй табындагыларны берьюлы әсир итте, көндәлек мәшәкать белән ката төшкән күңелләр назланып, хисләр сафланып, җанга һәм тәнгә табигый халәт кайтты. Гаяз җырның тагын бер ягын белде: «Гөлҗамал» төсле сагышлы озын көйләр дә кешене изми икән — алай гына да түгел, җанга азык индерә, илһам бирә икән; туган җиргә, бөтен җан иясенә ягымлы мәхәббәт уята, йөрәкне җилкендереп, куллардан бөркет канаты ясый икән, — һәм син бер талпынасың да үз-үзеңнән күтәрелеп, моңдай көчле талпыну белән югарыга ашасың. Туган җиренне әнә шул биеклектән күрәсең, күтәрелгән саен туфрак якыная бара — Агыйдел ярларына кабат төшеп, сине үстергән, сине ир иткән нык җиргә нык итеп басып торасы килә, аунап-тәгәрәп, капланып ятасы килә...

Туган җир! Нигә син шулхәтле кадерле, кочаклап үбәрлек якын икән? Бездәге иң бөек тойгы, илсөяр тойгы, ата-бабаларыбыз дөнья көткән, дөнья калдырган менә шушы кечкенә йорттан башлана бит! Әле син — нарасый бер бала гына: күкрәк сөтен имгәндә, күзеңне ача алмасаң да, авызыңны ачып, башыңны чайкый-чайкый имчәк эзләгәндә, син үзеңнең дөньяда яшәвеңне дә белмисең, ләкин шул вакыттан ук инде синең карыныңа йөз төрле ризыкны алмаштырган татлы сөт ага; сөттән соң тамагың кибеккәч, син, авызыңны очлайтып, тагын нидер сорыйсың, аны әниең генә белә: су сорыйсың син, — һәм әниең балкашык белән генә синең авызыңа су сала... Сөт һәм су! Ана күкрәгеннән чыккан сөт нинди пакь булса, җир күкрәгеннән сөзелеп кенә чыккан чишмә сулары да — шундый ук. Шулай булгач, Анага булган мәхәббәтнең — сөттәй, Җиргә булган мәхәббәтнең чишмәдәй сафлыгына гаҗәпләнмәгез...

Менә нинди тойгылар уята үз җирең, үз көең!..

Җыр агылды-агылды да тагын үз ярларына кайтып туктады. Өй әче тып-тын булып, үтә сәер булып калды, ләкин җыр колактан китмәгән, колак төбендә генә эленеп тора иде.

Беренче булып Кави телгә килде — Таһирның бармакларыннан күзен алмаган килеш:

— Әллә сөяге юкмы соң, апай, синең ул бармакларыңның? — диде. — Моңа чаклы бер дә игътибарлап караганым юк иде.

— Гел сөяк кенә, абзый!

— Ышанмыйм, булмас! Сөяк булса, шул төсле йөри алмас иде. Күз нәрми бит, парин! Телләренә тигән кебек тә түгел.

— Безнең кайныш уйный инде ул! — диде Гандәлиф тә.

— Нигә мине берегез дә мактамый әле! — диде дә Җаннәт кычкырып көлеп җибәрде.

— Синең туры да сүз особый әле,— диде аңа Кави.— Син нигә алай Гандәлиф җизнәй алдында: «Авыр җан сөйгәннәрнең булмавы», дип җырлыйсың? Җәле, җизнәй, үзенә дә җырлап җибәр әле берне, хотя бы: «Син сөймәсәң, бүтән бар...» дип.

— Бик җырлар иде дә, җыр белми бит, — диде Җаннәт.

Алар сөйләгәнне елмаеп кына тыңлап утырган Гандәлиф:

— Мин күңелдән генә җырлыйм, — диде.

— Нишләп син, җизнәй, һаман күңелдән генә җырлыйсың? Кырык-

ка житеп тә, кычкырып жырлый белмисең? — диде Кави. Әйдәле, алай булгач, Таһиржан апай, тартып жибәр әле минем көйне, үзем жырлап күрсәтим әле жизнәйгә.

Таһир маңгаена бәреп чыккан тирен сөртте дә Кави гына жырлый торган көйне башлады. Кави карлыккан тавыш белән акырып жырлап жибәрде:

Агыйдел буйлары ямьле,
Бакенщик буйлары ком.
Эчкәйләрем тулы кайгы,
Тышкайларым тулы моң...

Ләкин соңгы өлешен икенче кабатлап тормады:

— Миннән дә булмый икән, авыр, — дип кул селтәде.

— Бәй, әллә син аны бүрәнә чабу дип уйладыңмы? — диде Гандәлиф. — Мин шуны белеп кычкырып жырламыйм.

Таралышканда Гандәлиф тагын да эшне искә төшерде.

— Шулай да, кайныш, синең чутта мин Әсфәндияров абый белән сөйләшеп куям, — диде.

Гаяз дәшмәде. Локман аның колагына үрелде:

— Бик ашыгып барма, улым. Башка эш чыгарга тора...

— Ял ит тә дип әйтмиләр бит, ә! — диде Кави. — Әбел-Гаяз, апай, карама шулар сүзенә! Ял ит...

Гаяз аларны озата чыкты. Кич жилсез, болытсыз иде. Күк йөзе, көндезге зәңгәрлеген жуеп, карасу төскә кергән. Кояш инде «Идел эченә» төшеп баеган, ләкин офык чите кызгылт-сары төсләр белән яна иде әле.

— Кояш аязга баеды. Көннәр әйбәтләнеп китәр инде, боерган булса, — диде Локман.

Алар киткәч, өй эче бушап, тынып калды. Гаяз кергәндә, Таһир әле өстәл янынннан кузгалмаган иде. Гаяз да аның янына килеп утырды. Сөйләшер сүзләр бөтенләй юк кебек. Мондый чакта, күңелләр урыныннан кузгалган чакта, телләр түгел, туганлык хисләре сөйләшә иде. Таһир, энесенә елмаеп, яратып карап торганнан соң, ничектер борчылып сорап куйды:

— Китәргә кайтмагансыңдыр бит, апай?

Бу сорау аның теленә, Гаяз кайтып, туган өй бусагасына аяк баскач ук килгән иде. Тик ул сорарга һаман кыймый торды: сораса — «Китәм шул, күрергә генә кайттым», дигән жавап ишетер сыман иде.

Ләкин Гаяз:

— Юк, бәлкабзый, китәргә кайтмадым, — диде.

— Китмә шул... — диде Таһир.

### Өченче бүлек

Гаяз уянганда сәгать дүрт кенә иде әле. Ләкин аның инде йокысы туйган: Себер якларында өч ел хезмәт итү, аннары шунда ук тагын бер ел эшләү сәбәпле, андагы иртә вакытка күнегелгән, һәм әле кайтып төшүнең икенче көнендә үк мондагыча торып китеп булмаячак иде.

Ул, кулларын баш астына куйган килеш, түшәмгә карап ята бирде. Түшәм, кыш чыккач, гәрәбәдәй итеп юылган, хәтта пычак белән кырган эзләре дә беленеп тора. Бөтен түшәм бер такта кебек тигез иде! «Салынганына быел ун ел!» диде Гаяз. Бу йортны әтисе үзе салды. Ул вакытта әле Гаяз, бала гына булганга, әтисе эшен үз акылы, үз тәжрибәсе белән бәяли белмәгән икән. Ә менә хәзер, беренче кабат ныклап карагач, ул: «Әткәй чынлап та оста булган икән!» дип куйды. Әтисенең,

куе кара мыегын бөтерә-бөтерә башын аз гына кыегайта биреп, тәрәзә рамнары ясавын — инде сагыну түгел, башыңны шушы стенага бәрсәң дә кире кайтмас чакларны исенә төшерде.

Аннары ул сикереп торды да тиз-тиз генә киенә башлады.

Әнисе дә торып, үз ягыннан килеп чыкты.

— Кояш чыксын инде дип ята идем. Ә син нигә, улым, бик иртәләдең?

— Йокы туйды инде, инәй. Бу вакытта без эшкә тотына торган идек, — диде Гаяз һәм: — Агыйдел буйларын бер әйләнеп кайтыйм әле, — дип чыгып китте.

Заготзерно тавы тоташ бер нурга күмелеп, кояшны каршы алырга җыенган иде. Гаяз бу таныш күренешкә сокланып, ләззәтләнеп карап торды да Агыйдел буена төшеп китте.

Кояш, беренче башлап, үзенең нурларын шушы мәһабәт дәрья өстенә буйдан-буйга сибеп җибәрде. Су өсте, күз нурын алырдай булып, ялтырап-яктырып китте. Кояшны бар табигать шатланып, җилкенеп каршы алды. Салкын көннәрдә тавыш бирмичә, берәр җирдә өшеп утырган кызылтүш, чебенче кошлар, таң чыпчыклары куанышып сайрарга керештеләр... Чү! Сандугач түгелме соң? Сандугач шул! Ләкин әле бу аның ныклап сайравы түгел, бу аның, чын музыкант кебек, тавыш көйләве генә иде. Сандугачлар да, бар тереклек шикелле үк, җылы көн көткәннәрдер. Менә ул көн килде — инде Агыйдел буйлары иртә-кич сандугач моңына күмелер...

Гаяз зираттан юлга чыкты. Елкылдап торган кара айгыр җигелгән тарантаста колхоз председателе Тәлха Сәйдәшев утыра иде. Ике кулы белән дә дилбегәне тартып тоткан. Айгыр исә шәпләнеп башын чайкап җибәрә иде.

Сәйдәшев башта Гаязны танымый торды. Танышач, зур авызын җәеп елмайды.

— Бәй, Әбел-Гаяз түгелме соң син, апай?

— Мин, — диде Гаяз һәм: — Нихәл, Сәйдәшев агай? — дип тиз генә килеп күреште.

Тәлха Сәйдәшев 43 нче елны сугыштан кайтканнан бирле, гомумән Гаяз белә-белгәннән бирле — менә егерме ел инде, председатель булып эшли иде. Колхозларны азаккы берләштерүдә Гаязларга да председатель булып калды.

— Кайчан кайттың? — диде ул.

— Кичәгенәк.

— Бик иртә торгансың.

— Йоклатмады. Сагындырган. Агыйдел буйларын әйләндем. Зиратка да кереп чыктым...

— Шула-ай, апай... — диде Сәйдәшев. — Әтәң картны күрә алмый калдың шул... — Аннары читкәрәк шуышып киткән култык таякларын үзенә таба тартып куйды. — Әйдә, кайтасыңмы?

Гаяз утыру белән, ул дилбегәне бушатып җибәрде. Ат җиленнән борынга тансык ис килеп бәрелде.

— Машинаң кайда, Сәйдәшев агай?

— Буяткан булган идем... Үзең соң, ничек, отпускыгамы?

— Минме? — диде Гаяз. — Мин бөтенләйгә кайттым.

— Сине бит солдаттан соң кайдадыр эшкә урнашкан дип әйткәннәр иде?

— Демобилизациядән соң безнең частьтан берәү дә кайтып китмәде. Һәммәбез дә комсомол путевкасы белән чирәм җирләргә киттек. Төпләнеп калучылар да булды. Мин менә кайттым.

— Дөрес иткәнсең кайтып, — диде председатель, ләкин шатланырга ашыкмады, чөнки авыл кешесе, читтә бер йөреп кайттымы, колхозны түгел, заготзерно ягын чамалый торган иде.

— Эш турысында да уйлашырга кирәк булыр инде, Сәйдәшев агай,— диде Гаяз үзе башлап.

— Шулай инде, шулай... Исәпләрең кай тирәдәрәк соң?

— Хезмәттә мин моторизованный частька эләктем. Совхозда да һаман машинада эшләдем. Исәбем колхозда инде, Сәйдәшев агай. Бәлки, син дә машина бирерсең?

Председатель шатлыгын сиздермәс өчен айгырын тыя төште.

— Тәртәсе кыскарак. Дилбегәне чәк кенә бушайттыммы, сажжин ярым атларга керешә, тоягын бәрә башлый, — дигән булды. — Бүгеннән генә буш машина юк юклыкка. Шулай да табарга була. Иие. Табарга була анысын. Тик яшерен-батырын түгел, апай: бүгеннән миңа төзелешкә кешеләр кирәк. Төзелеш күп — осталар аз. Юк осталар! Җиде авылдан көчкә-иллалла җиде бригат әтмәлләдек. Халык та һәркайсы йорт житкезә. И шуннан уйла инде: әз генә балта тота белгәне дә көйләтә, апай. Чыктым-киттем белән куркыталар. Сезнең Кави белән шулай булмадымыни?! Ярый инде, Кавие — Кави. Ул, ни әйтсәң дә, оста! Чыпчык Сәмих ишеләре дә бар бит әле аның. Беләсең син аны, сельмагта сатучы иде. Кайсы үз аягы, кайсы бүрәнә икәнен бутый торган бер бәндә иде. Син юкта өстенә чыгып, төрмәдә дә утырып кайтты. Шунда әзрәк балта тоткан бугай. Хәзер нәстә эшләй диген? Йорт сөйләшеп чыгып киткән. Егыл да үл! Һа-ай, Сөләйман абзыйны терелтәсе иде! Эшләмәсен иде. Карап кына торсын иде... Юк, кайтыр жирләргә китмәде. — Сәйдәшев башын чайкап, телен шартлатып алды. — Мәрхүмгә илле чакрымнан килерләр иде. Колхоз рөхсәтеннән башка шаг та атламас иде. Ә хәзергеләр нәрсә? Карап торган Кавиебыз бар иде. Ул да тәртәгә типте. Локман абзый котыртты. Иблис дисәм — сезнең зат...

Алар өске урамнан килеп, олы урамга төштеләр. Күзләрне чагылдырып Агыйдел күренде.

Тәлха Сәйдәшев, атын тыя төшеп, нәрсәгәдер колак салып торды. Аннан соң:

— Вот понимаешлар, һаман эшкә тотынмаганнар! — диде һәм ачу белән атына сукты.

Тәрәзә астына хәтле менгезелгән бик озын бура утырган бушлыкка житкәч, атын шунда борды. Тып-тын, берниндн җан иясе барлык та беленми иде.

— Клуб буламы бу? — диде Гаяз.

Председатель аңа, җавап урынына, дилбегә бирде:

— Бүрәнә башына бәйләп куй әле.

Аннары тарантастан төште, өскә бөкләп, бил каешына кыстырып куелган чалбар балагын рәтләде дә, шалтыр-шолтыр китереп, култык таякларын алды. Гаяз кайтып китәргә уйласа да, председатель «әйдәле!» дигәч, аңа иярде.

Бураның кояш төшкән ягында ике ир балта көйләп утыра иде. «Исәнмесез!» дигәнгә аягүрә бастылар.

— Башкаларыгыз кайда? — дип кычкырды председатель.

— Килеп житмәгәннәр әле, Сәйдәшев агай, — диде берсе. Гаяз белән күрешергә кул сузып килгән җиреннән туктап калды.

— Нишләп яталар соң алар бу вакыт житкәнче? Артларына кояш төшкәнче ятмасалар!..

Тыкрыктан тагын ике кеше төшеп килә иде. Сәйдәшев, бөтен гәүдәсе белән култык таякларына асылынып, шул якка борылды һәм башын чайкап торды.

— Һей мала-ай! Болар да эшкә барабыз дип киләләр микән? Тфү, әдәм тәганаләре! Корсагы борынына житкән хатыннар да алай йөрми,

валлаһи! — Аннары ул ачы тавыш белән кычкырып җибәрде: — Шәбрәк атлый беләсезме сез, юкмы, понимаешлар?!

Тегеләр шунда гына председательне күреп алдылар һәм, тәмәкеләрен сүндереп ташлап, кызу-кызу килә башладылар. Урамнан да өч кеше күренде.

— Ә Исмәгыйль кайда?

— Килмәгән әле... Хатын яшь, төн кыска...

— Бирермен әле мин ул оппортунистка яшь хатынны! Өйләндем дигәч тә, ач талпан кебек ябешмәсә! — Аннары ул Гаязга әйләнеп карады. — Күрдеңме инде, апай: эшчеләре дә соң килә, ә бригадиры алардан да соңрак йөри...

## Дүртенче бүлек

Гаязның чыгып киткәнен Локман тәрәзәдән күреп калды. «Таң тишегеннән кая барыр икән бу бала? Гандәлифләргә менеп китте бугай. Әллә РТСка керергә чамалыймы?» — дип шиккә төште ул. Аннары үткен балтасын алып чыкты да, бик әйбәтләп, «Бисмиллаһи аллаһе әкбәр»ен әйтеп, тавык суеп керде. Саһирә җиңгигә:

— Әбел-Гаязны алып керербез. Аш сал, — диде.

Һәм менә ул Гаязның әйләнеп кайтуын сабырсызланып көтеп тора иде.

Берничә ел рәттән Локман, яз җитү белән, Агыйделдә юл өзелгәнче, Камбарка стансасына чыгып кала һәм агач-ташка бай булган Пермь якларына китә торган иде. Кайтуын ул соңгы пароход белән генә кайтып төшә. Кулда бер арыш капчыгы корал, өстә иске кәҗән, кесәдә кыш җитәрлек акча була иде. Ләкин быел, сөйләшеп кайткан кешесе булса да, ала кардан кәсепкә чыгып китмәде, бакчасына тотынды. Алмагачлар, бер дә тәрбия күрмәү сәбәпле, елдан-ел кыргыйлана бара иде. Шуңа күрә Локман быел беркая да чыкмаска, бакчасын рәткә китерергә булды: бер дә бер көн кулдан эш китсә, карап торган бакча гына торып калачак иде. Ләкин хәзер, буш кесәгә кул тыккан саен, Локманның эче поша башлады. Бакчада эш саега төшкәч, берәр яры чыкмый да булмас диде ул. Пермь якларындагы шикелле үк хутлы булмаса да, өй салдыручылар якын-тирәдә дә күп иде. Иптәш кенә тап.

Гаязның көтмәгәндә кайтып төшүе аны өметләндереп җибәрде. Шуның өстенә, эше дә табылып тора: кичә аны завсклад Нух дәшеп алды. Үзе Караиделдә райсоюзга сал кайтарту артыннан йөргән чакта осталарын тотып алып киткәннәр: язын күрше республикага чыгып больница салганда, бер машина такта саткан булганнар. Нух бәргәләнә генә. Башкаларны борып кына җибәреп торган Локман аңа: җавабын иртәгә әйтермен, диде. Шуңа әле Гаязның әйләнеп кайтуын сабырсызланып көтә иде.

Гаяз ишек алдына кайтып керү белән, Локман аны дәшеп тә алды.

— Төпчек җиңгәң, сине алып керербез дип, аш салган иде...

Колагында әле һаман да Сәйдәшевнең ачы тавышы ишетелеп торган хәлдә, Гаяз ике арадагы кечкенә капка аша Локманнарга керде. Моннан нибары утыз-утыз биш ел гына элек салынуына карамастан, Локманнарның өе искергән, таш нигезгә утырмаганга күрә, астагы бер ниргәсе череп, бүселеп чыккан, өй җиргә иңә башлаган иде.

— Яңаны салырга кирәк, төпчек абзый, — диде Гаяз.

— Эт ексын инде, — диде Локман. — Картайдым да. Малайлар үзләренә салыр әле.

— Нәҗим нинди эштә? — диде Гаяз.

— Төрле эштә йөри шунда. Укыта алмадым бит. Аяк терәп карышты. Хәзер әнә колхозда йөри. Әле аръякка чыгып китте. Безнең бригат-

ка, үзең дә беләсең бит, элекке Кырлач жирен бирделәр. Шулай, берләшә торгач, үзебезнең жирдән дә торып калдык. Сәйдәшев кенә житте безнең колхозның башына: авторит зур — буй житмәле генә түгел. Тотты да үзенә кушты. Халыкка ни кисәтүен кисәттем: кушылырга ризалашмагыз, дидем. Алар хәл итә разве хәзер? Өстән ни кушсалар — кул күтәрәләр дә, ярхәмикә алла дип, бит сыйпап куялар. Безнең жирләр үзенә башка иде! Учыңа ал да кап та жибәр иде!..

— Бер колхоз булгач, барыбер түгелмени, төпчек абзый?

— Барыбер булса, тәрәзәдән йөрерләр иде...

— Син! — дип дәште аңа Саһира жиңги. — Тукмачны салыйммы инде?

— Салсаң сал. Башта безгә итен куй әле. Әйдә, Әбел-Гаяз улым, без синең белән башта юынып алыйк.

Юынгач, өстәл янына утырдылар. Саһира жиңги сутан исе бөркеп торган бәрәңгеле ит китереп куйды.

— Син! — диде ул тагын. — Үзеңә күп салгансың бит. Яшь кеше белән тиңләшмәсәң дә ярарие.

— Йомрыда торсын дип кенә салдым, — диде Локман. — Әйдә, Әбел-Гаяз улым, ит алдыннан жибәр әле. Хәзер шул йөри инде алдан, первай сүзне шул әйтә.

— Юк, әчмим, төпчек абзый, — диде Гаяз. Чынаягын читкә үк этәреп куйды.

— Үзең кара инде, алай булгач, — диде Локман.

Гаяз, сүзсез генә ашап алганнан соң:

— Мине Сәйдәшев эшкә чакырды әле, — диде.

Локман шундук мыегын тырпайтты:

— Кайтып житмәс борын нинди эш ди ул?

— Төзелешкә, — диде Гаяз. — Мин машина сорадым. Бүгеннән генә буш машина юк, ди.

— Аның урынына буш баш шоферлары бар.

— Ул Һабилга право биргәннәрме инде, юкмы? — дип Саһира жиңги дә сорап куйды.

— Тарзанны әйтә, — диде Локман. — Аңа права ишшү! Яшел белән кызылны аера белмәгән кешегә нинди права бирсеннәр? Моңа яшелне күрсәтәләр икән, бу — кызыл, ди икән. Кызылны күрсәтәләр — яшел, дип әйтә икән. Ялгыш та ичмасам яшелне яшел дип әйтми икән.

— «Акны» бик тиз аера лабаса, — диде Саһира жиңги.

— «Акны» без дә аерабыз ла ул, — дип, Локман Гаязга гына сөйли башлады: — Колхоз жирендә балта осталарының эт кадере дә юк аның, Әбел-Гаяз улым. Хәзер шофер бул да, тракторист бул. Гандәлиф кияү дөрес әйтә: хәзер дөнья техника кулында. Эшләре пычрак — зато тамаклары тук. Малайларның берсен дә шул юлдан жибәреп булмады. Шуңа үкенәм. Балтага киттеләр. Син, улым, машинаны авызына бер алгансың икән — төшермә. Тапсын Сәйдәшев. Түлке што, эш дип, тиз генә егылып төшмә. Эш беркая да качмый ул. Тим более — колхоз эше. Аннары — колхоз гына димәгән бит. Әнә — заготзерно. Ә аңынчы синең белән минә бер эш чыгып тора...

— Нинди эш? — диде Гаяз.

Локман аңлатып бирде. Гаяз, эшеннән бигрәк, Нухның үзен сорады:

— Каян килгән кеше соң ул? Пароходта да шуның белән кайткан идем.

— Алайса, син аның юан Зәкиевын да күргәндерсең инде? «Уфада очрашып, бергә кайттык», дип торган иде Нух.

— Күрмичә! Бер каютада томаланып ят та...

— Шул Зәкиев, син юкта, бер елмы, артыгракмы, замдиректор заготзерно булып эшләгәние. Хәзер районда ашханә директоры икән. Шуның чорында килеп калдылар инде Нухлар. Зәкиев белән икесе дә бер районнан алар — Чакмагыштан, хәтта бер авылдан. Вообщем, заготзернода хәзер — күбрәге читтән килгән кеше. Элек безнең авыл белән Кырлач халкы гына иде. Аларын Сәйдәшев, әкрен-әкрен генә, кайтарып бетерә бара инде. Хәзер безнең Кавига кыжрап йөри...

— Ярый, анысы кирәкми, — диде Гаяз. — Син шуны әйт: ул Нухның эше күпмегә житәр?

— Теге осталары, бәбкә утыртып, гәрничкә тотынган булганнар. Ләкин кобагасын гына сугып чыкканнар. Стал бит, гәрнич тегелмәгән. Шул. Гәрнич теккәч, калган эшләрен беләсең инде. Бер унбиш-егерме көнлек эш бар инде анда.

— Ай-һай, унбиш-егерме көндә генә бетәр микән?

— Синең белән минем кебекләр бер айда бер өй житкезеп куя, — диде Локман коры гына. — Әлбәттә, тугызда барып биштә кайтсаң, ике ай да үтәр.

— Шулай да өйдәгеләр белән, Сәйдәшев агай белән сөйләшеп карамыйча килешмәс, — диде Гаяз.

— Бар әнә, сөйләшеп кара, — диде Локман. — Бәлкабзыйга санаторийга барырга да ярдәм итмәгәнсез икән, дип әйт. Сөләйман абзый гомере буе колхозда эшләде мәрхүм. Инәң колхозда эшләде. Таһиржан колхозда эшләп шулай булды. Бер путевка табып бирә алмадылар. Хәзер аны обязательно санаторий кебек жиргә жибәрергә кирәк. Өйдә ятса да — үзенә бер тәрбия кирәк. Акча каян аласың? Әтәң акча калдырган дисеңме әллә? Калдырган! Бер сандык ко ралы калды әнә...

Гаяз, алдындагы шулпага кашык та тыкмыйча, башын иеп чыгып китте. Холыкларына тикле абзыйныкына охшар икән, байткә[1], дип калды Локман.

Гаяз үзләренә кайтып керде.

— Бик озакладың, улым, — диде аңа әнисе.

— Әткәйнең кораллары кайда, инәй? — диде Гаяз.


— Әнә шул сандыкта.

— Шушындамы? — диде Гаяз һәм ишек төбендә торган сандык янына килеп тезләнде, ләкин капкачын тоткач, кинәт күңеле тулып, туктап калды.

Ул, армиягә киткәндә, үз гомерендә беренче кабат, әтисенең шыңшып-шыңшып елавын күреп гажәпкә калган иде. 41 нче елны Гаязның ике абыйсын, үләргә китсәләр дә, еламыйча сугышка озатып калган әтисе кире әйләнеп кайтырга киткән улын, Гаязны, нишләп шулай елап озатты икән?.. Март аенда әтисенең атна эчендә үлү хәбәрен алгач, шушы көн исенә төшеп, йөрәгендә дәвасыз сызлау калды. Төпчегемне дә күрә алмам инде дип, үзенең үләрен сизеп елаган икән, мәрхүм. Һәм шул чакта әтисенең, кул сырты белән күзен сөртә-сөртә, яр башында басып калуы менә кечкенә күз алдында, һәм кичә, пароходтан төшкәндә дә, яр өстендә әтисе торадыр төсле иде. Түшәк өстендә үлеп ятуын, тар ләхеткә тыгып куюларын үз күзләрең белән күрмәгәч, үлемгә дә күңел ышанмый икән... Ләкин әтисе урынына инде туфрагы басыла төшкән кабер калган да, менә бу сандык калган...

Гаяз иплән кенә сандыкны ачты. Кораллар аның яртысыннан күбрәк өлешен алып тора иде. Буйга гына тезелгән фуганоклар... йөзләре тимергә тиеп кайтарылмасын өчен агач ояларына тыгылган өтергеләр... Әтисенең кулы тию белән жан иңеп, гөлләр коя башлаган бу кораллар борчулы бер сагыш кичерәдер сыман иде. Нинди язмыш көтә бу ятимнәрне? Арыш капчыгымы әллә?..

[1] Русның батька (атакай) сүзеннән бозылган.



Гаяз янына Таһир килеп басты.

— Әткәй ничек салган булса, һәммәсе шул килеш тора.— диде ул.— Алмазы гына шкаф эчендә.

Гаяз дәшмәде, сандык эченә иелгән килеш тора бирде. Аннары, коралларга кул да тигезмәстән, сандыкны япты да тизләнгән җиреннән кузгалып, ишеккә юнәлде. Кая барып сугылырга, нәрсәгә барып тотынырга белмичә, болдыр читенә чыгып таянды. Тыш тулы кояш, тыш тулы нур, тик күңел генә әтисенең кабер туфрагыдай салкын, кояшсыз иде. Кайтыр җирләргә китмәдең шул, әткәй...

— Әллә күңелең болганып киттеме, улым?

Гаяз сискәнеп башын күтәрде: күзен каплаган юеш элпә аша, бик ерак итеп, кече капкадан кереп килүче Локманны күрде.

— Юк, — диде ул. — Күңел болганудан түгел. Болай гына.

— Болай гына булса ярый, — диде Локман һәм шундук: — Без синең белән икәү сөйләштек сөйләшүен. Нух янына чыгып керергә кирәк бит хәзер, — диде. — Кичә мин аңа үзеп кенә әйтмәгән идем. Иптәш тапмыйча торып, әйтеп булмый. Әйдә иртәнге сәгатьтә, аллага тапшырып, сөйләшеп кайтыйк.

— Арттан кумыйлардыр бит, төпчек абзый?

— Мине кумыйлар. Минем яшь чыккан...

— Өйдәгеләр белән сөйләшмичә булмый, — диде Гаяз.

— Сөйләшерсең әле. Башта тегенең белән сөйләшеп кайтыйк. Күтә булыр.

— Бер көн көткәннән кыегаймас, — диде Гаяз.

— Бүген дүшәмбе. Самый эш башлый торган көн. Иртәгә — чишәмбе белән чәршәмбедә эш башларга кушмыйлар.

— Өйдәгеләр белән сөйләшми булмый, — диде Гаяз.

Шунда өйдән Таһир килеп чыкты.

— Коймак суынып бетә инде, апай. Чәй эчеп алыр идең, — диде. Әдәп саклап, Локманны да чакырды. Локман кикереп:

— Рәхмәт, бер ашар җирем дә юк, — диде, ләкин шунда, башына икенче уй килеп, сүзен борды: — Керим әле, коймагын ашамасам да, чәен эчәрмен. Әллә нәстәсенә иртәдән бирле тамакка ут капкан шикелле йөрим. Сөйләшәсе сүз дә бар, — дип, иярен өйгә керде.

Сүзне Гаяз башлады. Локман да, кыек-мыек боргаламыйча, әйтәсен әйтеп бирде. Таһирны читләтеп, Кифая әбигә карады.

— Без Әбел-Гаяз белән сөйләштек. Инде сүз синеке, җиңгәй. Акча кирәм дип торганда, кесә авызын япмаска кирәк.

Бераз тынып тордылар. Самовар да, җавап көткәндәй, чыжылдавыннан туктап, Кифая әбигә текәлеп калгандай булды. Кифая әби Таһирга карады.

— Ничек булыр икән соң, улым?

Локманның курыкканы да Таһир иде. Хәзер бу, чукынып, аркылы төшә инде, дип уйлады ул.

Таһир, ашавыннан туктап, башын түбән иеп утыра иде. Күтәрелеп карамыйча гына:

— Бу ни эш бу, ә? — диде. — Кичә дә табынның бар ямен китәреп шул турыда сөйләшеп утырдыгыз. Эштән башка сөйләшер сүзегез юк мәллә?

— Әдәм баласы эш өчен яралган да, Таһирҗан улым, — диде Локман. — Рас шулай икән, аның телендә дә эш булырга тиеш. Аннан кире генә — аш. Мин менә Никулай заманыннан бирле эшлим...

«Тотына инде хәзер купецларда эшләвен сөйләргә», дип уйлады Таһир һәм коры гына:

— Син монда кабердәге Николай заманын чокып чыгарма,— диде.

— Хәзерге дә шул, Таһирҗан улым: эшләмәсәң, коммунистлар да ашатмый. Кем эшләми, шул ашамый дип кенә торалар. Сәйдәшев тә әнә ашка чакырмаган.

— Сәйдәшев — икенче чут. Сәйдәшевкә бүгеннән барса да сүзем юк. Колхоз эшенә чыкканнан кеше көлми. Колхозга самый эшчеләр кирәк вакыт. Әбел-Гаяз бүген армиядән кайтып, иртәгесен колхоз эшенә тотына икән — аның бер ояты да юк. Ә менә синең белән чыгып китсә — кешедән оят. Ни әйтерләр? Кунак итәрлек тә хәлләре юк икән, эшкә дә куштылар дип әйтерләрме? Алай гына дисәләр ярый ла...

— Шулай шул, — диде Кифая әби. — Кешедән оят...

— Кешедә безнең эшебез юк, — диде Локман. — Без кешегә зыян итмибез. Чакырсам икән Әбел-Гаязны берәрсенең өен барып сүтәргә! Ул чакта әйтер идең: кеше көләр, дияр идең. Мин бит аны өй салырга чакырам, кешегә файда итәргә.

— Ул бит Нухка файда да сиңа файда. Ә колхозга?

— Хәзер ул безнең колхоз түгел — Сәйдәшев колхозы. И син дә ике сүзнең берендә колхоз димә. Колхозны без аны син әйтмәсәң дә беләбез. Син менә миңа шуны әйт: колхозга файда итеп ни кырдың?..

— Мин өлгерә алмадым...

— Мин дә өлгерә алмадым, — диде Локман. — Алтмышка җиттем— өлгерә алмадым.

— Бәлки, йөзгә җиткәндә өлгерерсең.

Кифая әби түзмәде:

— Таһирҗан, әтәң урынына калган төпчек абзыең белән телләшеп утырмасаң иде, — диде.

Аның бу сүзе егылган кешене кыйнау өчен күсәк бирү белән бер булды. Локман инде, шул күсәк белән селтәнә-селтәнә, Таһир өстенә килә башлады.

— Син башың белән думайт итмисең, Таһирҗан. Башың белән думайт итсәң, колхоз дип авыз суларыңны корытып утырмас идең. Та-

залыгыңны кайда югалттың? Минем эштәме? Юк. Колхоз эшендә... Әбел-Гаяз эшли башлагач, знамо, колхоз сиңа ашлык бирүеннән дә туктар әле. Житте, инде Гаязлары карасын, дияр.

Таһир, эченә сыймас ачу белән:

— Син монда кереп, төпчек абзый, колхозны яманлап утырма, яме! — диде. — Әткәй төзегән колхоз ул!..

— Без дә төзедек аны, — диде Локман. — Тик без төзегәне юк хәзер. — Аннан ул, тавышсыз гына көлеп: — Абзыйның да кызыл чаклары бар иде, мәрхүмнең, — дип куйды.

Кинәт Таһир йөрәктәге бар булган канының беләкләренә сава башлавын тойды. Әгәр Локман урынында икенче берәү булса — яралы арсландай ташланыр да бугазын чәйнәр иде. Ләкин ярсу беләктән чыкмады, жыела гына башлаган күз яшедәй, тамакка килеп тыгылды. Шул хәлендә ул Локманга текәлеп калды. Локман тетрәнеп куйды: бу караш иртән үзе тавык суйган балта йөзедәй зәһәр иде. Әмма Таһир үзенең бирешә башлавын сизде: яшькә ике тапкыр, көчкә ун тапкыр өстен торган кан кардәшенә каршы тора алмый иде инде ул. Шулай да соңгы көчен жыеп:

— Әткәй колхоз өчен кан койган, шуңа кызыл булган! — диде һәм буылып ютәлләргә тотынды.

Ул биреште, аны жиңделәр, аны Локманнан алда чир жиңде. Ул өстәл яныннан торып, урынына барып ятты. Чир өстенә ни әнисенең, ни Гаязның яклап сүз әйтмәве аны рәнжеткән, аяктан еккан иде. Бер тазалыгың киткәч, үзеңнекеләр дә саңга сукмый икән, диде ул.

Инде Локман Таһирның ютәл өянәген гадәти хәлгә санап, аңа күз дә ташламастан, Гаязга карап дәвам итте:

— Менә шул, Әбел-Гаяз, үзең хәл ит. Дөньяны син көтәсе. Синең өстә үзең белән өч жан.

Гаяз уйга калды. Ул инде баядан бирле уйлый, аның башына бая төпчек абзыйларында утырганда ук уй төшкән иде. Узган ел, совхозда эшләгәндә, ике-өч тапкыр акча жибәрүен исәпкә алмаганда, ул әле дөнья көтүнең ни икәнен дә белмәде. Дөньяны картайганчы әтисе көтте. Хәзер ул көтәргә тиеш... Әллә юкса чынлап та төпчек абзый белән эшләп алыргамы? — диде ул күңеленнән. Сәйдәшев бүгеннән генә кыстап бармый бит. Берәр атна ял ит әле, диде. Берәр атнасын ял исәбенә эшләсәм, икенче атнасын өстәп сорармын. Аңлар. Аңламас кеше түгел. Аннары төпчек абзыйсы, әтисеннән кала, тирә-якта беренче остадан санала иде, аның янында ун-унбиш көн эшләп алуның файдасыннан башка нәрсәсе булмаска тиеш.

Гаяз Таһирга карады. Абыйсы ике кулын баш астына салып яткан да күзләрен түшәмгә текәгән, гүяки аның хәзер бернәрсәгә катнашы юк, табындагылар сүзе, таза кешеләр сүзе, аны борчымый иде. «Да, диде Гаяз, санаторийга жибәрергә кирәк. Файдасы булмас та бәлки, шулай да жибәрергә кирәк. Барып кайтса, савыкмаса да күңеле булыр»...

— Ярар, — диде Гаяз. — Ни булса ул булыр...

— Жә, аш кайтарыйк, жиңгәй, — Локман, амин тоткач, түр стенадагы сәгатькә карады. — Унбер тулып килә икән инде. Булмаса кузгалыйк, Әбел-Гаяз.

Гаяз да табыннан торды, син теләмәгәнне эшләргә жыенганым өчен гафу ит дигәндәй, бөтен гәүдәсе белән абыйсы ягына борылды. Таһир һаман да шул килеш, түшәмгә караган килеш, тик кенә ята иде. Моннан дүрт ел элек кенә чәчрәп торган тазалык нуры, йөзенә бер тибеп, очып киткән кебек, шул тибүдән битләре эчкә батып, анда күксел-авыр күләгә генә ятып калган иде. Гаязның кинәт коты алынып, йөрәге жу итеп китте. Һәм ул тиз генә, хәтта кабаланып, абыйсының күзләренә

карады. Ләкин бу күзләрдә — чыкмас җан, бетмәс гомер ялтырап тора иде.

Гаяз әкрен генә абыйсына дәште:

— Бәлкабзый, син ачуланма. Мин син сөйләгәннәрне аңламаска бала түгел. Барысын да аңлыйм. Ну бит, мин күп акча белән кайтмадым. Ничек яшәп китәрбез соң? Ярый, яшәп тә китәрбез ди, анысыннан курыкмыйм. Ничек тә юнәербез... Ә менә син? Сиңа тәрбия кирәк бит... Ачуланмыйсыңмы?

Таһир телдән калган кебек ята бирде.

— Бәлкабзый, нигә эндәшмисең? Нигә йөрәгемә ут саласың? Болай да дөрләп китәргә генә тора бит!..

Таһирның нечкә күңеле озакка чыдамады. Ул, очлаеп торган йөзен борып, энесенең күзләренә карады.

— Мин сиңа ачуланмыйм, апай. Кайтуыңны өзелердәй булып көттем бит мин. Сагындырдың. Тик мин синең яман атың чыгуын теләмим. Син безнең нәселнең мактанычы булырга тиеш. И нәрсә генә эшләсәң дә, күңелеңнән әткәй белән киңәш тот: синең кылган эшләрең өчен каберендә рәнҗеп ятмый микән дип уйла...

— Әткәйне оныту юк анысы, бәлкабзый, — диде Гаяз һәм абыйсының янган йөрәген тагын да басар өчен сабыр гына сөйләнеп алды: — Барып карыйм әле. Эшен күрим. Ниндидер бит эше? Тиз генә бетәрлекме, түгелме? Тиз генә бетәрлек булмаса — лучше тотынмау хәер.

Аннары ул ишек төбенә килде. Әтисеннән калган кораллар сандыгы уң як стена буенда тора иде. Аңа карау белән кинәт Гаяз икеләнеп калды: «Әллә бармаска микән соң?» Ләкин шундук сандыктан күзен кире алды. Хәзер үк чыгып китмәсәм, башка китә дә алмам, диде ул һәм ашыгып ишеккә юнәлде.

## Бишенче бүлек

Локман лапастан ишкәкләрне алып чыккан, иңбашына күтәреп, Гаязны көтеп тора иде. Кичәгечә, бәрәңге бакчасын үтеп, сөйләшмичә көймәгә утырдылар. Тез тиңентен су эчендә торган карт өянкеләр турыннан үткәндә Гаязның исенә малай чаклары килеп төште. Малай чакларында алар, бишәр-алтышар көймә җыелып, менә шушы өянкеләр арасыннан бәрелми-сугылмый йөрергә өйрәнәләр, агач кәүсәләренә ышыклана-ышыклана, дингез сугышы уйнарлар иде. Гаяз як-ягына каранып алды — агачлар арасында бер көймә дә юк иде. «Хәзер балачага без уйнаган уеннарны уйнамый микәнни?» дип, Гаяз бик гаҗәпләнде. Ул киткәндә Миңеште тамагы таррак, кызыл яр биредәрәк иде. Хәзер ераклашкан, арткарак чигенгән, күкрәген тагын да ача биреп, ташкынга каршы калкан шикелле үрә баскан. Яр читендә — быел ишелми калган, ләкин киләсе ел ишелеп төшәчәк зур-зур кәсләр асылынып, агач тамырлары тырпаеп тора иде.

— Дүрт ел эчендә су күпме җирне ашаган, ә? — диде Гаяз.

— Дүрт ел нәстә ул? Менә син кырык ел дип әйт, — дип Локман телен шартлатып куйды. — Вәт менә кырык ел эчендә ашады! Ничә гектар җир, чәйгә салган шикәр сыман, суга эреп акты? Груздевның амбарлары торган җирдә хәзер әнә Агыйдел чажлап ага. Грунт йомшак. Груздев урынны сайлый белмәгән.

Гаяз күтәрелеп заготзерногә карады.

Камада һәм Агыйделдә берничә икмәк җыю пункты һәм бер пароход тоткан купец Иван Груздев 1912 нче елда Иерусалимга хаҗга китә, шул изге һәм эссе җирдә үлеп кала. Ике улының берсе дә эшне әтиләре сыман йөртә белми; аннары герман сугышы башлана, әтиләре гомер буе җыйган малны ике малай биш ел эчендә туздырып, акча эшләрен тәмам

чуалтып бетерәләр. Ашлыктан күбенеп-бүселеп торган амбарлар, урамдай бушап, бер очыннан икенче очына шар сугып уйнарлык булып калалар. Шунда яшь Груздевлар, яшен сугып икмәк янды дигән сылтау белән страховой акчасы алыр өчен, бер-ике амбарга ут төртергә булалар. Һәм яшьнәп яңгыр яуган бер төнне янәшә торган ике амбарның берсенә ут каба. Яңгыр таң атуны да көтмичә туктый, әмма яңгын туктамый, беренче амбардан икенчесенә, икенчесеннән өченчесенә күчә. Ул арада җил бөтенләй кире якка борыла, җае чыкканда әйдә монысы да янсын инде дигән сыман, Агыйделгә карап торган ике катлы чардаклы йортка да бер көлтә очкын илтеп ташлый. Ике авыл халкы уянып килгәндә инде ут — сүндерерлек кенә булмый. Груздев хезмәтчеләре чаң сугып тыз-быз килеп йөрсә дә, халык сикереп төшми. Дүрт ел буена сузылган мәгънәсез сугыш җәфасын чиккән, шундый ук мәгънәсез, шатлыксыз тормыш иткән халык: «Ходаның рәхмәте!» дип, бер генә көнен булса да шушы утка шатланып, тамаша итеп үткәрә.

Груздевлар вакытлы хөкүмәттән бер тиен дә акча ала алмыйлар: Октябрь революциясе булып, вакытлы хөкүмәте дә, Груздевлары да, ташкын уйган яр кебек, юкка чыга.

1940 нчы елга житкәндә Груздевның эчкәрерәк салынган биш-алты өе генә калган иде, ә яр буендагы амбарлары, күчерә-күчерә, бәләкәйләтә-бәләкәйләтә, юкка чыгып бетте диярлек; алар биләп торган җир дә су астында калды. Аңысын гына да түгел, Совет власте чыккач, заготзернонын үзенә бирелгән 15 гектар җирне дә бер яктан Агыйдел, икенче яктан Миңеште кабып-кабып йота башлаган иде. Ләкин бу җир озак еллар буена буш торып, илле-алтмыш чакрымдагы авыллардан килгән олау атларының ял итү урыны, чи игенне кояшта киптереп яту урыны булып торды.

Соңгы дүрт ел эчендә заготзерноны яңабаштан төзеп куйганнар. Бөтен склад һәм башняларны җир асты юллары белән тоташтырып, бөтен эшләрне иң соңгы техника белән өр-яңадан корып җибәргәннәр.

Боларның бөтенесе дә Гаяз армиядә чакта эшләнгән эшләр иде. Локман аның ни уйлаганын сизеп:

— Заготзерно үсте! — диде.

— Танырлык та түгел шул! — диде Гаяз.

Локман көймәне яр буйлап түбәнрәк алып китте һәм су читендә торган ак мунча янына китереп туктатты. Мунча стенасына биш-алты көймә бәйләрлек боҗра кагып куелган иде — көймәне шуңа бәйләделәр дә урамга менделәр.

— Боларын да бер-ике ел эчендә тау башына күчереп бетерәләр инде, — диде Локман. — Бу якка тагын да заготзерно киңәячәк. Бөтен тирә-як игенен йотып тора бит. Склад житкерә алмыйлар. Узган көз ашлыкны, складларга сыймагач, ачык һавага өйделәр. Ел яңгырлы булды. 600 тонна ашлык янды шунда. Килмәгән комиссия калмады. Шагалиевны йөртмәгән җир калмады. Тегендә бюро, монда бюро. Уфасына өч-дүрт кабат чакырып алдылар. Шагалиев күзен дә йоммый икән: «Склад юк, склад салырга территория юк, бирегез территория», дип әйтә икән. Обком тотынгач, Совет Министр тотынгач, Сәйдәшев җирне тиз бирде. Без барасы кеше йортын шунда сала инде.

Заготзернога имәнлек белән басу арасындагы иген үсми торган җирне кисеп биргәннәр. Инде булачак урамны да сызып-билгеләп куйганнар: кешеләрнең үз йортлары имәнлеккә аяк сузып утырачак, ә заготзерно үзе каршы якка салачак икән: инде астан берсен менгезеп салганнар, икенчесен күтәреп яталар иде. Имәнлек буенда дүрт-биш бура тезелеп утырса да, әлеге берсе генә — Нухныкы гына күтәрелгән иде.

Локман Гаязның беләгеннән тотты.

— Туктале, Әбел-Гаяз, — диде ул. — Башта үзебез сөйләшеп алыйк: эш хакы турында сүз чыгу белән, син ул биргән хакка ризалашма, юк

кына дип әйт, булмый диген. Нухның көймәсе самый комга терәлгән вакыт. Ул безнең кулда. Чабаланып кына карасын, күршесенә чыктык киттек: каян осталар табарга белми утыра.

Өйдәге сөйләшүдән соң, бигрәк тә абыйсының бу эшкә рәнҗеп кенә ризалашуыннан соң, бүгенге җылы, кояшлы көндә Гаязның күңел күгеннән яумый гына үтә торган, төтендәй коры болыт каплап алган иде. Әле, төпчек абзыйсы «ризалашма» дип әйткәч, капыл җил исеп, әлеге болыт кузгалып киткәндәй булды — күңел күгенең дә бер чите йөзен күрсәтте. Булды! Димәк, ул Нух белән, кулыннан килгән кадәр, килешмәү ягын каерачак. «Ичмасам, намусыма авырлык килмәс. Ичмасам, бәлкабзый янына килешә алмадык дип кайтырмын», — диде ул.

Нухлар торган өй буйга да, иңгә дә алтышар почмаклы иде һәм, Гаяз белә-белгәннән бирле, аста, тау итәгендә утыра иде һәм, Гаяз белә-белгәннән бирле, анда ике семья тора иде. Хәзер аның урта ишекләрен томалап дүрт квартир ясаганнар. Шуның өч тәрәзәсе дә көнчыгышка, иманлеккә караган иң зур ягын Нух семьясына биргәннәр.

Гаязлар кергәндә, кече якта Нухның әнисе чәй эчеп утыра иде.

— Ай алла! — диде ул ютәлле тавыш белән. Һәм алдында торган конфетны тиз генә савыты-ние белән җыеп куйды.

Мич артындагы караңгы бүлмәдән авыру тавышы ишетелде:

— Кем бар анда?

— Осталар килде.

— Кая, торгыз әле мине. Тот әле беләгемнән, төшим.

— Кыл кыймылдатырлык та хәлем юк әле үземнең дә, җә икебез бергә егылып китәрбез. Бүген тагын баш өянәгем купты, — диде ана әлеге карчык һәм, ярым пышылдап, Локманга сөйли башлады: — Сиңа гына әйтәм, Локман: исенә һич чыдарлык түгел. Кыш буе җәфа чиктек. Ике аягы гөбе кебек шеш, ташка үлчим. Гомер буе бүсере тотып интектергән иде. Хәзер шул бүсере дә калкып чыкты. Әйтсәм дә ышанмассың, менә шушы комган чаклы, ташка үлчим, — дип, ул җиз тас эчендә утырган калай комганга күрсәтте.

Аның сүзен карты ишетеп ята иде. Ул тавышын беркадәр суза биреп карчыгына кычкырды.

— Сиңа әйтәм!.. Кортка! Минем чирем аларга нигә кирәк? Утырыгыз дип әйтер идең, алла бәндәсе...

— И алла! Утырыгыз дип тә әйтми торам икән, — диде карчык шунда. — Уңсызланып беттем инде шул карт белән.

Локман, ишек урынына эленгән пәрдәне ачып, мич артына башын тыкты.

— Нихәл, Сәмигулла абзый? Хәлең ничек?

— Әйбәт булыр иде дә, Локман, шул кортка бит — кергән бер кешегә чиремне сөйли. Гомер буена авызында гел тузга язмаган сүз булды. Гомер буе акыл өйрәттем — кермәде. Шулар гына картайтты инде мине.

— Була инде ул алай гына. Фаягәл җиңгәйгә дә авыр инде. — Ул ишектән башын алды. — Кая соң Нух?

— Хәзер кайтып җитәр, — диде Фаягөл кортка. — Килсәләр китмәсеннәр, төшеп кенә менәм дип китте.

Чынлап та, ул шулай дип әйтүгә, өйалдында дөп-дөп баскан аяк тавышы ишетелде, һәм Нух кайтып керде.

— Осталар да килгән икән, — диде ул.

— Килдек әле, — диде Локман.

Нух башта, яктыдан кергәнгә сәбәпле, Гаязны танымый торды, күзе караңгыга ияләшү белән танып алды.

— Һей-й! Синмени әле бу, апай! — дип Гаязга кул бирде. — Танымый да торам тагын. Мин аны үзем алып кайттым бит, Локман абзый.

Ул елмайды — ике якка үсеп торган казык тешләре ялтырап китте.

«Тешләренә кадәр әнисенә охшар икән!» дип уйлап куйды Гаяз.

Ләкин Нух, җәелгән авызын шундук җыеп: «Бу собака алдында әллә ниләр такылдап ташламаган булсак ярый инде», дип куркып куйды. Шулай да көр тавыш белән аларны зур якка чакырды.

— Әүвәл эшеңне чыгып карыйк, — диде Локман.

— Алай итсәк тә ярый, — диде Нух һәм, чыгып киткәч кире кереп, әнисенә табын әзерләргә кушты.

Нухның йорты бераз эчкәрәк кертеп, урамга буй күтәреп куелган иде. Инде бәпкәләрен утыртып, кәрнизгә тотынган булганнар, ләкин кобага сузып кагудан үтә алмаганнар. Гаяз, бәпкәләренә карап: «Бик текә иткәннәр, такта яптыра микәнни?» дип куйды.

Локман инде карыйсын карап беткән, хәтта сорыйсы хакын, күпме төшәсенә хәтле исәпләп, күңеленә беркетеп куйган иде. Ул әле эшне үзе карарга түгел, Гаязга күрсәтергә генә чыкты.

— Осталарыңның берәр хәбәре юкмы? — диде ул сүз башлау өчен.

— Суд юк әле, ябулы яталар, — диде Нух. — Йөз егерме сумны алдылар да, хәзер әнә, бар сорап кара — алар белән бергә үзеңне гаепләп куюлары бар.

Локман эченнән: «Ай-һай, тоттырдың микән?» дип уйлап алды.

— Кичә, күңелең төшмәсен дип, әйтмәгән идем, Нух, хәзер әйтим инде, — диде ул. — Менәвыннан икегез дә түшәмне карагыз әле. Күрәсезме, ничек кысканнар: такта араларыннан пычкы гына йөрткәннәр — такта читләрен пычкы ничек талаган, ә? Иске чабата кебек чачакланып тора! Бүтәнгә бик башлы соң бит син, Нух апай. Моңа нишләп башың җитмәде? Закрой тарттырырга кирәк иде бит!

Нух, алдануын исенә төшергән Локман картка ачуы килеп, әдәпсез бер сүз әйтте һәм:

— Осталары да шуның кебек иде аның, — дип өстәп куйды.

— Хәзер аларның барысы да шуның кебек, апай, элгәреге урыс осталары юк шул инде хәзер. Менә алар эшли торган иде, байткә! Әл-ләл-ләл-лә!.. Коеп кына куялар иде! Ул корал-инструментларын күрсәгез, ушың китәр иде, дурак! Ә хәзергеләрнең ние бар? Балтасы да пычкысы. Алары да туң тимер. Шуларны тота да хәзерге «оста», агачташны аннан талап, моннан талап, өй салып йөри. Кала җирендә ишшү дә җиңел эшлиләр: бүлмәме, түшәмме, җыен эшкә ярамаган кыртыш такталарын сугып чыгалар да шикатурлап тик куялар.

Локман, теле белән осталар турында сөйләсә дә, күңеле белән инде бик еракка киткән, үзе күреп-белеп калган байлар заманына ук кереп чумган иде: аның күз алдына купец Груздевларда ун яшеннән батрак булып эшләве килеп басты. Инде боларның барысы да үткән-беткән, юкка чыккан, һәм Локман карт, акылы җитмәс хәлдә: «Бар иде дөньясын шаулатып яшәүчеләр...» дип куйды. Хәзерге авыл кешесенең иң хәллесе салдыра торган шушы алты почмаклы өйгә карап, баш селкеп торды.

Шулай да ул, йөрәкләрен җилкетеп, үткәнгә чапкан күңелен тиз арада йөгәнләп, бүгенге көнгә борып кайтарды — ә бүгенге көндә аңа акча кирәк иде. Акча китерә торган эшнең дә, акча бирә торган кешенең дә үзе белән янәшә генә торуын ул белә, тик, аз әләгеп куймасын дип, кулын сузарга гына ашыкмый иде. Һәм ул, имән бармагы белән чиртепчиртеп җибәргәндәй, мыегының башта бер, аннан икенче очын күтәртеп куйды.

— Хак күтәрәсе килеп әйтүдән түгел, Нух апай. Болай әйтәм: кеше башлаган эшне күңел салып эшләп китүе бик авыр ул. Тегесе дә синеңчә түгел, монысы да...

— Башта ук үзеңне чакырган идем бит, Локман абзый. Килмәгән булдың бит. Үзең башлаган булыр идең...

— Шулай, апай. Үзең башлаганны үзең бетерүгә ни житә! Кеше башлаган эшне аны беребез дә яратмый. Түшәмне әйттем. Инде бәпкәләргә карагыз. Калай түбәгә разве шулай текә утырталар? Значит дигәндәй, бәпкәләрне яткыза төшәргә кирәк. Чыктымы син кәтмәгән эш?

Локман әйткән һәр сүз туп-туры Нухның нервысына барып кадала иде, ахырда Нух үзен энә йоткан эт кебек сизә башлады һәм түземлеге бетеп, яңак сөяген уйнатып алды. Ләкин ул хәзер «бу карт төлкегә» берни дә әйтә алмый, чөнки ул салынып бетмәгән йорты-ние белән аның кулында иде. Шуңа күрә ачуын йотып, ялагай тавыш белән әйтергә тырышты:

— Жә, Локман абзый, эшне күрдегез, нәрсәсенә монда торабыз инде? Өйгә кереп сөйләшик тә кулга кул сугышыйк булмаса. Әллә нәрсәсенә кулы да, тамагы да кычыта башлады.

— Мин күрү генә житми бит әле, апай, — дип, Локман карт Гаязга карады. — Менә, үз күзең белән күрдең инде, улым. Ничек, тотынырлыкмы?

— Белмим шул, — диде Гаяз.

Кабат өйгә керделәр. Олы яктагы өстәлгә инде, батырдай күкрәк киереп, биле нәзек, жилкәсе киң самовар менеп баскан; өстәл уртасындагы зур сай тәлинкәгә байлар телеме дип аталган юка гына телемнәр өелгән; шуның янында ук өлеш тәлинкәсе, анысына башлы суган туралган, ә кыяклы суганны турамыйча гына, тәлинкә читенә куйганнар, аның ямь-яшел очы ашъяулык өстенә сузылып төшкән иде. Ит жамаягында, ике ботын өскә сузып, бөтен бер тавык ята иде. Нух, кулын юып өстәлгә утыру белән, шул тавыкны ботарлап ташлады һәм, «килешсәк — ашарсыз» дигәндәй, сыңар күзе белән башта Локманга, аннан Гаязга карап алды.

Фаягөл кортка өч пар чынаяк, өч стакан алып керде һәм бу якта иркенләп утырырга жай эзләп:

— Чәйне хәзер ук ясаргамы? — дип сорады.

— Майны алып кереп куй да — чәен үзебез ясарбыз, — дип, Нух әнисен чыгарып жибәрү ягын карады.

Шул вакыт кече яктан Сәмигулла картның авыру тавышы ишетелде:

— Нух, үзегезнең янга чыгарып утырт әле мине дә...

Нух, тавыш килгән якка карап:

— Кычкырып ятмале, пажалыста! — диде. — Ишетәлми калам дип йөрәге яна инде аның.

— Ничек соң, бер дә хәлләнүгә таба бармыймыни? — дип сорады Локман.

— Юк. Ни бу таба, ни теге таба түгел. Аяклары йөрми.

Карт турында сөйләүләрен ишеткәч, Фаягөл кортка да чыгып барган жиреннән туктап кире килде, өстәге ике казык тешен ныграк ачып, карты хакында тәмләбрәк сөйләргә жыенды. Ләкин Нух аңа ирек бирмәде.

— Бар әле, инәкәй, бар! Янында утырып тор. Ишекне ябып куй, — диде.

Әнисе чыгып киткәч тә, әллә карават астыннан, әллә өстәл астыннан үрелеп кенә бер «столичный» тартып чыгарды, үртәлеп ача башлады.

— Сабыр ит, апай, — диде аңа Локман. — Син бездән сүз көтәсеңдер.

— Әйе шул, — диде Нух.

— Түшәмне кертмичә, дүрт ярым, — диде Локман. — Түшәмне кабат, закрой тартып жәйдерергә дисәң — тагын илле сом. Ике тапкыр ашау — синнән.

— Ну, анысы инде... анысы инде аның...

— Түгел, апай, — диде Локман. — Дөрес, безнең татар кайда да останы ашата анысы. Шулай да ашау чутында да алдан сөйләшеп кую кирәк.

Нух, башын иеп, бик озак утырды, ахырда телгә килеп:

— Син мине егып суйма инде, Локман абзый, — диде.

— Синекен ишетеп карыйк, алай булгач, — диде Локман.

— Өч ярым, — диде Нух. — Нык бәя бирәм, Локман абзый.

Аның тавышы да бәясе шикелле үк нык иде.

Гаязның эченә шатлык йөгерде. Болай булгач, килешә алмыйлар, дип уйлады ул. Локман, алдан сөйләшкәнчә, сүз көтеп аңа карады.

— Мондый хак белән сөйләшеп торуның да мәгънәсе юк, төпчек абзый, — диде Гаяз.

Алар өчесе өстәлнең өч ягында утыралар иде. Гаязны Нух, моның белән сөйләшәсе юк дип, үзенең күзсез ягына утырткан иде. Ләкин Локманның җавап көтеп Гаязга каравы, ә Гаязның судья кебек хәлиткеч сүз әйтүе Нух өчен бөтенләй уйламаган яктан, күзсез ягыннан, китереп сугу белән бер булды. Ул тагын шиккә төште. «Бу собака тәки нәрсәдер белгән кебек сөйләшә. Әллә чынлап та моның алдында исерек баштан түбә калаен лыгырдап ташладыкмы?» дип, пошаланып уйлый башлады һәм шундук дүрт йөзгә менде.

— Юк, — диде Гаяз. — Төпчек абзый тиярен генә сорады.

Нух гәүдәсе белән аның ягына борылды. Шикләнүе һаман арта барып, «Калайны гына ычкындырмаган булсак ярар иде!» дип, тәмам аптырауга төште. Шушы минутта Гаяз аның күрәлмәс дошманына әйләнде. Шулай да, осталар белән ике арадагы мөнәсәбәтне кулыннан килгән кадәр кискенләштермәс өчен, дусларча әйтте:

— Сөйләшү болай булмый бит инде, Гаяз апай. Мин мендем — инде сез дә төшегез.

Аның сүзе җавапсыз калды. Гаяз әйтәсен әйткән, ә Локман Нухның тагын да бераз менүен көтеп утыра иде.

Ахырда Нух бер Гаязга, бер Локманга карап торды да кулын селтәде.

— Ярар, сезнеңчә булсын: дүрт йөз илле!

Аның теленә усал һәм төртмә сүзләр килде килүен, ләкин әйтмәде, «Илле сомга калган көн юк әле!» дип, бая ачмый куйган шешәне ачты, бер нәрсә булмаган шикелле, осталарны сыйлый башлады.

— Әнә, артыннан яңа суган кабыгыз.

— Иске корсак, яңа аш, зәңгелә кач, идел кич, тазалык кил, байлык кил, — дип, Локман абзый авызына ямь-яшел суган кыягын бөкләп тыкты. — Әй-яй шәп икән! Кеше яңа утыртканда, каян чыкты әле бу, Нух?

— Чыга инде ул, абзый. Әле кыяры да бар иде. Малайлар ашап бетергән. Ярар, тагын китергәч, авыз итәрсез әле.

Нухның тиз генә килешүенә тәмам аптырап калган Гаяз да төпчек абзыйсы артыннан суганга үрелде. Ләкин шул вакыт кече якта нәрсәдер дөп итеп идәнгә килеп төште, шул ук минутта Фаягөл кортка ишектән башын тыкты.

— Атаң егылып төште!

Нух, берни булмагандай, Локман алдында торган стаканга үрелде.

— Кая, тагын берне салыйм әле, Локман абзый.

Сәмигулла карт ыңгырашып куйды:

— Ы-ыһ!..

Ишек авызында торган Фаягөл кортка кинәт, гомер иткән картын кызганып:

— Как идәннәрдә җан бирә бит, күтәрепләр салыгызчы әле урынына! — дип өзгәләнеп әйтте. Ул бик каты курыккан, буынсыз-хәлсез калган, хәтта битенең җыерчыкларына кадәр дерелди иде.

Алдан Нухның чыгуын көткән Локман:

— Ярамас... чынлап та... әйдәгез... — дип өстәл яныннан торды.

Гаяз да тиз генә урыныннан кузгалды. Нух үз стаканына шобырдатып аракы агызды да үртәлеп авызына китерде.

Сәмигулла карт идәнгә капланып килеп төшкән, әле кабыргасына әйләнергә маташып ята иде. Маңгай тиресе ярылып, сызылып кына кан агып чыккан, хәзер инде кызгылт идән буявына тамып тора иде.

— Әйдә, улым, син гәүдә ягыннан тот, ике кулыңны да астан ал, — диде Локман Гаязга, үзе, бүрәнәгә тотынган шикелле, картның шешенгән аякларын ике куллап күтәреп алды. Нух та чыгып, килеп тотынган булды.

— Рәхмәт, улым, — диде аңа этисе.

— Дурака валяйт итеп ятма, яме! — диде аңа кызмача улы. — Тапкан куркытыр әмәл! Егылып төшеп куркыта, имеш!

Аннары ул әле булса ис җыялмый торган әнисенә ыжгырды:

— Мин бит синң янында тор дидем. Безнең сүз сиңа нигә кирәк? Ишек төбенә килеп тыңламасаң...

Сәмигулла карт өмет өзеп улыннан күзен алды.

— Ы-ыһ, алла! Үлепләр булмый бит!..

Ул улын бик ярата иде һәм бая, өй чаклы өй сөйләшкәндә, улым үзләре янына мине дә алып чыгар, урындыкта утыра алмам, диванга утыртып куяр, миннән киңәш сорар дип уйлаган иде. Ләкин улы чыгып алмады, җитмәсә кеше алдында: «Кычкырып ятмале!» дип җикерде. Шуннан ул: «Мин булмагач, саранланыр, сөйләшә алмаслар, Локман кебек останы кулдан җибәрер», дип, ястыгыннан сәке читенә шуып килде, ләкин аягына баса алмады, капланып төште.

— Астын алыштырырга кирәк иде чүдеки, — диде Локман.

Нух инде олы яктан аңа дәште:

— Әйдәгез, Локман абзый, саласын салып, кабасын кабып бетерик булмаса!..

Локманның да, Гаязның да өстәлгә кабат кереп утырасылары килмәде: бердән, табынның яме качкан; икенчедән, йорт сөйләшенгән, эше беткән иде. Шуңа алар тизрәк чыгып китү ягын карадылар.

Аларны Нух озата чыкты.

— Ярый, Нух, иртәгә аллага тапшырып тотынырбыз да, — диде Локман.

Гаяз үзенең иртәгә килә алмавын, райүзәккә барып хәрби учетка кереп кайтырга уйлавын әйтте. Бер эшкә тотынсаң — вакыты да тимәячәк, диде. Шуннан — Гаяз берсекөнгә килергә, ә Локман бер кеше эшли алырлык эшләрне иртәгә үк башларга булды.

Инде киткәндә генә Локман Нухка әкрен генә әйтте:

— Карале, Нух апай, бик кыен булса да, син атаң картка хөрмәтләрәк йөзеңне күрсәт инде. Яшәгән кадәрле яшәмәс. Каның күрдем, бик тазадан түгел, кәфенлек-мазарын әзерләп торганда да ярар... Ийе...

— Алары әзер лә аның...

— Әзер булуы яхшы, — диде Локман. — Әдәм баласын җиргә дә шәрә күмеп булмый бит...

Алар китеп бардылар.

— Тфү! Шул кешегә йорт салып бирергә йөр инде, — диде Гаяз.

— Син аның кешесенә карама, улым. Эшенә кара. Кешесенә төкерсәң дә, эшенә төкермә. Эшнең хуҗасы юк аның: Нухка эшләдең ни, чуртка эшләдең ни... Акча гына бирсеннәр. — Аннары ул: — Кавида йомышым бар иде, — дип, заготзерно территориясенә юнәлде.

## Алтынчы бүлек

Гаяз, бер үзе генә калгач, юксынып, Халидәне исенә төшерде. Аның күңелендә Халидә таң атканда сызылып киткән бер нур булып, бала чакларын бизәп торган бер ямь булып саклана иде. Йодрык хәтле генә җилкәләренә сугыш китереп өйгән мохтаҗлыклар, үскәч кенә аңлашыла торган хәсрәтләр инде онытылып, искә алганда гына үзәкне өзеп китсә дә, бу нур һаман сүнми, еллар үткән саен отыры көчәя барып, күңелгә моңсу бер сагыш биреп тора иде.

Гаяз, бала вакытта Халидә белән йөргән җирләреннән урап кайтырга булып, «Галәү тегермәне» ягына борылды. Бу як ярдан, һәр көн иртә белән, Кырлач көтүе үтә, шунлыктан буй-буй булып сукмак сузылып киткән иде. Гаяз шуларның берсенә төшеп, авылның югары очына таба атлады. Бу якта агач та үсми, шәп-шәрә булып сукмаклар гына ярылып ята иде. Шушы шәрәлек Гаяз күңеленә дә үтеп керде: бушлык, юксыну көчәя барып, ул инде моннан китүенә үкенә башлады. «Мәңгегә югалган нәрсәләрне нигә кабат искә төшерергә кирәк?» дип кабатлый-кабатлый, гүя ул тау битләп түгел, ә тоташ сагыш өстеннән бара иде. Ниһаять, ул тегермән урынына килеп төште, күңелендә күпме эз уйган нәрсәләрнең инде эзе дә юклыгына шаккатып, күзе бер нәрсә аермас, үзенең барлыгын тоймас дәрәҗәгә җиткәнче басып карап торды. Тегермән урынында ямь-яшел кычыткан үсеп утыра. Арбалы ат иркен чыгып йөргән буа калдыгыннан нык булсын өчен кат-кат түшәлгән тал, карамалар гына әле булса тырпаешып торалар иде; шулар гына биредә буа булганлыгын, шунда Гаяз белән Халидәнең бала чагы үткәнлеген сөйләүче гадел шаһитлар иде. Шунда Гаяз буа тулы суның, кәвестән агып килеп, куласа канатларына тулуын, аннары туктаусыз гөжләп, күбекләнеп түгелә баруын күз алдына китерде, шул ямьле гөжләүне чын-чынлап ишетә башлагандай булды, шунда кинәт Халидәнең, кәвестән сөзелеп кенә аккан судай, саф тавыш белән: «Га-я-аз!» дип кычкырган тавышын ишеткәндәй булды. Аңа шулай Халидә кычкырыр иде, тавышы артыннан үзе дә килеп чыгар иде...

Гаяз армиягә китәсе елны абыйсы кайтып төште. Таһир армиядә чакта кызлар белән хат язышып торса да, кайту белән тотып кына йөреп-яратып китәр кызы юк иде. Таһир да буйга Гаяз кебек үк озын, таза, йөзгә-биткә аңардан да матур — хәтта кызлар чибәрлеге бар иде. Чем-кара күз, кап-кара каш, куе-озын керфекләр, көлмәгәндә дә елмаеп балкып торган йөз — бөтен кыяфәтендә, бөтен кыланышында кызларның үзәкләрен өзеп ала, ихтыярсыз итә торган бер көч бар иде. Ул кайткач, кызлар бер-берсеннән көнләшә, дуслар дустыннан аерылыша башладылар. Ләкин Таһир аларның берсенә дә әйләнеп карамады: кайтуына үсеп торган Халидәне күрү белән, аңа гашыйк булды.

Гаязның армиягә китәргә каралып йөргән чагы иде. Августның якты һәм салкынча киче иде. Гаяз белән Таһир, клубтан кайтып, лапас кыегы астына печәнгә менеп яттылар.

«Мин кайттым, ул китә, сөйләшеп калыйм ди торгандыр инде», дип уйлады Гаяз. Ләкин абыйсы сөйләшми дә, йокламый да — тик әйләнгәләп ята иде. Ахырда ул, Гаязга борылмыйча гына, сүз башлады:

— Апай, без бүген я дошманлашабыз, я дус булып калабыз...

Абыйсының мондый сүзе Гаязга бик сәер тоелды, һәм ул әллә берәр гаеп эшләдемме дигәндәй, сорап куйды:

— Нигә алай дисең, бәлкабзый?

— Мин... мин бит... Халидәне яратам... — диде Таһир һәм кинәт кызып-кызып сөйләргә тотынды: — Беләм, син аны яратасыңдыр, апай. Андый кызны яратмау мөмкин түгел. Ләкин синең өч-дүрт ел хезмәт итеп кайтасың бар. Өч-дүрт ел эчендә сиңа менә дигән кызлар үсеп торачак. Мин киткәндә, Халидә дә бәләкәй генә кыз иде. Ә хәзер?.. Без —

ике туган. Кызлар өчен синең белән чит-ят кешеләр кебек бер дә сөйләшәсем килмәгән иде, апай. Нишлим соң? Мәхәббәт сөйләштерә икән. Син бүгеннән аңа өйләнергә булсаң, мин инде ничек тә үземне тыярга тырышыр идем. Ләкин син — бүген-иртәгә армиягә китәсе кеше... Халидә чибәр. Аңа әллә күпме егетләр ябырылырга әзер. Әле син барга гына тыелып торалар. Китеп кара әле... Көтәм дигән жиреннән дә көтә алмас...

Аның шушылай, малайлар кебек, колагыннан мәхәббәткә чумуы Гаязга әллә нигә бик авыр тоелды, һәм үзенең дә тиздән әле үзләре яткан лапас түбәсен дә, абыйсын да, Халидәне дә ташлап китәсен уйлап, көрсенеп куйды.

— Халидә үзе яратса, миңа нәрсә?.. — диде ул, ләкин шундук эче, салкын август төнедәй, бушап китте. Аңа хәзер нәрсәдер житми, нәрсәдер югалган кебек иде. Шунда аның, сикереп торып, абыйсына:

— Алма Халидәне! — дип кычкырасы килде.

Аннары ул абыйсының сүзен дә дөрескә чыгарды: «Өч-дүрт елга китәсе кешенең кемгә дә булса хакы юктыр», дип уйлады ул. Әлбәттә, солдат кеше көтмичә булдыра алмый, ә кызлар?..

Аннары Гаяз армиягә китте. Халидәгә хат язмады ул. Абыйсына язган хатларында да аның исемен телгә алмады: Таһир үзе язар әле дип көтте. Ләкин ул Халидәне белмәгән икән, «Бәлкабзый яратыр да бит, Халидә яратыр микән?» дип уйламаган икән. Аның өчен — кызларны абыйсының яратуы житә, ул яратса, кызлар күптән яратырга әзер дигән уй гына яши иде. Бер нәрсә белмәгән икән!..

Шул ук елны көз, Таһир авырып китмәс борын ук әле, Гаяз Халидәнең кадровыйда хезмәт итүче күрше авыл егетенә кияүгә чыгу хәбәрен алды...

Гаяз сискәнеп артына әйләнеп карады. Бер төркем житкән кызлар мәктәптән кайтып килә иде. Кинәт аңа шулар арасында Халидә дә бардыр төсле булып китте... Гаяз, алар килеп житкәнче дип, хәтта качкандай, тиз генә китеп барды.

Галәветдин абзыйларга кереп чыгыйм әле, диде ул һәм түбән урамга борылды.

Аны күргәч, Галәветдин картның күзеннән яшьләре чыкты.

— Синмени соң бу, Әбел-Гаяз улым?.. Мин бит Сөләйман килеп керде дип торам. Ул да мәрхүм шулай, синең кебек, тавышсыз гына килеп керер иде дә әкрен генә тамагын кырып алыр иде. Нигәдер яшьтән үк тамак кыра торган гадәте бар иде мәрхүмнең. — Ул, исе китеп, Гаязга карап торды. — Үсепләр беттек диген, ә? Ә без менә чүгә барабыз...

Галәветдин — Гаязның әтисе белән бер яшьтәге кеше. Алар сугышка да икесе бергә киттеләр. Моннан төгәл егерме ел элек — 43 нче елның жәендә китkәннәр иде. Ай-ай ярым үттеме-юкмы, Галәветдиннең «без вести пропал» дигән хәбәре килде. Шуннан соң аны инде, барысы да үлгәнгә санап, көтүдән үк туктаганнар иде. Ләкин ул пленга төшкән булган, сугыш беткәч, төрле концлагерьларда яткан. Германия жиренә союзниклар гаскәре килеп кергәч, аларны корабльгә төяп, Америкага алып киткәннәр, ләкин Америкада төшермәгәннәр, яр буенда күпмедер тотканнан соң, әсирләрне кайтару турында килешү төзелгәч, шул ук корабльләре белән Россиягә озатканнар.

Галәветдин абзый яшьтәшләре арасында бер үзе укый-яза белми калган кеше иде. Ул русча да белми иде. Ул өч ай буена диңгездә чайкалуларын иркенләп сөйләсә дә, кайда булганлыкларын ачык кына әйтеп бирә алмады. «Әмрика яр буенда торабыз дип әйттеләр... аннан Гарәбстанны да үтеп киттек инде без... аннан Чурный мурегә кердек, диделәр...» дип, белмәвеннән үзе дә кыенсынып утыра торган иде.

Кайтып, бер атна чамасы өйдә ятты да унике яшьтән бирле эшләгән тегермәнен көйләргә тотынды. Сугыш вакытында тегермәннең куласаларын ваткалап ягып бетергәннәр, кәвес такталарына хәтле ботарлаганнар, эчендә мөшкә белән таштан башка нәрсә юк — бер кыса утырып калган иде. Ике ай эчендә Галәветдин бер үзе шул тегермәнне рәткә кертте. Су куласасы белән кырык чөйне генә ул Гаязның этисе белән бергә ясады, калган эшләрнең берсен бер — кешегә бирмәде.

Гөрләтеп эшләтә генә башлаган иде Галәветдин тегермәнне! Ләкин аны урак өстендә райвоенкоматка чакырып алдылар һәм... кире кайтармадылар. Немецка плен төшү белән гаепләп, башка урынга күчерделәр. Ул анда ирektә булган, эшләгән, хезмәт хакы алган, тик шәһәрдән генә беркая да чыга алмаган. Һәм шушы — ни укый, ни яза белмәгән бер кешегә, кайткач та әле, үз авыл Советыннан читкә чыгарга рөхсәт юк иде, 56 нчы елны гына ул мондый чикләүләрдән арынды...

Галәветдин Гаяз күрми торган дүрт ел эчендә бик нык бирешкән, озын гәүдәсе җилкәдән бик нык бөкрәеп төшкән, бите, кулы җыерчык иде.

— Кайтуыңны бүген ишеттем. Бүген үзем барып та чыгармын дип уйлап куйган идем. Үзең килдең, рәхмәт. Таһиржанкайның хәле ничек соң? — диде ул һәм, Гаяз җавап биргәнне дә көтмичә: — Туганлаша алмадык шул, туганлаша алмадык... — дип, үкенеп башын чайкады. — Халидәбез хәзер районда... Әллә нәмәсенә кияве яратмады бит. Торып китә алмадылар...

— Ишеттем, чибәр бабай... Үзең ничек соң? Эшлисеңдер инде?

— Пилорамда эшлидерием дә, ашказаным бик йөдәтә башлады. Чыктым. Хәзер каравылда — райсоюз складларын каравыллыйм. Нишлисең бит...

— Иртәгә районга барам. Халидәгә бирәр йомышың юкмы? — диде Гаяз.

— Йомыш дип, нинди йомыш әйтергә соң сиңа?.. Кайтмый дип, картлар үпкәләп ята, дип әйт. Ул бер атна эшли дә бер атна ял итә. Элек атна саен кайтып йөри иде. Әле туктатты. Укырга әзерләнәм, ди.

## Җиденче бүлек

Заготзернодан Уфага район үзәге аша көн саен автобус йөреп тора: кичтән килеп куна да иртән сәгать җидедә китеп бара иде. Гаяз таңнан шул автобуска чыкты.

Сәгать сигездә район үзәгендә иде инде. Эш башланырга тәгәл бер сәгать вакыт бар иде әле. Гаяз, бу бер сәгатьне ничек үткәрергә белмичә, тукталышта аптырап басып торды. Район үзәге анарда: тизрәк тугыз житсә иде, дигәннән башка берниндн тойгы да уятмый иде.

Тукталыш Культура йорты каршындагы кечкенә мәйданда иде. Автобус киту белән, мәйданда кеше бетте. Гаяз бушап калган эскәмияләрнең берсенә килеп утырды. Тугызга хәтле шушында гына көтәргә булды. Кояш та нәкъ аңа гына карап торган шикелле иде. Шушы май кояшы Халидәне тизрәк күрергә ашыкынган күңелен бераз баса төште. Шушылай көтү аңа очрашуның үзенә караганда да рәхәтрәк, нурлырак кебек иде. Хәтта нигәдер, Халидә белән очрашкач, бу нурдай җылы рәхәтлек бетәр төсле булып китте, күңеленә кинәт кенә ниндидер салкынлык килеп кагылгандай булды.

Бераздан ул утырып торудан ялыгып, кая барыйм икән? дип уйлана башлады. Район үзәгендә аның нибары өченче тапкыр гына булуы, һәм мондагы бер нәрсә дә аны тартмый, истәлекле урыннары да юк иде. Юкка Халидә торган квартир адресын алмаганмын, дип үкенеп куйды

ул. Ләкин шундук: «Инде ул эшенә килгәндер», диде. Шул уй белән жылы урыныннан кузгалды.

«Ашханә-ресторан» дип язылган таш бина олы юл өстендә генә тора иде. Гаяз нигәдер каушабрак калды: ул әле Халидә белән очрашырга әзер түгел. Халидә менә хәзер килеп чыкса, аңа бөтен очрашуның яме китәр төсле тоелды. Дулкынлануы бераз басылып, күңеле тына төшкәч, шулай да ашханәнең кайчан ачылуын беләсе килде. Ишеккә беркетелгән язу вакытсыз килеп төртелгән кешеләргә ашханәнең сәгать унбердән генә ачылуын әйтеп тора иде. «Сәгать унбердә ачыласы булгач, кухня эшчеләре инде күптән килергә тиештер бит», дип, ахырда Гаяз үзенең юкка гына көтеп торуын искә төшерде, үткән бер кешенең күзенә кереп тормас өчен, тагын да автобус тукталышы ягына китте. Район хәрби комиссариаты шул якта иде. Ул арада сәгать тә тугызны сукты.

Сәгать бергә аның эше беткән, хәрби учетка да, комсомол учетына да кергән иде инде.

Башта ул, ашханә коридорындагы көзге каршына басып, өс-башын рәтләп алды. Эшләгәндә ул әйбәтлеккә бер кат кием юнәткән иде. Әле аның өстендә иң соңгы мода белән тегелгән кара костюм, ап-ак күлмәк, кара галстук, аягында зәңгәрсу нейлон оекбаш, очлы башлы кара туфли иде. Гаяз, чәчен тарап, галстук төенен кысты да, инде очрашырга әзермен дигәндәй, залга керде. Залда кеше аз — нибары биш-алты гына кеше утыра. Буфет янында да бер-ике кеше генә тора иде. Гаяз килеп керү белән, залда күпме кеше булса, бөтенесе дә аңа борылып карады. Ул тиз генә буфет янына үтеп меню укырга кереште. Аннары кинәт карлыккан тавыш белән буфетчицадан сорады:

— Әллә сездә самообслуживаниеме?

Буфетчица елмаеп:

— Сезнең кебек егеттән аш күтәртеп йөрмәбез инде, — диде. — Нәрсәләр аласыз?

— Борщ, бефштекс, сөтсез кофе.

Буфетчица тиз-тиз генә талоннар сугып бирде дә:

— Әнә шул өстәлгә утырыгыз, хәзер үк кызларның иң чибәре чыгып алыр, — диде, аннан калын гына тавыш белән: — Кызлар, чыгыгыз әле берегез! — дип кычкырды.

— Рәхмәт, үзем дә барып ала алам, — диде Гаяз һәм аш бирә торган тәрәзәгә борылды. Буш тәрәзә алдында ябь-яшь кенә дүрт-биш кыз елмаешып аңа карап тора иде. Гаяз аларга таба борылгач, тиз-тиз генә тәрәзәдән читкә сирпелделәр. Икәве генә аның килүен көтеп калды.

— Халидә апагыз кайда соң? — диде Гаяз. — Мин аның авылдашы идем...

Кызларның берсе ялт итеп артына борылды, кухня түреннән күренеп торган ачык ишеккә карап:

— Халидә апа, — дип кычкырды. — Сине бер абый эзләп килгән.

Гаязның йөрәге тибүдән туктагандай булды, кичәдән бирле шушы очрашуны өзелеп көткән күңеле кинәт талпынып куйды — тын алырга да хәленнән килмичә, Халидәнең кухня түрендәге ишектән килеп чыгуын көтә башлады.

Халидә шундук чыкты. Үзен нигә чакыруларын аңламыйча, озын кухня буйлап килә башлады. Аның бөтен киеме актан иде, йөзе генә янып торган кара-тут иде. Ул бер дә үзгәрмәгән, атлап килүләренә кадәр шул — элекке Халидә иде. Ул Гаязны килеп житмичә танымады, хәтта килеп житкәч тә әле: «Кая, кем?» дип кызлардан сорарга итте. Шунда гына ул елмаеп торган Гаязга карады һәм йөрәге өзелеп төшкәндәй булды. Аннары сагыш тулы тавыш белән:

— Гаяз!.. Син түгелме соң? — диде.

— Мин шул! — диде Гаяз көлеп һәм күрешергә кул сузды.



— Тәрәзә аша күрешмик инде. Кер бу якка әнә шул ишектән,— диде Халидә һәм үзе дә ян ишеккә юнәлде.

Гаяз залдан чаршау белән генә бүленгән коридорга керде һәм каршында елмаеп торган Халидәнең уттай кулын кысты. Халидә аның кулын җибәрмәде. «Әйдә монда» дип, кухня каршындагы кунак бүлмәсенә алып кереп китте. Бу бүлмәнең тәрәзәсе зур, эче тулы кояш иде. Халидә аның икенче кулыннан да тотып алды һәм шулай, каршына баскан килеш, әз генә башын күтәрә биреп, Гаязның күзләренә карады; шунда аның төпсез күзләренә яшь тулып, иреннәре калтырый башлады.

— Халидә! — диде Гаяз. Үзен-үзе белештермичә аның калтырап торган гәүдәсен кочаклады.

Халидә барыбер тыела алмады — елап җибәрде.

Шунда ишек шакыдылар. Халидә тиз генә Гаязның кочагыннан чыгып, арткарак чикте. Ишектән, кер дигәнне дә көтмичә, Гаязга аш бүлгән кыз килеп керде.

— Менә, абый, сезнең ашлар, — диде ул. Подносны өстәлгә китереп куйды.

— Утыр, — диде Халидә Гаязга һәм үзе дә аның каршысына утырды.

— Кайчан кайттың? — диде ул бераздан.

Гаяз аңа җавап бирде.

— Я, безнең ашларны да ашап кара, — диде Халидә.

— Инде ашыйсым да килми, — диде Гаяз. Шулай да теләр-теләмәс кенә ашый башлады.

Улына сөеп караган ана кебек, Халидә аңардан күзен дә ала алмый иде.

Гаяз ярты гына тәлинкә аш ашады да кашыгын читкә куйды.

— Яратмадың ахры безнең ашны? — диде Халидә.

— Аш бик тәмле, ашыйсым гына килми.

— Таһирҗанның хәле ничек соң?

— Бераз хәлләйде.

— Бүген үк кайтып китәсеңме авылга? — диде Халидә.

— Бүген үк китәм. Төпчек абзый белән бер эш алган идек.

— Нинди эш?

— Кичә Нухка өй сөйләштек.

Халидә кинәт үзгәреп китте, әле генә балкып торган йөзенә кара күләгә яткандай булды. Гаяз моны үзенчә аңлап, тиз генә аклану табарга ашыкты.

— Бәлкабзый бик каршы килсә дә — тыңламадым. Тегендә эшли башлау белән, беренче эш итеп өс-башны караган булдым. Үзен беләсең бит инде: солдатның нинди киеме бар. Акчалы кайтырга туры килмәде. Бәлкабзыйга тәрбия кирәк, ун-унбиш көн эшләп алыйм, дидем. Аннан колхозда эшләрмен дип торам.

Ул, күзен күтәреп, Халидәгә карады. Халидә инде, бер нәрсә булмагандай, кояш кебек аңа тутырып карый иде, аның әле генә күләгә төшкән йөзендә тагын да яктылык, бөтен авыр уйларны чәчеп җибәрә

алган җылылык бөрки иде. «Аңлады! Халидә булсын да — аңламасын!» дип, Гаяз чын күңелдән шатланып куйды.

— Кара кофе эчәсеңме? Үзем пешереп бирәм, — диде Халидә.

Ул урыныннан кутәрелде, чыгарга дип ишек ачты, ләкин ул ачкан ишектән бүлмәгә ашханә директоры Зәкиев килеп керде. Шундук Гаязны күреп, танып та алды. Гаяз да аны таныды. Ул — Нух белән пароходта бергә кайткан кеше иде.

— А, иске таныш! — диде Зәкиев һәм, елмаеп, туп-туры түргә узды.

Гаяз да, торып, аның кулын кысты — аның кулы яшь иттәй йомшак һәм дымлы иде.

— Авылдашым... — диде Халидә. — Бергә үскән идек...

Ләкин Зәкиев аның сүзенә игътибар да итмәде шикелле. Өстәл өстенә тиз генә күз ташлап:

— Кунакны коры шулпа белән генә сыйлыйсыңмыни? — диде.

— И алла, башыма да килмәгән! — диде Халидә гаепле кеше сыман. — Берәр нәрсә эчәсеңме, Гаяз?..

— Кунактан шулай сорап торалармыни? — диде Зәкиев. — Бар, алып кер әле бер савыт венгерский коньяк. Синең кунак — минем дә кунак.

— Минем өчен булса мәшәкатьләнмәгез. Мин эчмим, — диде Гаяз.

Зәкиевның да исенә төште:

— Әй, шулай бит әле! — диде ул һәм, бер яңалык әйткән кешедәй, Халидәгә карады: — Пароходта да эчмәгәние шул. Күпме кыстауга кыстадык — эчмәде тәки. Молодец!

Аның сүзеннән Гаязның күз алдына салкын көн, туктаусыз яңгыр, караңгы каюта һәм шунда туктаусыз эчкән Нух белән шушы кеше килеп басты. Табигатьнең салкын ямьсезлегенә боларның ямьсез эчүләре кушылып, күңелен тәмам өшеткән, болай да атасыз өйгә авыр тойгы белән кайту көне, җитмәсә шулар аркасында, һәрвакыт җан биздергеч бер көн булып калачак иде.

Гаяз урыныннан кузгалды.

— Ярый, мин китим инде.

— Гаепләп китмә инде, — диде Халидә. Йомшак кына итеп аның кулын кысты.

Гаяз чыгып китү белән үк, Зәкиев:

— Кемең бу? — дип сорады.

— Авылдашым дидем бит.

— Ай-һай, авылдаш кына микән?..

— Алай булгач, сөйгән егетем! — диде ачу белән Халидә.

Халидәнең болай әйтүе Зәкиевка аяктан еккандай тәэсир итте. Ул, кинәт йомшап, Халидәгә ялманып карап куйды.

— Каты бәгырьле син, Халидә. Мин сине якын күргән саен — бәгырең ката бара...

— Бу турыда сөйләшмик дип күпме әйттем инде мин сезгә, Зәкиев абый. Һаман үзегезнекен тукыйсыз.

— Халидә, баштагы мәлне син ул кадәр каты бәгырьле түгел идең. Нәрсә булды?

— Бер нәрсә дә булмады. Башта мин сезне уйнап сөйләшә торгансыздыр дип уйлаган идем. Хатыныгыз, җитеп беткән ике кызыгыз бар, оят түгелме сезгә, Зәкиев абый?..

— Их, Халидә, Халидә!.. — дип, Зәкиев урыныннан торды.

Ул кырт кына итеп өзеп куя торган кешеләрдән түгел иде. Кулында нинди дә булса соңгы чара булганда гына ул үз алдына максат куя. Әгәр, бөтен көчен куюына карамастан, максатына ирешә алмаса, ул шул соңгы чарасына ишарә итә башлый иде. Бүген ул Халидәне шуның белән куркытмакчы булып кергән иде, ләкин тагын кичектерде: ул әле үзе әзер түгел иде.

Ул чыгып китү белән, Халидә әле генә Гаяз утырып торган урынга килеп утырды, баядан бирле, тулып та, елый алмый торган күңелен иреккә куеп, әкрен генә елый башлады. Ул үз язмышын каргамыйча, әрнеп сыгылып төшмичә елый иде. Хәтта аңа шушылай елау рәхәт тә иде. Булмәгә беркем дә кермәде, аны беркем дә борчымады. Халидә күңеле булганчы елады да, күз яшьләре үзеннән-үзе тукталгач, битен-кулын юып керде, халатын, башлыгын салып, чәчен тарап алды, аннары, кызларга үзенең бераздан киләчәген әйтеп, чыгып китте.

Автобус туктый торган мәйданда аның битен саф җил сыйпап үтте. Шунда гына аның гарьлектән кысылган йөрәге тигез тибә башлады.

Автобус көтүче биш-алты кеше арасында Гаяз юк иде. Кинәт Халидәгә бар нәрсә ямьсез булып китте, күңелен шушы мәйдан кебек битараф бушлык суырып алды: «Киткәндер... Минем турыда начар уйлап киткәндер...»

Аннары ул Гаязның малай чагыннан бирле киемне саклап кына, кадерен белеп кенә тотуын исенә төшерде. Гаязның өстендә әнәдән-җептән генә чыккан костюм иде. «Юк, китмәгәндер. Андый костюм белән ул теләсә нинди машинага утырмас», дип уйлады Халидә һәм эченә шатлык йөгерде.

Башкалардан бер читтә, башына кәшимир яулык бәйләгән, өстенә ирләр пиджагы кигән бик матур бер әби утыра иде. Халидә, аның янына килеп:

— Уфадан автобус булмадымы әле? — дип сорады.

Автобус килмәгән икән, ярты сәгать вакыт бар икән әле.

Ул көтәргә булды һәм бер читкә, койма буена барып басты. Гаяз белән бүгенге очрашу шатлыгын искә алды. «Олыгайган...» диде. Гаязны ул бүген гомерендә беренче тапкыр кочаклады, һәм менә хәзер, шуны кабат уйлаганда, мәхәббәт һәм бәхет өчен яратылып та, тормышта киресенә юлыккан кешеләр генә белгән үкенеч биләп алды аны.

Көтү бушка китмәде. Өч туларга ун минут калды дигәндә, олы урамнан Гаяз килеп чыкты, аның кулында капрон сетка, ә сеткада өчмедүртме кисәк такта чәй күренеп тора, калганнары күренми — кәгазьгә төрелгән иде.

Халидәне күргәч, ул сөенеп елмайды, малай чактагы шикелле, ни әйтергә дә белмичә, кулындагы сеткасына карады.

— Менә алдым әле.

— Авылда әллә чәй юкмы? — диде Халидә.

— Әллә тагын. Магазинга кергән юк әле.

Алар әкрен генә атлап кешеләрдән читкәрәк китеп бардылар. Койманың буеннан-буена, эчке яктан тезелеп киткән чаганнар әрсез ботакларын урамга ук сузып, кош теледәй нәфис яфраклары белән Гаязның ялан башыннан йомшак кына сыйпап калалар иде.

Алар читкәрәк чыктылар. Аларның сөйләшер сүзләре күп, тик вакытлары гына аз иде. Сәгате-минуты белән автобус килергә торганлыктан, икесе дә иркенләп сөйли башлаудан курка, бер-берсенә генә сөйли ала торган сүзләрнең урыны бу түгел, вакыты да бу түгел иде. Ә хәзер алар, тирәнгә кермичә, җәелеп китмичә, сорашып-сөйләшеп йөрделәр.

— Кичәләргә чыкканың булдымы соң әле? — диде Халидә.

Гаяз көрсенеп куйды:

— Юк, Халидә, ул кайгы булдымыни әле миндә?.. Иртәгә таңнан эшкә тотынам. Монысы инде сиңа производство түгел. Кояш чыкканнан кояш батканга хәтле эшләргә туры киләчәк. Клуб кайгысы булмаячак.

— Әллә кемгә эшләмисең әле — Нухка эшлисең. — диде Халидә. — Эш дип егылып барма. Клубка да бармасаң, кызлар көләр үзеннән...

Ул әле тагын да нидер әйтергә тиеш иде, ләкин авызыннан «кызлар» дигән сүз чыгу белән, аның исенә кылт итеп Нух кызы килеп төште.

Ул кыз яшь һәм чибәр иде. Һәм менә хәзер Халидә үзе өчен өтәләнеп торган шул кыздан көнләшеп куйды: Гаязны ул һәр көн күреп торачак иде...

Ул арада үзәк урамнан автобус килеп чыкты, һәм алар тиз-тиз атлап тукталыш ягына киттеләр.

Автобуска кергәндә Гаяз:

— Әтиеңә сине кайчан кайта дип әйтим инде? — диде.

— Көтелмәгән эш килеп чыкмаса, алдагы атнага.

— Кайт, көтәбез, — диде Гаяз.

Ул автобусның ишеккә каршы ягына кереп утырды. Халидә, машина артыннан урап, аның ягына чыкты. Алар әле сүзсез генә бер минутмы, ике минутмы тәрәзә аша карашып тордылар.

### Сигезенче бүлек

Кайтучыларның күбесе Бишбүкән чатында төшеп бетте, биш-алты гына кешесе калган автобус заготзерно юлына борылды. Чуерташ түшәлгән юл каты, дыңгырдык иде, алгы тәгәрмәч ыргыткан вак ташларның өзлексез шоссега бәрелгән тавышлары көчәя төште. Тәмам бушап, җиңеләеп киткән автобус, җилгәргеч сыман, бөтен гәүдәсе белән калтыраргa, тәрәзә пыялаларына хәтле зыңларга тотынды, пассажирларны, иләктән үтми торган орлык шикелле, селкетә-сикертә башлады. Сикерткән саен идәннән борхылдап тузан күтәрелә иде.

Кайтып җитәргә ике чакрымлап җир калгач, юл сөзәкләп кенә түбән төшә башлады. Уң яктан колачын җәеп күгелҗем Агыйдел килеп чыкты. Алда үз авылының өске урам өйләре чагылып китте. Нәкъ каршыда, заготзерно тавы өстендә, Нух күтәреп куйган өй ялтырап күренде. Барысы да үз урынында иде. «Төпчек абзый бәпкәләргә тотынды микән?» дип уйлады Гаяз. Үрелеп тәрәзәдән карады. Ләкин бура күз күременнән аста иде — якты фонда тормавы сәбәпле, моннан аның бәпкәләрен дә, өстендәге кешесен дә аерып булмый иде.

Автобус заготзерноға төшеп туктаячак, Нухлар турыннан үтеп кенә китәчәк. Ләкин Гаязның бүген алар турыннан үтеп тә китәсе килми иде. «Кырлач аша кайтыйм әле, учетка да керермен», диде ул һәм, ферма юлына җиткәч, шофер егеткә туктатырга кушты. Автобуста киеменә тузан кунган иде, төшкәч, пиджагын кагып киде, аннан әйбәтләп чалбарын какты. Аннан — ике ягы да сөрелгән юл буйлап Кырлачка төшеп китте.

Авыл үзе, бу яктан килгәндә, өстенә басмыйча күренми. Гаяз тау битендә бер генә минутка туктап, аяк астында яткан авылга карап торды. Бәләкәй чакта алар Кырлач малайларын: «Кырлач, Кырлач кырылган, бер чокырга тыгылган», дип үчеклиләр иде. Исенә шул килеп төште. «Кая! Ул чакта әле Кырлач моның яртысы гына иде!» Ә хәзер?! Ул юкта гына да күпме кеше йорт салып чыккан! Бөтенесе дә таза, нык. Түбәләре дә — шифер да калай. Миңеште тугаенда бүтәнчә киңәер җир калмагач, элекке ихаталар кысыла төшеп, араларына яңа өйләр кереп утырган. Ике яклап та тау битенә менә башлаганнар. Шулай итеп, Кырлач үз «чокырыннан» киерелеп чыгып килә иде.

Бу авыл Гаязга үз авылыдай якын — бигрәк тә әнә теге мәктәп, әнә теге клуб якын иде. Клубны соңгы ел укыган кышны сала башлаганнар иде — ике ел эшләделәр. Гаяз да ел ярым эшләп калды: балта осталары җитми иде, укуын бетереп, ике-өч көн ял иттеме, юкмы — әтисе аны үзе янына эшкә дә кушты. Инде аңа алты елдан артык гомер үткән. Хәзер ул шул клубка кереп чыгачак. Шунда эшләүче бер кыз аны комсомол учетына алачак. Карале, фамилиясен дә әйткәннәр иде бит әле ул кызның. Кем диделәр соң әле? Ахметшина... Мухаметшина... Бер

«шина»сы бар иде инде... Гаделшина да түгел... Ул, мәсьәлә чишә алмый интеккән укучы кебек, уйлый-уйлый авылга төште. Аннан Имай тыкрыгына керде. Аннан үзәк урамга чыкты.

Фойеда дүрт егет, авызларына папирос кабып, бильярд сугып ята иде. Алар Гаязны шундук таныдылар. «Исәнме, Гаяз абый? Кайттыкмы?» — дип, барысы да күрешеп чыкты. Гаяз аларның икесен генә таныды, икесен танымады: бу икесе ул киткәч калкып чыккан егетләр иде.

— Клуб мөдиреге мондамы?

— Монда, — диде Гаяз таныганы. — Монда булмаса, Флүс монда булыр идемени?

Ана кушылып теге ике яшьрәге дә көлде, ләкин артык җаелмаделәр, каз төсле «ыгы-гы» дип кенә куйдылар. Бу икесе чүкеч буйлыгы гына иде. «Шөрлиләр тагын үзләре!» дип уйлады Гаяз һәм Флүскә карады. Флүс гәүдәгә өчесеннән дә озынрак та, калынрак та иде. Гаяз карагач, кып-кызыл булды.

— Земфира дигәч шарын да онытты инде, — диде Гаяз таныганы. Алар тагын тыелып кына көлеп алдылар.

Флүс баядан бирле таягын шарга төзәп тора иде. Кинәт ул чәмләнеп шарга сукты. Ике шар ике якка томырылып төшеп китте.

— Менә шулай җиппәрәләр аны, апайлар! — диде Флүс.

Тегеләрнең көнчелеге йөзләренә үк чыкты, әлеге бәйләнчеге:

— Ярый әле Земфира килде, — диде.

— Мин сине ул килгәнче дә җинә идем, апай! — диде Флүс.

Ул инде лузага «үз» шарын төшерергә чамалый иде. «Күп сөйләшми икән, басынкы икән», дип уйлады Гаяз. Аннан соң:

— Хәмзә нишләп чыкты? — дип сорады.

— Чыгаргач, — диде берсе.

— Нигә чыгардылар соң?

— Әллә. Белеме юккадыр.

— Монысының бармы инде?

— Бардыр инде. Стәрлетамакта укыган бит.

— Кайсы авылныкы?

— Әллә. Бу тирәнекеләр түгел. Әнә Флүс беләдер.

— Мин каян белим? Син үзең беләсендер, — диде Флүс.

— Фамилиясе ничек, Ахметшинамы?

— Юк. Хәсәншина.

«Безнең як түгел икән шул», — дип куйды Гаяз. Үзләре ягында аның Хәсәншина дигән фамилияне ишеткәне юк иде.

Шунда Флүс, башын күтәрмичә генә:

— Нигә кирәк соң ул сина, Гаяз абый? — диде.

— Учетка керергә иде.

— Кара, кара! Көнләшә дә башлады! — дип, егетләр Флүсне әләп тә алдылар.

Гаяз ян якта торган ишеккә юнәлде. Аның артыннан берсе:

— Репетиция булмәсендәдер алар, — дип калды.

Гаяз ишекне киң ачып, ян коридорга керде. Борынына, клубны салган вакыттагы кебек, чыршы исе, сагыз исе килеп бәрелгәндәй булды. Коридор буйлап баян һәм җыр тавышы агылып килә иде — монда да «Гөлҗамал»ны уйныйлар иде.

Гаяз сагыштай кысан, сагыштай озын коридорның аргы башына тизтиз генә атлап китте. Каты гына итеп ишек шакыды. Эчтәгеләр шундук, чит кеше барлыгын сизеп, уйнаудан да, җырлаудан да туктап калдылар.

— Керегез! — диде бер тавыш.

Алар өч кыз иде: берсе утырып, икесе басып тора, утырганы баян тоткан — һәм өчесе дә, кем булыр икән дип, ишеккә караган иде.

— Исәнмесез, кызлар!

— Бик исәнбез әле, — диде баян тотканы.
— Бүлдердем бугай.
— Юк, юк, — диде баянлы кыз.
Гаяз аларның берсен дә танымады. Болар шулай ук — ул киткәч буйга җиткән кызлар иде. Баскан икесе чегәндәй кара-сылу, гәүдәгә, коеп куйган сындай, ныкча иде. «Болары үзебезнең Миңеште буе кызлары инде!» дип уйлады Гаяз. Исенә үзе эшләп кайткан совхоз килеп төште. Анда иң авыр, иң кара эшләрне менә шушындый кызлар эшли иде. Аннан соң ул өченче кызга текәп карады. «Шушысыдыр инде Хәсәншина», — диде.
Бу кызның бөтен гәүдәсен баян каплаган, баян өстеннән ачык муены белән иңбашлары гына күренеп тора, тулылыкка теге ике кыздан күпкә кайтыш иде. Төскә-башка да Миңеште кызларына бөтенләй охшамаган: йөзе ак, чәчләре дә аксыл, ә күзләре — болындагы күлдәй зур иде.
— Земфира Хәсәншина сез буласызмы? — диде ана Гаяз.
— Мин булам, — диде аңа кыз. Тиз генә торып, баянын урындыгына куйды.
Кичә соң гына, район культура бүлегеннән шылтыратып: «Уфадан вәкил килде. Кара: иртәгә сезгә барып чыгуы бар...» — дип колагына төшереп куйганнар иде. «Әллә шул микән? — диде Земфира. — Сез Уфадан түгелме? — дип сорарга итте, ләкин Гаязның кулында, я портфель, я папка булмау сәбәпле, икеләнебрәк калды.
— Нишләп сүзсез калдыгыз әле, кызлар? Бүлдергәнгә ачуландыгызмы әллә? — диде Гаяз.
Кызларның берьюлы теле ачылып китте:
— Нинди ачулану ди, абый?..
— Утырыгыз...
— Менә монда...
Бөтен бүлмә, ничектер кыймылдап, аңа урын бирә кебек иде.
— Рәхмәт. Утырып тормыйм. Юлдан гына.
«Шул бугай!» — диде Земфира, һәм тел очында гына торган сүзе төшеп тә китте:
— Сез Уфадан түгелме?
Гаяз шаяртып:
— Уфа егетләрен көтәсез икән, белдек! — диде.
— Егетләрен көтмибез лә ул. Егетләр үзебездә дә күп.
— Әллә артып та каламы?
Кызлар да уен сүзгә күчте:
— Кала шул. Әнә Сария кияүгә чыккач, биш егете артып калды.
— Кыз табам дип өмет тә итәсе юк икән, — диде Гаяз.
— Әллә сезнең якта да шулаймы, абый?
— Шулай дисез бит.
— Без бит үзебезнең якны әйтәбез.
— Мин дә сезнең якныкы инде: Айбавылныкы.
Кара кызларның берсе: «Айбавылныкы?!» — дип кайтарып сорады, икенчесе:
— Айбавылларны беләбез без. Алдашып тормагыз, абый, — диде.
Гаяз пиджагының эчке кесәсеннән документларын алды да Земфирага бирде.
— Ышанмасагыз, менә паспорт, менә комсомол билеты, менә прикрепительный талон. Учетка керергә килдем.
Земфира аның паспортын ачып карады да иптәшләренә:
— Чынлап та Айбавылныкы шул, кызлар! — диде.
— Я, ышандыгызмы инде?
— Баштук шулай паспорт күрсәтеп сөйләшәләр аны.
— Шулай итми дә булмас.

— Фаизны күрмәдегезме әле? — диде аңа Земфира.
— Юк. Нигә?
— Ул — безнең комсомол секретаре.
Гаяз шатланып:
— Шулаймыни?! Күрмәдем әле мин аны, — диде.
Земфира аңа паспорты белән комсомол билетын кире бирде.
— Ә талоны миндә кала, учетка алырбыз, — диде.
— Шул гынамы?
— Шул гына.
— Ярый, исән булып торыгыз, — диде Гаяз һәм чыгып китте.
Фойеда бильярд сугып яткан егетләрнең дүртесе дә: «Озакларга итә бу», — дип, аңардан көнләшә үк башлаганнар иде — Гаязны күргәч, эчләренә җылы йөгерде. Гаяз таныганы, аны үз ише итеп:
— Ну ничек, булдымы? — дигән булды.
— Булды, — диде аңа Гаяз.
Ә теге бәйләнчеге:
— Шәпме соң Флүснең Земфирасы? — дип сорады.
— Әйбәт кыз, — диде Гаяз. — Өчесе дә әйбәт, — диде. Ул аңа тагын бер карап куйды, елмаеп әйтте: — Ике сүзнең берендә Земфира дисең, апай, үзең чапмыйсың микән артыннан?
Аның сүзен Флүс эләп алды:
— Земфира килгәннән бирле чаба да — житә алганы юк әле.
— Син житәрсең инде аю табаның белән, — диде тегесе.
Ул алама көнчел булса кирәк: сүзен дә Флүснең авырткан жиренә тисен әле дип, белеп әйтте. Флүс кабынды да китте — авыр таягы белән сугарга кизәнде.
— Минем табанда синең эшең булмасын!
«Сукса өзә бит!» — дип уйлады Гаяз һәм минут эчендә Флүснең беләгеннән тотып алды.
— Жә-жә! Бала-чагаланмагыз. Килешми.
— Нигә мыскыл итә? Мыскыл итмәсен!..
Шулай да Флүс сабыр иде — аның сабырлыгы жиңде. Бер нәрсә дә булмагандай, таягын шарга төзәде. Мәгәр тегесе агарып каткан иде.
Гаяз урамга чыкты. Фаизлар өе авылның бөтенләй икенче башында иде. Барыйммы, юкмы дип торганнан соң, бүген бармаска булды. Иркенләп бер килермен әле дип, кайтыр якка борылды.
Шунда аңа кинәт клубта бик кадерле бер нәрсәсе торып калган кебек тоела башлады. Әллә юкса һәркайда күбәләктәй очып йөргән этисе рухы калдымы?..
Шунда аның колак төбеннән генә клубта ишеткән «Гөлжамал» көе аваз биреп үтте.
Шунда ул күңел китеп торган нәрсәнең өстенә генә баскандай булды: клубта калган Земфираны уйлагач, күңеленә рәхәт булып китте.

**Тугызынчы бүлек**

Балтя осталарына булган кытлыкны Тәлха Сәйдәшев моннан алты ел элек, колхоз үзәгенә культура йорты салганда, бер мәртәбә татыган иде инде. Бәхеткә каршы, ул чакта осталар Сөләйман абзый кул астында эшләделәр.
Кыю кеше иде мәрхүм Сөләйман. Культура йортының фасады типовой проектта бөтенләй икенче төрле иде, ямьсез иде. Тотты да шуны үзенчә эшләде дә куйды. Райком секретаре моны соңыннан үзенең бер докладында «архитектурные излишества» дип каты гына әйтеп тә үтте. Хәлбуки монда берни дә «излищество» юк иде. Сөләйман фәкать,

культура йортын заготзерно амбарлары белән бутамас өчен, архитектура ансамбле генә өстәп ясаган иде.

Тәлха Сәйдәшев, клуб салучылар яныннан нервысын бозып кайтканда, минә шуларны уйлап кайтты. Гаязның әтисен тагын бер тапкыр сагынып искә алды.

Быелга колхоз бик күп нәрсә төзүне планлаштырды. Ике авылга ике клуб, бер ашханә, дүрт кибет саласы бар. Караучысыз калган колхозчыларга өй салып бирү дә бик күпкә китә: саный башлагач, жиде авылдан унбишкә житте. Болары әле беренче чиратта торганнары... Ә күпме кеше үзенә йорт житкезеп ята? Барысына да каян оста табып бетерәсең?

Балта кәсебе үзе дә соңгы вакытта бөтенләй бетте диярлек. Сугышның бу ягындагы авыр еллар бетерде аны. Колхозның да, колхозчының да яңага хәле юк, искене генә сипләп, зурны гына кечерәйтеп сала иде. Амбарлар кечерәйде, мәктәпләр кечерәйде, йортлар кечерәйде, я бөтенләй юкка чыкты. Осталарга балта эшендә хут юк, балта эше белән генә тамак туйдырып булмый башлады. Шунлыктан аларның бер кышесе бөтенләй башка һөнәргә тотынды: атлы эшкә күчте, каравылчы булып булса да, машина янынарак күчте. Локман кебекләре исә, колхозларны берләштерә башлагач, Сәйдәшевкә кушылмыйбыз дигән булып, кәсепкә үк чыгып китте.

Локманны Сәйдәшев яшьтән үк белә. Авыллар элек-электән — берберсенә кул бирешеп торган кебек якын, хәтта, ике арада Галәветдин тегермәне бар чакта, бөтенләй бер авыл кебек иде. Сәйдәшев хәтерли: Локман, колхоз төзелгәч, бик дәртләнеп, жиң сызганып эшли башлаган иде. Ләкин соңыннан каяндыр, нәрсәседер сынды. Һәм Локман, 38 нче елны булса кирәк, корсактагысы белән жиде баласын калдырып, читкә чыгып китте. Сәйдәшев аның Мәскәү «Метрострой»ында эшләгәнен дә, өенә ай саен күп кенә акча жибәреп торганын да белә. Хәтта семьясына ниндидер льгота да биргәннәр иде. Авылына Локман сугыш чыгар елныны, элекке елныны гына кайтты. Юлда машина авариясенә эләгеп, сул кулын терсәктән түбән сындырган иде, бик озак муенына асып йөрде. Ләкин кулы, вакытында медицина ярдәме булмау сәбәпле, дөрес ялганмыйча, сынган жиреннән аз гына кәкрәеп калды, әмма Локман балтасын да, башкасын да бер тотса туры тота иде. Аны сугышка да алмадылар, комиссиядән комиссиягә йөрткәннән соң, трудармиягә генә ярады. Күрше Бишбүкән больницасында Петров дигән баш врач эшли иде. Петровның ул вакытта ук инде дәрәжәсе зур, сүзе районда гына түгел, Уфасында да үтә иде. Шул Петров, хәрби комиссариат аша юллап, Локманны үз больницасына алып калды. Локман трудармия срогын шунда тутырды.

Әле менә шуларны искә төшергәч, Сәйдәшев Локманның шул вакыттагы эшенә хәйран китеп, башын селкеп куйды. Больницаның үз янында унбиш гектар жире бар иде. Шул жирне сөргән дә, карабодаен, солысын чәчкән, бәрәңгесен, яшелчәсен утырткан да, шуларны карап, каравыллап үстергән дә, жыеп келәткә салган да — бер Локман белән ике ат өстенә төште. Болар гынамы соң? Бөтен балта эше, урман эше аның өстендә иде. «Больницаны иң авыр еллардан бер үзе алып чыкты бит, ә!» диде Сәйдәшев. Сугыш беткәч, Петров, күзләренә рәхмәтле яшьләр чыгып, Локманны кочаклап үпкән, кал дип үтенгән, дип сөйләделәр. Бу сүзне берәү дә: дөрес түгелдер лә, димәде. Шуннан Локман кайтмады, больницада инде хезмәт хакына эшләп калды. Трудармия срогын үтәгәндә, Петров аны авылына дүрт айга бер генә — мунча кереп килергә генә кайтара иде. Хәзер ул атна саен, кайвакытта хәтта көн саен кайтып йөри башлады. Авылдагы дөньясын туздырмады ул. Хатыны гомер буе колхозда эшләде, балалары да үсә тордылар, колхозга эшкә китә тордылар.

Больница эшеннән Локман 50 нче ел башында үзе чыгып кайтты: инде семьядан аеры яшәүдән ялыккан иде — Бишбүкәндә эшләп. Айбавылда дөнья көтүе дә авыр иде; хатыны, балалары да: «Иллегә житкән башың белән бала-чагадай чабып йөрмә, кайт!» — диделәр.

Ул кайткач кына, алар колхозына председатель итеп Кырлач авылыннан Әсләмне куйдылар.

Локман ничектер, кинәт хуҗасы үлгән хезмәтче сыман, ике кулсыз торып калды. Җиде ел буена бер хуҗада — Петровта хезмәт итеп, аңа күнеккән, өйрәнгән иде. Петров каты куллы иде, ләкин Әсләм кебек вакчыл түгел, бәйләнчек түгел иде, аңа синең уең да, карашың да кирәкми иде — аңа синең эшең-гамәлең генә кирәк иде. Ә монда, үз авылында, Әсләм аңа бәйләнә башлады: «Контр! Артта калган элемент!» дия башлады.

— Үзебезнең авылда да исәр Шәйхетдин бар иде ләбаса! Кырлачтан китереп шул диванны утыртмасалар... — ди дә Локман, Әсләменә дә, колхозына да төкереп, заготзернога чыгып китә.

Әслам отыры кызып, җыелышларда хәтта: «Әгәр кире кайтмаса, оясы белән туздырып ташлыйм мин аның дөньясын!» — дип аңа янап йөри башлый.

Локман үз чиратында Әсләмгә әйткән:

— Мин, апай, син килмешәкне колхоздан сөрмичә, кайтмаска булдым инде... — дигән.

Әсләмне, билгеле, «сөргәнче» тотмыйлар — колхозларны берләштергәндә, үзеннән-үзе төшеп кенә кала. Хәзер әнә — налоговой агент булып йөри. Инде Локман колхозга кире кайтырга тиеш иде бит! Ләкин ул кайтмый. Ул вакытта заготзерно директоры икенче иде әле — Шагалиев иде. Дөрес, Сәйдәшев белән алар әйбәт-тату яшәмәделәр — кеше өчен низаглашып, бозылышып беттеләр. Хәтта, Шагалиев заготзернога җир юллый башлагач, Сәйдәшев: «Колхоздан киткән кешеләрне кайтарсын, шуннан соң карарбыз җир бирүне», дип кенә җибәрде. Райком бюросына барып җиттеләр...

Ләкин, моңа карап кына, Сәйдәшев Шагалиевны яманлап йөрмәде — киресенчә: «Әйбәт хуҗа!» дияр иде. Чынлап та, Шагалиев эшләгән кешене күрә дә, бәяли дә белә иде. Локманны да тиз күрде. Күрде дә чат ябышты. Ябышмыйча! Бер үзе дүрт кеше урынына эшләсен әле Локман. Сәйдәшев үзенең Локманны, өенә барып, колхозга кайтырга димләвен бер дә онытмый. Кайтмады тәки! Кабат килерлек тә итмәде. Әйткән сүзләре Сәйдәшевның әле булса исендә:

— Тәмле телеңне әрәм итеп йөрмә инде, Тәлха туган, — диде ул. — Синең үзенә бер каршылыгым да юк. Ну ләкин дә безнең колхозны сина кушуларына бер дә риза түгелмен. Син йөргәндерсең, син йөрмәсәң — кушмаган булырларие... Хәзер безнең җирне Күктавы да, Бикктавы да имәргә тотына инде. Стал бит, икмәкне безнең авыздан кисеп алалар. Нигә мин, шулай булгач, кире кайтыйм? Беләсең: семьям — ишле. Аларны бит хезмәт көне белән туйдырып булмый. Үзебезнең җир үзебездә генә булса, эпекәе дә, юк дисәң дә, тиярие әле. Шул. Монда ичмасам мин, эшләсәм, акчасын да алам. Картлык көнемдә әзрәк пенсиясе дә чыга...

Әле, болар исенә төшкәч, Сәйдәшев, күңеленнән Локман белән килешеп: «Дөрес инде анысы... — дип куйды. — Колхозларның авыр чагы иде. Ләкин Сөләйман абзый чыгып китмәде бит. Әллә аның чыгып китәрлеге юк идеме? Бар иде. Китмәде. Колхозда калды. Аттан ала да туа, кола да, диләр. Дөрес... Хәзер Сөләйман абзыйны кем алмаштыра ала инде?..»

Сөләйманның үзенең өмете Гаязда иде. Җәй саен, Гаяз укуын тукта белән, ул аны үз янында эшләтә иде. Ун классын Гаяз авылда культура йорты салган елны бетереп чыкты. Ял да итеп тормастан, бүтән

осталар белән бертигез дәрәҗәдә этисе янында эшли башлады. Сәйдәшев бер дә онытмый: шулай бервакыт, Гаязның балта эшенә һәвәс булуыннан сүз чыгып, Сөләйман әйткән иде:

— Балта һөнәре безгә эткәйдән калды. Үземнең дә Әбел-Гаязга калдырасым килә. Олысыннан булмады инде — машинага китте, — дигән иде.

«Гаяз да, балта дип, бик егылып төшмәде әле бер көн», — дип куйды Сәйдәшев.

Ике авылны бүлеп торган Үләт ярын әйләнеп үткәч, тарантас кукуруз жиренә килеп керде. Күзгә җылы кояш нуры бәрде. Камырдай күпереп яткан җир өстеннән карга өере күтәрелеп китте, алар әз генә очкандай иттеләр дә ашыга-ашыга кире төшеп тә беттеләр — карга да кара, җир дә кара иде, — шундук күренмәс тә булдылар, кыймылдаулары гына күзгә чалынып китә иде.

Тәлха Сәйдәшев дилбегә белән атына сукты, моны көтмәгән айгыр сискәнеп алга сикерде, аннары тоякларын, ыргытып-ыргытып җибәргәндәй, алга ташлап, юырта башлады. Җир өстендәге каргалар, өркешеп, ат тоягыннан ычкынып калган балчык кебек, очып-очып китәләр дә арткарак барып төшәләр иде. Алар Сәйдәшевнең җен ачуларын чыгарды. Балта осталары берьюлы онытылып, башына кукуруз хәсрәте капты. «Кукуруз... кукуруз... кукуруз...» Бу ят сүз, пленумнан активка, активтан җыелышка күчә-күчә, бала-чаганы куркытыр өчен тоткан бер папайга әйләнеп китте. Аны, әллә кайдан алып килеп, «кырлар патшасы» ясадылар, җирнең төп хуҗасы булган арыш, бодай колга әйләнде. Моңарчы Сәйдәшев кукурузны заготзерно ягындагы басуга, тау башына чәчеп килгән иде. Ләкин узган ел кемдер аны югарыга чаккан. Бик каты пешереп алдылар. Әгәр колхоз районда иң алдынгы колхоз булмаса, аны эштән үк алып аткан булырлар иде. Тиргәү белән чикләнделәр. Шуңа быел кукурузны иң яхшы җиргә чәчәргә туры килде. Чыкмый калса нишләрсең? Каргалар чүпләде, дип әйтерсеңме? Бу сүзеңә синең кем ышаныр?

Ат колхозның алма бакчасына җитте. Капкасы Миңеште ягында булганлыктан, Сәйдәшев бакчага кереп тормады. Эчтә берничә хатын эшли иде, шуларга койма аша гына дәште:

— Сабира!.. Мәликә!..

Хатыннарның барысы берьюлы аңа борылып карады.

— Исәннәрмесез! Арымый гына эшләп буламы?

— Иртәдән үк арыйлармыни әле...

— Барыгыз әле, яшьрәгегез, Сәлимҗанны чакырып китерегез.

Берсе Миңеште ягына чабып китте. Бераздан, титаклый-титаклый, Сәлимҗан килеп җитте. Койма аша чыгарга иткән кеше сыман, җәһәт кенә аскы аратага менеп басты, койма өстеннән Сәйдәшев ягына башын сузды. Тәскә-биткә чуендай кара булганга, яшьрәк чакта аны: «Чегән арбасыннан төшеп калган» дип йөртәләр иде, хәзер инде, олыгая төшкәч, просто: «Кара Сәлим» генә диләр.

— Нихәл, апай, исәнме? — диде аңа Сәйдәшев.

— Бик исән әле, Сәйдәшев агай, — диде Сәлимҗан.

— Кукурузны карга чүпли башлаган бит әле.

— Күмелми калгандыр шул, — диде Сәлимҗан.

— Тавык кебек тибеп алалар.

— Кара син аларны, ә! — диде Сәлимҗан. Ак тешләрен күрсәтеп көлә башлады, йөзе яктырып киткәндәй булды.

Сәйдәшев аның көлүен ошатып бетермичә:

— Авызыңны ерма әле, — диде. — Лучше хәзер үк мылтыгыңны ал да бер әйләнеп кайт, ичмасам.

— Монда мелкокалибр гына бит әле, Сәйдәшев агай. Аның тавышын беләсең — карга түгел үзем дә ишетмим.

— Куш көбәгең кайда соң?

— Анысын өйгә алып кайткан булган идем.

— Куш көбәкне өйдә калдырып йөриләрмени, ә? Хатынына кирәк булыр дип уйладыңмыни? Әйдә, тиз генә кайтып алып кил!

Сәлимҗан, койма аша чыгып, Сәйдәшев янына утырды.

Идарәгә урап кайткач, Сәйдәшевнең беренче эше агрономны эзләп табу булды. Агроном өченче бригадага киткән иде, аларны телефоннан тоташтырдылар. Сәйдәшев аңа кукуруз хәлен сөйләп бирде.

«Мин анда әле генә Сәлимҗанны җибәрдем. Атып булса да өркетә торсын, әйдә», — диде ул трубкага.

Трубкадан агрономның:

«Бәй, Сәйдәшев агай, көн саен басуда мылтык атып йөреп булмас бит инде?» — дигән тавышы ишетелде.

«Бүтән әмәлен тапмасак, йөрергә дә туры килер».

«Әллә кабат тырматып чыгабызмы?»

«Син анда эшләреңне җәтрәк бетер дә шул басуга кайтып кара әле. Шуннан сөйләшербез», — дип, Сәйдәшев трубканы куйды.

Шуннан соң гына бераз тынычланып өстәлгә беркетелгән кнопкага басты. Кабинетка, елт итеп, бакырдай чәчле бер малай килеп керде. Малай чагында үзе дә авыл Советы өендә аунап үскәнлектән, Тәлха Сәйдәшев йомышчы итеп өлкән кешеләрне тотмый; җиденчесен тутырып та, укымый йөргән малайларны тота иде. Ул малайлар идарәдә бер елмы, ел ярыммы эшли дә укырга керә, инде укып кеше булганнары да күп иде.

— Бар, Рәмзис апай, Фаиз абыеңны алып кил әле, — диде Сәйдәшев әле кергән малайга. — Бер аягың монда, икенчесе анда булсын, ямме!

— Я, — диде Рәмзис. Ут өереп чыгып та китте. Күз алдында «бакыр башы» гына ялтырап калды. Бу малай бик үткер иде, тап дигәнне җир астыннан да табып китерә, Сәйдәшев аны үз улыдай күреп ярата иде.

Ярты сәгать тә үтмәде, Фаиз килде. Фаиз күзлекле иде, шуның аркасында солдатка да китми калган иде.

— Син чакырттыңмы мине, Тәлха абый? — диде ул.

— Мин чакырттым, — диде Тәлха Сәйдәшев. — Кил әле, менәвында утыр әле.

Фаиз аның каршысына килеп утырды. Күзлек кисә дә, күрә-карау күзләрен кыса төшеп, Сәйдәшевкә карады. Ачулы чагы түгел икән, дип куйды. Сәйдәшевнең күзләре ягымлы иде — күз читенә кунган җыерчыгы саен йомшак нур уйный иде.

Председатель сүз башлады:

— Мин, апай, бүген синең белән теге вакытта сөйләшкәннәрне уйлап кайттым әле... — диде дә, үзе генә уйлап нәтиҗә чыгара алмаган кеше төсле, туктап калды.

— Кайсы сөйләшүне әйтәсең микән, Тәлха абый? — диде Фаиз.

— Бәй, кайсы буламыни? Комсомоллардан төзүчеләр бригадасы оештыру турында соң?..

— Ә-ә, аны әйтәсең икән, — диде Фаиз.

— Кире кайттыңмы әллә? — диде председатель.

— Нишләп кире кайтыйм, Тәлха абый! Менә сал гына төшеп житсен.

— Нигә — сал?

— Шамилләр анда бит.

— Ә-ә, — диде председатель.

Таныптагы Чумар леспромхозында күпләп урман кисү туктатылгач, Агыйделнең Таныптан түбән ягында, бигрәк тә аның «Кыр ягында», бүрәнә табу мәсьәләсе бик тә авырлашты. Чумар, Әңгәсәк урманна-

рыннан районга бирелгән еллык лимит күзгә кырып сибәрлек кенә калды. Анысын да райбашкарма комитеты бүрәнәләп тараткандай гына тарата иде. Шул сәбәпле колхозлар да, аерым кешеләр дә урманны ерак Караиделгә менеп кисә башладылар. Сал белән бергә, озын кышны да суга салып кайталар иде. Урманны быел колхоз райсоюз белән берләшеп кисте, салны да бергә алып төшәләр иде.

— Июнь урталарында кайтып житәрләр бит, Тәлха абый?

— Павловка ГЭСында гына тотылып ятмасалар.

— Иртәрәк кайтмасалар, апай, — диде Сәйдәшев. — Нух: «Озатып кына жибәрдем», — диде бит. Ярар, тагы кемнәрең бар?

— Үткән комитетта карадык. Тәгаен генә дүрт кешебез бар инде: үземнән башка — Шамил, Рәшит, Флүс.

— Ул Флүс балта тота беләмени?

— Флүсме? — диде Фаиз. — Белмәс! Өендәге әйберләрен күрсәң — шкафы, өстәле, башкасы — гел үзе ясаган.

— Һе, — диде Сәйдәшев, тел шартлатып куйды. — Бүген үлсәм, белми үләдерием. Ярар, Флүс тә булсын ди, болар гына бригадага житми бит.

— Менә эзлим инде. Балта тотучылар юк түгел түгеллеккә. Только аларны өйрәтергә кирәк. Бу турыда инде күпме сөйләшәбез. Зурлар үз яннарына алмыйлар, белми дисәң — якын да китермиләр. «Аны өйрәтимме, эшлимме?» дип кенә жибәрәләр.

— Да-а, — диде Сәйдәшев. — Шулай шул.

— Бригада төзесәк тә, үзебезгә бер өйрәтүче кирәк булачак әле. Айбавылның Локман бабай риза булмас микән?..

— Локманмы?! — дип, Сәйдәшев йөзен үк читкә борды.

— Ә нигә?

— Бер ел шулай, кайт дип, жыландай телләремне чыгарып ялындым. Юк — кайтмады, апай... Үз һөнәреңнең ыштансыз колы инде мәгәр! Бер генә атнага куеп карыйсы иде үзен клуб салучыларга бригадир итеп. Жаннарын суырырие ул! Кәжә майларын чыгарырие тегеләй! Юк бит, булмады...

— Булды! — диде Фаиз. — Кави абый белән сөйләшергә кирәк.

— Вот Кави белән сөйләшкәндә ярый. Тик анысы да бик үз сүзле нәстә инде. Эсләмгә үч итеп, чыгып китәләрмени колхоздан.

— Кеше юк, дибез. Айбавыл Гаяз кайтты бит! — диде Фаиз тагын. — Менә аны алабыз бригадага.

— Мин сөйләшеп караганием инде аның белән, — диде Сәйдәшев. — Балтага бик риза түгел — машина сорый.

— Соң, Тәлха абый, Гаяз да балта эшендә эшләмәгәч?

— Шулай да бит... Менә син дә сөйләшеп карале, Фаиз апай. Ул комсомолдыр бит?

— Комсомол. Учетка безгә керде.

— Шулай булгач.

— Гаяз ризалашса тегеләә-әй!.. Аның аша бәлки Кави абыйны да күндереп булыр иде, — диде Фаиз.

— Кави башка. Аның белән үзем сөйләшергә итәм әле. Син Гаязны күндер.

— Бүген үк барып сөйләшәм.

— Барсаң да, эш дип авызыңны ача күрмә. Үзе башламаса, кузгатма. Мин бер көн үзе башлаганнан гына әйттем. Берәр атна ял итсен. Күңеле утырсын. Күземә бик боек күренә. Жирсеп кайткандыр. Абыйсының да хәлен беләсең... Туктале! — диде ул кинәт. — Нишләп һаман путевкалар килми әле безгә?

Бу сүзләр инде Фаизга кагылмый иде. Шуңа ул — җавап та, сорау да бирмәде. Алар сөйләшкән мәсьәлә хәл ителгән, ә председательнең уе инде башкага күчкән иде.

— Мин киттем алай булгач, — диде Фаиз.
— Нәҗмиевка гына әйт әле, керсен әле.
Фаиз чыгып китте. Коридордан аның: «Нәҗмиев, сине Тәлха абый чакыра!» дигән тавышы ишетелеп калды. Баш бухгалтер Нәҗмиев стена аша гына утыра иде, муенын сузып кереп тә житте. Аның муены гына түгел, буе да озын һәм ул аны кая куярга да белми — торайтса да, иелсә дә, җайсыз кебек иде.
— Карале, Нәҗмиев, икенче кварталга путевкаларны алып бетердекме әле без?
— Бетте инде. Күптән.
— Ә Таһирҗанга алмадыкмыни?
— Нинди Таһирҗанга?
— Нинди Таһирҗанга буламыни, понимаешь? Айбавыл Сөләймән абзый малаена! Мин бит сиңа март башында ук әйткән идем. Сөләймән абзый үзе дә исән иде әле.
— Әйткән идең. Ләкин дә бит мин сиңа шундук әйттем: «Таһирга путевканы Обкомсоюз бирми», дидем. Аларның бөтенләй аерым: аларга тубдеспансер аша больницалар алып бирә.
— Әй-й, шулай бит әле! — диде Сәйдәшев һәм, үзенең хәтерсезлегенә шаккатып, башын чайкап торды. — Бу кукуруз белән башларым катып бетте инде...
Ул телефон трубкасын алды, район больницасының баш врачы Әхмәтовка шалтырата башлады.

## Унынчы бүлек

Бүген кич Гаязлар эштән иртәрәк туктадылар. Әле кояш баемаган иде — хәер, бу урын үзе дә югары, шуңа уйсу офык чите дә ерак, шуңа кояшы да моннан бик озак күренеп тора; шуңа күрә авыл халкы элек-электән кояш баюын шушы тауга карап билгеләгән, ураза вакытларында әби-бабайлар тау түбәсеннән иң соңгы нур китми торып авыз ачмаганнар.
Гаяз күтәрелеп караганда, кояш әле авыл өстеннән дә китмәгән, шулай да нәкъ Агыйдел кереп югалган тугайга турылап төшәргә җыенган, ләкин әле берәр сәгатьлек юлы бар иде.
Гаяз балтасын өрлеккә чабып куйды.
— Ярый, төпчек абзый, миңа туктарга вакыт. Өсне дә алыштырып киләсе бар, — диде.
— Әйдә, коралларны җый инде алай булгач. Бүгенгә житәр. Минем дә алмаларга төтен саласым бар, — диде Локман.
Ул, көндез үк әле, Фаягөл әбигә кичке ашны алданрак житкерергә, юынырга суны да шул тирәләргә җылытып куярга кушкан иде.
Гаяз коралларны, ящигына салып, өйгә алып китте. Локман, эсседән башына бәйләгән яулыгын чиша-чиша:
— Бер онгайдан юынырга да алып чык! — дип калды.
Гаяз коралларны чолан ишек төбенә куйды да су алырга өйгә керде.
Тәрәзәләренең өчесе дә көнчыгыш якта булганлыктан, Нухлар квартирасына кояш иртән торып киерелгәндә генә бер карап ала, калган озын көнен ул чолан ягында үткәрә, ә баюын стена аша торган күршеләр ягына чыгып баййый һәм, табигый, Нухлар ягында бик иртә куз бәйләнә иде; шуңлыктан, Гаяз кергәндә, алар инде ут алганнар: чоланда бер, кухняда бер, бүлмәдә бер лампочка янып тора иде. Электр энергиясен счетчиксыз гына тотканлыктан, лампочканы кызганмаганнар — чоланда 100 ле, кухня белән бүлмәдә 150 ле яна, тик Сәмигулла бабай яткан тәрәзәсез мич артында гына ут юк иде. Ул

почмакны мич тигезлегеннән такта белән генә бүлгәннәр, тактасы түшәмгә җитмәгәнгә, өстәге ачыклыктан эчкә ут яктысы төшкән, шул яктылыкта электр шнурының очы күренеп тора, ләкин патроны юк, аны өзеп алып, шнурның ике чатын ике якка аерып куйганнар иде. Сәмигулла бабайның тавышы-тыны килми, йоклап киткән күрәсең, Фаягөл әби белән ике малай зур якта, ә кухняда — Нух белән хатыны Фагыйлә генә: Фагыйлә токмач кисә, Нух, сыңар күзе белән бик җентекләп, бал мичкәсен карап утыра иде.

Фагыйлә, бүген беренче көн, иртәнге сменада эшләп кайткан һәм, беренче көн, кич өйдә иде. Гаяз да, бүген беренче кабат, күзләрне кисеп кергән ут яктысында аермачык итеп бу хатынның иренә пар түгеллеген күрде: бу хатын әле шушы яшендә дә Нух янында гүзәл бер кыз кебек иде. Нух белән Фагыйләнең ирле-хатынлы икәннәрен белгән көннән үк Гаяз аптырап: «Бу апа моңа, шилә, яратып чыкты микән?» дип уйлаган иде, шуннан бирле бу хәл аның башына сыймый йөри. Һәм менә ул әле тагын: «Юк, яратып чыкмагандыр», — дип куйды.

Фагыйлә Нухка инде күптән — сугыш вакытында — чыккан иде һәм, әлбәттә, яратып чыкмады, үз егете сугыштан әйләнеп кайтмагач, аны: «Олы булса булыр, я ирсез калырсың», — дип, әти-әнисе көчләп бирде. Бу да, үзенә күрә, үткән сугышның бер фаҗигасе, ләкин моны Гаяз белми иде.

Фагыйлә, токмач кисүеннән туктап, Гаязга карады, йөзедәй ягымлы тавыш белән:

— Керә башласагыз да ярый инде, — диде.

— Хәзер. Юынып алабыз да, — диде Гаяз.

— Хәсәншин, ташлале шул мичкәңне, су таманлап бир әле, — диде Фагыйлә.

Үз әтисенең дә исеме Нух булганлыктан, иренә Фагыйлә исеме белән дәшә алмый, фамилиясе белән генә дәшә иде. Монысы да әллә ничек кызык та, сәер дә яңгырый иде.

Нух мичкәсен идәнгә утыртып, чоланнан салкын су алып керде. Электр плитәсенең берсендә миски белән аш, икенчесендә су кайнап утыра иде, Нух кайнар суны чәйнектән чиләккә агызды.

— Таманлыгын үзең карале, апай, — диде ул.

Гаяз суга бармагын тыгып карады.

— Салкынрак. Әз генә агыз.

Шул вакыт Земфира да кайтып керде.

— Мин кайттым, — диде ул.

— Бик әйбәт, кызым, хәзер аш житешә, ашап китәрсең, — диде әнисе.

— Ә сез?..

— Барып булмый инде, — диде Нух. — Эш килеп чыкты. Ятканчы бетерергә кирәк. Әниеңә дә иртәнге сменага барасы.

— И-и... — диде Земфира. — Сезнең шул булыр инде.

Монысын ул әти-әнисенең күңеле булсын дип кенә әйтте. Эченнән үзе аларның бармавын тели иде. Ул әтисенең гадәтен белә: клубка барып утырдымы — йоклый. Спектакль-мазарда бер хәл әле: баш өлешен карый ала, ә менә кинода — ут сүнеп аппарат гөрли башлау була — ул да йоклап китә. Боларны ул соңыннан үзе дә сөйләп көлә, ләкин берсендә, кино өзелеп, ялгаган арада, аның гырылдап йоклавын күргәч, бөтен клуб күтәрелеп көлде. Төрле яктан:

— Абзый, икенче килгәндә түшәк-юрганыңны алып кил! — дип кычкырып уяттылар. Земфира бик гарьләнде.

— Синнән түгел, соңыннан кеше миннән көлә, әнә йомшак түшәгең, өйдә йокла, — дип, әтисен ул клубка йөртмәс булды. Бүген чсә аларны, әтисеннән бигрәк, әнисе өчен чакырган иде.

Фагыйлә, күзен тутырып, иренә карады:

— Хәсәншин, әллә дим, урап кына кайтабызмы? Озак тормабыз, кереп кенә чыгарбыз, Фәридә Кудашевага күз кырые белән генә карап.

Нух, анын сүзен авызыннан өзеп:

— Нәрсәсенә карыйсың инде анын? — диде. — Уфада чакта телевизорда күрдем: бер карар җире дә юк. Радиодан да — көн саен булмаса — ике көнгә бер җырлатып торалар.

Земфира җавап бирмәде, Гаяз алдында әтисе өчен оялып, бүлмәгә кереп китте.

Гаяз да иелгән җиреннән турая алмый торды. Үз ана теленнән, үз халкының Агыйдел дәрьясыдай мөлдерәмә тулы моңыннан аерылып яшәгәндә, аның ялгыз күңеленә җыр иптәш булды — берәр көйне авызына алдымы, ул аның телгә килеп кунган бер куплетын эченнән генә өзлексез җырлап йөри, ахырда бу куплет, — хәтта күп вакытта ярты гына куплет, — күңеленә шул тикле сеңеп керә иде — җырдан туктагач та әле, сулыш кебек, йөрәк тибеше кебек, сизелеп тора иде. Шундый чакларда ни өчендер Гаязның тел очына гел: «Әллә нилэр бирер идем аһ дигән сүзләреңә», дигән сүзләре, ә колак яфрагына, кубәләктәй җилпенеп, Фәридә Кудашеваның тавышы килә иде, һәм ул, Кудашеваның шушы көйне җырлаган тавышын ишетү өчен генә дә әллә ниләр бирердәй булып, үз теленә, үз җырына — капланып эчсә дә туя алмастай булып, сусап кайтты...

Гаяз чыгып киткәч, Фагыйләнең күзе чөйдәге тастымалга төште.

— Земфира, бар әле, кызым, чыгарып бир. Тастымал да, сабын да алмаган бит.

Гаяз инде яңа өй ягына чыгып бара иде. Кычкырып дәшкәнгә артына борылып, Земфираның йөгереп килгәнен көтеп торды.

— Онытkансыз, — дип, Земфира аның кулына сабын, тастымал тоттырды.

— Чыккач та искә төште төшүен — кире кермәдем инде. Рәхмәт, — диде Гаяз.

— Үпкәләдегезме әллә, Гаяз абый?

— Минме?.. Нәрсәгә?..

Земфира ачынып:

— Безнең әткәй шулай инде ул, — диде.

Гаяз моңысына да бер сүз дә әйтмәде — болай да озакладым, көтәләр дип, төпчек абыйсын уйлап куйды, күз алдына аның тояктай каты аркасы килде.

Земфираның әле өс алыштырасы бар иде, ул да көндез әйтергә оныткан сүзен, онытылганчы дип, әйтергә ашыкты.

— Мин сезгә урын алып торам, кергәч үк алга үтәрсез.

— Ярый, — диде Гаяз.

Локман, чынлап та, юынырга күлмәген салган, күкрәген кашып, Гаязны көтеп тора иде.

— Озакладың тагын...

— Әйдә иел, — диде ана Гаяз.

Юынгач, ул ашарга кереп тормады: аның кабат Нух янына керәсе килми, Нух белән бер өстәлдә ашыйсы килми иде. Аннары, ашап-нитеп торса, концертка соңлавы мөмкин. Аның әле Минеште чыгып кайтасы бар, киенәсе бар, якын дисәң дә, күрше авылга барасы бар. Бер сәгатьтә өлгерәме, юкмы? Ә Таһирҗан?

Ул бер көн Гаяз кайту шатлыгыннан гына җиңеләеп аягына баскан икән. Соңыннан егылды. Соңыннан авыр ятты. Бүгеннәрен генә хәле яхшырды. Әгәр хәле тагын авырайса, концертка барып булмас. Концерт дип, чирле абыйны ташлап китмәм бит. Инде кайттым, инде үз туфрагымда, үзебезчә концерты да булмас түгел, булыр. Фәридә Ку-

дашева да килмәскә китмәс. Тагын бер килер әле. Килмәсә Уфасыннан җырлар. Казаныбыз җырлар...

Әллә нинди көн булды ла бүген. Авыр көн булды. Иртәдән бирле тәннең ватылып торуы... Халидәнең үзе кайтасы урынга — хаты... Земфирасы... Инде килеп — концерты...

Ләкин барысы янында да иң көтелмәгәне Земфира белән очрашу булды. Теге көнне клубта күргәннән соң Земфираны ул янадан күрмәгән иде. Хәер, аннан соң әле аның Кырлачка да барганы булмады, ә Земфираны бер-ике тапкыр клубның үзе турындамы, мөдире турындамы сүз чыгып кына исенә алды. Ләкин Нухның кызы булыр дип уена-башына да китермәгән иде.

Бүген көндез, ашарга керсәләр — ни күзе белән күрсен, — Земфира табын әзерләп йөри, ә Нух, «бик белеп тор син, энем!» дигән сыман, куәнәтә Гаяз өчен әйтте:

— Монысы минем кызым инде. Быел институтка кертәбез. Бүген генә Уфадан документларын биреп кайтты.

Земфира моны бер дә яратмады.

— Әллә кирәм, әллә юк, сөйләнеп утырасың, — диде.

— Нигә? Стажың җитә. Ни кирәк тагын! — диде Нух. Кызын Гаязлар янына ашарга чакырды: — Әйдә, утыр әле монда.

Ләкин Земфира утырмады.

— Без соңыннан ашарбыз. Әле суга барам, — дип чыгып китте.

Кучеп менгәннәр өчен иманлек башында артезиан коесын әле генә казып яталар, шуңа суны чишмәдән төшеп алалар иде.

Аштан соң Локман, көндәгечә, Нух белән сөйләшә-сөйләшә чәй эчеп калды, Гаязга алар сүзе, башыннан ук белмәгәч, аңлаешсыз, кызыксыз иде, ул ашын гына ашады да болдырга чыгып утырды. Как тау өстендә, әләгер урын таба алмыйча, сәхрә җиле уйнап йөри, ә болдырда аеруча рәхәт иде.

Земфира да, җилдәй сызылып, чишмәдән кайтып җитте. Гаяз аңа, читкәрәк шуышып, юл бирде. Ләкин шундук, сикереп торып, каршына төште, көянтәсеннән чиләкләрен алды.

— Кая куярга?

— Хәзер, — диде Земфира. Алдан йөгереп менеп, чоландагы бакны ачты — Халидә апа сезгә сәлам әйтте.

— Ул да кайтты мәллә?!

— Әллә бик көткән идегезме?

— Бу атнада кайтам дигән иде бит.

— Анда әле — кызык хәлләр: бер поварлары юкка чыккан, Халидә апаны җибәрмәгәннәр — шунын урынында эшләп калган, — диде Земфира һәм, өйгә кереп, аннан хат алып чыкты. — Мена хат җибәрде.

Конверт ябыштырылган иде. Гаяз аны ертып ачты да, ишек яңагына сөялеп, укый башлады.

Хатны Халидә җибәрсә дә, үзеннән күп язмаган — Җәмилә апасыннан хат килүен әйткән дә, «Мена шуны укыгыз әле, Таһирҗанны күндерсәгез иде», дип кенә куйган. Апасының хаты озын гына — дәфтәр бите тулы — һәм бөтенләе белән Таһирҗан өчен иде.

Җәмилә хатында үзләре торган Бәйрәм-Алидә туберкулез авырулылар өчен санаторий барлыгын, бөтен Рәсәйдән шунда килүләрен («Ирем дә килгәндә шундый булган, барып җитәлмәс дип калганнар»), кайнар чүл һавасында тәмам савыгып китүләрен («Ирем хәзер тап-таза»), кире кайтырга ярамаганнарының эшкә урнашып бөтенләйгә торып калуларын («Минем ирем әнә шундый. Рәсәйдә торырга ярамый, кайтса чире яңадан башлана» дип) бик белеп язган иде.

Гаяз, укып бетергәч тә әле, ишек яңагына сөялгән килеш, хаттан күзен ала алмый торды. Битенә гүя авыру үпкәләрне сау иткән шифалы эссе һава килеп бәрелгәндәй булды. Рәхмәт, Халидә! Син кайгырткан-

сың инде моны. Җәмилә апа, сиңа да рәхмәт! Яхшы сүзең — алып киткәннән дә артык, бик рәхмәт...

Ул аның төсен күз алдына китерергә итеп карады. Ләкин күз алдында, чүл өстендәге эссе рәшә кебек, ыгы-зыгылы пристань да ак пароход кына тирбәлә иде. Кара, «Тукай» пароходы бар иде бит әле. Җәмилә апа шуның белән китте бит. Шул елны «Тукай» үзе дә соңгы елын йөрде шикелле. Аннан, Агыйделгә баткан кебек, юк булды. Шул китүдән Җәмилә дә кайтмады — Төркмәнстанда төпләнеп калды. Әле хатында: «Июньдә отпускыга кайтабыз, Таһирҗан әзерләнеп торсын, риза булса, үзебез белән алып китәрбез», — дигән иде.

Кулда барлыгы да сизелми торган бу хат тау чаклы сөенеч алып килгәндәй булды, абыйсын уйлаганда башыннан китми торган әллә нинди уйлар тәтендәй таралып, өмет күгенә якты нур кабынды, һәм әле, өенә кайтып барганда, исенә тагын шул хат төште. Гаяз аны, җан кебек күргән бер шатлык сыман, кесәсе аша сыйпап куйды.

Таһир урыныннан торган, өстәл янында, әйләндергәләп, фотоаппаратын карап утыра иде (авыргач өйрәнгән шөгыле инде). Гаяз аның караватына күз төшерде — урыны да җыелган иде.

— Нишләп озаклыйсы иттең, апай? Концертка соңлыйсың бит, — дип каршы алды аны Таһир.

— Барсам өлгерәм әле, — диде Гаяз. — Хәлең ничек соң үзеңнең?

— Бүгенгә хәл ярый, апай.

Гаяз чалбар кесәсеннән хат чыгарды.

— Менә сиңа бер хат алып кайттым, бәлкабзый. Шуны укып кара әле. Халидә җибәргән.

Халидә исемен ишеткәч, Таһирның кулы дерелдп башлады һәм ул тиз генә, Гаяз күргәнче дип, ике кулын да өстәлгә куйды.

— Син мин укыганны көтеп торма, киенә башла, урынсыз калырсың ату, — диде ул.

Гаяз чишенеп-киенгән арада, Таһир хатны укып чыккан иде инде, ләкин — сүзгә дә, сергә дә каты иде ул — ашыгып фикерен әйтмәде. Гаяз: «Я, ничек?» дип әйләнеп караганда, хатка янадан текәлгән, әллә укып, әллә укымый утыра — йөзенә ни кайгы, ни шатлык типмәгән-кагылмаган, бөтенләе белән сынга әйләнгән сыман иде. Бераздан гына исенә килеп:

— Әткәй мәрхүм дә, уләреннән бер аймы элек, шул Бәйрәм-Алине ишетеп кайтып, тоже бик кызыгып сөйләгән иде, — диде.

Ул Гаязга яны белән утырган иде һәм әле дә аңа борылмады, хатта йөзен дә күтәрмәде. Шунда Гаяз аның күз очында гына елтыр эләп торганын күрде, һәм аңа шунда гына барып житте: абыйсының күтәрелеп карарлык та көче юк, аның күңеле тулган — ялгыш кына башын күтәрде исә, түгелеп китәргә тора иде.

— Я, нигә инде, бәлкабзый? — диде Гаяз. — Җылап үзеңә генә начар итәсең бит. Үлгән артыннан үлеп булмый инде.

— Таза булсаң — булмый да бит...

Хәзер аңа каты гына бәрелеп, юк-бар уйларын бәреп чыгарырга кирәк иде. Гаяз шулай итте дә:

— Әллә нилэр сөйләп, ачуымны китермәле, яме,— диде ул. — Үзеңне үзең бетерәсең. Яшәгәннәрне уйларга кирәк.

Каты сүз Таһирны да айнытып җибәрде.

— Ачуланма, апай. Авыру күңеленә нилэр килмәс, — диде.

Локман алма бакчасында казына иде. Иелеп эшләгәнлектән, ул Гаязның өйләреннән чыгып китүен күрми калды. Билен турайтып караса, Гаяз инде көймәсен ярдан этеп жибәргән, ишкәккә утырып маташа иде. Менә башкалар да, төркем-төркем булып, алар турыннан

үтеп китте. «Концертка инде. Концерт дисәң, чукынып баралар! Элгәре җыенга шулай төзәнеп-ясанып йөрерләр иде», — дип куйды Локман. Аннары, үз балалары исенә төшеп, ашыгып өенә керде. Яңа өйләнгән улы белән килене, җиткән малае белән кызы әле булса китә алмаганнар иде.

— Бер бетмәгән бизәнү булыр икән! Соңлыйсыз бит инде, алла бәндәләре! — диде Локман. Ишек төбеннән узмыйча гына, кире борылды: — «Китсеннәр инде, яу басылсын...»

Ниһаять, балалары җыенып чыкты. Инде аларның берсе дә уртәлми, өзгәләнми; артларыннан тузып калган өйләре дә, алтмышка житкән әниләре булгач, күңелләрен борчымый иде. Алар бакча сукмагыннан, тезелешеп кенә, тату гына төшеп киттеләр. Алар да күздән югалгач, Миңеште буенда кеше бетте, су өстенә авылдан төшкән кулагә генә ятып калды.

Локман, сәнәгенә таянган килеш, тора бирде — гомер үтүгә исеакылы китеп, башларын кагып торды: «Нишләп үтмәсен ул гомер! Үтәр дә шул! Җиде бала үсеп житсен әле»... Аннан соң ул, әкрен генә артына әйләнеп, өенә карады. Хәтеренә Гаяз әйткәннәр килде. «Күрми торып күргәч, искерүе күзгә нык ташланадыр шул», — дип куйды. Әзмәвердәй егетләр үстереп чыгарган өй, чынлап та, бар тазалыгын шул балаларга биреп бетергән сыман: тәрәзә астына сипләп кыстырылган яңа бүрәнәләре дә искесеннән аерылмый иде. «Илдус быел солдатка китсә, какрас черегән өйгә генә кайтып керә икән, — дип уйлады Локман. — Кайту белән өй салаламыни ул?.. Минем дә кулдан көч китсә?.. Тазалык бүген бар, иртәгә юк ул. Сәмигулла карт әнә былтыр таш кебек иде, быел — чыкмаган җаны гына калган. Үзем исән-таза чакны, әллә дәрт итеп карыйм микән?..»

Ләкин мондый уй аның күңеленә, кешеләргә өй салган саен, килә дә соңыннан китә торган иде...

### Унберенче бүлек

Концерт беткәч тә әле, халык кайтып китәргә ашыкмады. Фәридә Кудашева әллә ничек һаман сәхнәдә торадыр, һаман да җырлыйдыр сыман, һәм кешеләр дә әллә ничек, җырдан айнып житмәгән килеш, кара төндә таралышып, җырсыз өйләренә кайтып китүдән шикләнәләр сыман иде. Артистлар клубтан чыкканда фойе аша үтәсе булганлыктан, Кудашеваны, кая әле дип, тотып карар дәрәҗәгә житкән халык фойега чыгып тулды. Һәм сәхнә ишегеннән ул күренү белән, барысы да тын калып, шул якка карадылар. Кави белән хатыны урынны сайлабрак басканнар иде. Ләкин, артистлар читтәнрәк юл алгач, Кави түзмәде:

— Каягыз әле, иптәшләр, без концертта да артта утырдык, житәр, — дип, кукрәтеп әйтте дә, халыкны ике якка егып салгандай гына итеп, артистларның алдына ук килеп басты. Фәридә Кудашева ана, хушбуй исләре бөркеп, карап үтте.

Артистларны халык юл биреп озатты да, алар чыгып киткәч, артларыннан үзләре дә кузгалды — бер-берсенең аркасына жылы куллары терәп, ишек авызына барып өелделәр. Бар ямь бетте. Күңелләрдә генә калган җыр да, ишектән үткәндә, кысылып имгәнә сыман иде.

Кави белән хатыны өемнең кап-уртасына эләккәннәр, үзләрен этеп алып барганга карышмыйча гына, Гаяз турыннан узып киттеләр. Кави, үтеп киткәч кенә, Гаязны искәреп артына борылды:

— Әйдә, апаң, кайтасыңмы?

— Юк әле, — диде аңа Гаяз.

Алар Фаиз белән бергә торалар иде. Фаиз да, йөргән кызының чыгып баруын күргәч, Гаязга кул бирде:

— Ярый, бүгенгә исән булып тор. Иртәгә сөйләшкән вакытка барып житәрмен.

Ул кызын күрше авылга озатып куярга ашыга иде. «Анда хәтле озатып йөрми инде ул аны, илтеп кенә куя, — дип уйлады Гаяз. — Мотоциклы бар, тырылдатып илтте куйды».

Гаяз Земфираны көтеп калды. Земфира, концерт бетү белән, артистлар бүлмәсенә кереп киткән иде. «Әйдә, якыннан күрерсең»,— диде, аны да чакырган иде, ләкин Гаяз кермәде: күрдем бит инде, диде. Алар иң алда утырдылар, Фәридә Кудашева алар каршында гына җырлады. Аның өстендә үзе җырлаган «Уел» көедәй озын ак атлас күлмәк иде, бу күлмәк белән аның буе да нәзек һәм озын күренә иде. Гаяз күңеленә ул әнә шулай сеңеп калды. Инде тиз генә онытылмас — радиодан тавышын ишеткән саен, җырларын искә төшергән саен, күз алдына да гел әнә шул бүгенге Кудашева килеп басачак. Һәм Гаязның аны башкача итеп күрәсе килмәде, шуңа артистлар фойедан үткәндә бер читтәрәк торды.

Земфира озак көттермәде. Алар клуб караучы апа белән бергә чыктылар. Ул ана, утларга күрсәтеп, нидер аңлатты да туп-туры Гаяз янына килде. Килешкә үк:

— Әнә тегендә бер егет тора, арттан иярә-нитсә, әллә нәрсә уйламагыз, — диде.

Ул егетне Гаяз, күз кырые белән генә, бая ук шәйләп алган иде. Ләкин, халык чыгып бетсен әле дип көтеп торучылар бер ул гына булмаганга, игътибар итмәде, Земфира әйткәч кенә борылып карады, һәм шунда нигәдер, ярамас эшкә тотынгандай, эче пошып китте: стена буенда Флүс басып тора иде.

Алар чыгарга юнәлделәр. Флүс тә сөялгән стенасыннан аерылды.

— Калмас инде ул! — диде Земфира.

Флүснең калу исәбе юк иде. Ул бүген, кичә генә алган костюмнарын киеп, Земфираны озатып куярга җыенып килгән иде. Их, озаттырсамы?.. Бүген инде ул җебеп тормас иде, билеңнән генә, менә шулай итеп кысып алыр иде дә... Үптермәсен дә ди әйдә...

Ул концерт алдыннан Земфира янында буш урын күргәч: «Миңа алып куйганмы әллә?» дип бөтенләй каушап төште. Ләкин Земфира: кешесе бар гына диде.

Менә кем булган икән аның кешесе! Бу сине, апаем, билеңнән генә кысып калмас — бу сине май йомарлагы итәр. Ух! Үз тиңем булсамы — мин аның белән ничек сөйләшергә белер идем әллә!.. Юк, моны җиңү — ай-яй! Кави абзый төсле дә булса... Флүс, көнләшүдән кара көеп, тешләрен кысты, янсын әйдә дип, тәмәке кабызды.

Алар урамда иде инде. Яктыдан караңгыга чыккач, Земфиралар чокырга төшеп киткәндәй булдылар. Флүснең иң курыкканы шушы иде. Ул: «Китәләр, калам бит!» — дип уйлады һәм, киткәнне тәмәке төтенедәй суырып алырга житеп, төн карасына дәште:

— Земфира!..

— Менә, әйткән идем бит! — диде Земфира һәм, Гаязга бара торырга кушып, тәмәке утына каршы китте.

— Нигә кычкырасың инде, Флүс? — диде ул.

— Земфира... Бер генә сүз.

— Я, нәрсә?

— Тыкрыктан соң да ул озатамы?

— Флүс, мин сиңа бер әйткән идем бит инде: минем егетем бар...

— Ул түгелдер бит инде егетең?

— Шул! — диде Земфира һәм, ялкындай кабынып, кире йөгерде.

Бәхетенә, Гаяз атлый торган, алар сүзен ишетер арада түгел иде.

Бераз юлны сүзсез үттеләр.

— Сине мин тартып алгандай килеп чыкты инде бу, — диде Гаяз. Ул баядан бирле Флүсне уйлап килә иде.

— Аның өчен кем тартып алса да — барыбер. Мин аңа күптән әйткән. Аңласын иде.

— Егет жәл, — диде Гаяз.

Земфира, уртәлүе кайтып, көлеп җибәрде:

— Сез дә бер-берегезне жәлләрсез икән!

Гаяз да сүзне көлкегә борды:

— Кызлар жәлләмәгәч — нишлисең бит!

— Кызлардан жәлләтеп торыр идегезме, Гаяз абый?

— Аның хәленә төшсәң...

Клубта Флүс, ул әйләнеп карагач, күзен читкә алган иде. Сер бирмәве ярый, дип уйлаган иде Гаяз, ләкин соңыннан егет сер бирде. Нык бирде. «Алай ярамас иде, Флүс. Кызлар сина бер өзеп әйттеме — сагыз булма инде син аларга, туганкай. Күкрәгеңне бирмә. Шулай!» һәм Гаяз аны чын-чыннан кызганып куйды.

— Минем андый хәлгә каласым килмәс иде, — диде ул.

— Андый хәлгә сезнең калган да юктыр.

— Шуңа мин яратырга да куркам.

— Ышандыра күрмәгез тагы, — дип көлде Земфира.

— Чынын әйтәм.

— Ә Халидә апа?

— Халидәме?.. — диде Гаяз. — Халидә — башка!

Ул тынып калды. «Әллә яратмады инде?» — диде Земфира һәм, Гаяз авызыннан көтеп тә сүз чыкмагач, үкенә үк башлады: «Ник сорадым, минем анда ни эшем бар иде?..»

Гаяз, инде бөтенләй сөйләшмәс булды дип торганда, тагын көрсенеп әйтеп куйды:

— Халидә — башка!

— Каты серле икәнсез, Гаяз абый.

— Каты серледән түгел. Бернинди сере дә юк аның. Без Халидә белән бергә үстек.

Ул тагын сүзсез калды, аннары тирән сулап:

— Бердәнбер мәхәббәтем дә, бәлки, ул булгандыр, — диде. — Тик моны мин бик соң аңладым...

Алар ике ягы да читән тыкрыктан тау битенә килеп чыктылар. Монда юл түгел — монда сукмак кына иде. Юл икенче тыкрыктан, иске зират янынннан китә. Ләкин халык заготзернога аннан йөрми — моннан йөри. Сукмагы да, әз генә урап, сөзәгрәк җирдән менә иде.

— Әйдә моннан! — диде Гаяз, һәм алар өскә төртеп торган йомры таудан туры менеп киттеләр. Земфира биек үкчәле туфлие белән артка кала башлады. Гаяз, туктап, аңа кулын сузды:

— Бирегез әле кулыгызны, бик җайсыз да менәсез.

— Әллә кайдан алып киттегез бит, — диде Земфира. Үрелеп Гаязның кулына тотынды.

Алар артыннан тагын кемнәрдер менеп килә иде. Алар яшь кенә ике егет булып чыкты. Йөгереп диярлек менгәнлектән, икесенең дә сулышы капкан, гөжләтеп тын алалар иде. Шулай да берсе, узып киткәндә:

— Бәй, кемнәр болар? — дигән булып, артына әйләнде, фонарен яндырып, тикшереп алды. Гаязның нигәдер моңа кәефе килеп:

— Нәрсә, әллә кызыңны югалттыңмы? — диде.

Теге егет аңа:

— Безнең кулга эләккән кыз югалмый ул! — дигән җавап ташлап китте.

Тауга менгәч, туктап тын алдылар.

Заготзерно үзе күренмәсә дә, яктысы, сыек кына булып, караңгы күккә төшкән, һәм шул яктылыкта Земфиралар яшәгән тау өсте аз гына беленеп тора иде.

Аннары алар, төп сукмакка чыгып, басу җиренә керделәр. Юл катканак, салынып бетмәгән иде әле. Тау өстен басу иткәч, бер уңайдан туры юлны да сөреп ташлаганнар иде, ләкин халык яңадан салып куйды, шуннан бирле юлны сөрә торалар — халык аны ел саен сала тора, чөнки моннан заготзерноога якын, нибары ярты гына чакрым иде.

— Халидә турында нәрсәдер әйтмәкче булган идегез, — диде Гаяз. Земфира үзе дә, басуга кергәннән бирле, бу турыда ничек сүз башларга белми бара иде.

— Халидә апа үзе бернәрсә дә язмаганмы? — диде ул.

— Ю-ук. Язмаган, — диде Гаяз. Аның күңеле нидер сизенгән иде, шуңа әле туп-туры: — Әллә берәр нәрсә булганмы? — дип сорады.

— Зәкиев аңа пычрак уй белән йөри. Безгә килгән саен, авызында Халидә апа.

— Нәрсә ди соң ул?

— Әйтә инде, — диде Земфира уңайсызланып. — Мин тыңлап тора алмыйм бит инде андый сүзләрне... — Һәм шуннан соң ялварып диярлек: — Гаяз абый, Халидә апа кайткач, әйтегез әле, бәйләнмәсен әле шул гыйбрәт белән, — диде. — Ух! Центнер ярым гәүдәсен түгел, йөзен дә күрәсем килми.

— Рәхмәт, Земфира, күңелегез яхшы икән, — диде Гаяз.

Ул аның кулын кысты һәм — башка җибәрмәде.

*(Ахыры бар.)*

## СЕЗ ҮЗ ИСЕМЕГЕЗНЕҢ МӘГЪНӘСЕН БЕЛӘСЕЗМЕ?

Татар халык исемнәренең күбесе — гарәп һәм фарсы сүзләре. Ләкин ул сүзләр шулкадәр нык үзләштерелеп киткән, без аларның алынма сүзләр икәнлекләре турында уйламыйбыз да. Ә уйлап-тикшереп карасаң — аларның һәркайсының үз мәгънәсе бар бит. Журналыгыз битләрендә татар исемнәренең мәгъналарен аңлатып бирсәгез әйбәт булыр иде.

Соңгы айларда редакциягә эчтәлекләре, нигездә, менә шушындыйрак булган берничә хат килде.

Укучыларыбызның теләкләрен искә алып, бу санда без халык арасында аеруча киң таралган исемнәрнең мәгънәләрен урнаштырабыз.

Башта шуны әйтеп үтик: ул исемнәрнең мәгъналарена игътибар ителми бездә. Шулай ук язылганда да аларның күбесе үзебезнең телгә җайлаштырып, үзгәртеп языла. Кыскасы, алынма исемнәр бездә бары тик атама, кеше исеме буларак кына гамәлдә йөри. Шунлыктан кайбер исемнәрнең мәгъналәре сәеррәк булу укучыларны аптырашта калдырмас дип уйлыйбыз.

Асия — тегермән.
Бакый — мәңгелек.
Бану — бикә, ханым, кәләш.
Бари — юктән бар итүче.
Биби — хуҗа хатын.
Борһан — дәлил.
Бәдигъ — искиткеч гүзәл.
Банат — кыз бала.
Бәсим — ачык йөзле.
Басыйр — күрүче, аңлаучы.
Бәхтияр — бәхетле.
Бәшир — сөендерүче, куанычлы хәбәр китерүче.
Бәян — аңлату, төшендереп бирү.
Вагыйз — үгетләүче, димләүче.
Вазыйх — ачык, аңлаешлы.
Вакыйф — аңлаучы, эшнең төбенә төшенүче.
Васфи — сыйфатка бәйләнешле әйбер.
Васыйл — ирешүче, барып җитүче.
Вәли — ия, хуҗа.
Вәсилә — чара, юл, әмәл.

*Гамил Афзал*

●

Дан-дәрәҗә теләмим мин,
Нигә миңа дан-дәрәҗән!
Йөз жыермый ачы җилгә
Ачык тора киң тәрәзәм.

Тыныч картлык теләмим мин,
Нигә миңа тыныч картлык!
Далаларда давыл кичеп,
Җилгә каршы бару артык.

Кышлар язны сагынсын, дим,
Сулар ярга кагылсын, дим;
Йөрәк янсын, яра калсын,
Ялкын шигырь язылсын, дим.

## Ышаныгыз

*Җәлилчеләр тавышы*

Освенцимда үскән гөлләр сөйли, —
Көлдә үскән гөлгә күз салыгыз,
Бухенвальдтан искән җилләр сөйли —
Ышаныгыз!

— Без мыексыз яшь егетләр идек,
Юк иде әле кызлар кочканыбыз,
Беренче кат хәрби кием кидек,
Ышаныгыз!

Күкрәк белән утны каршы алдык,
Тимер ташкын иде дошманыбыз,
Кырык тапкыр камалуда калдык,
Ышаныгыз!

Без кыюлар, комсомоллар идек,
Булмады һич артта посканыбыз,
— Яки җиңү, яки үлем! — дидек,
Ышаныгыз!

«Хейнкель»гә винтовкадан аттык,
Елга булып акты ал каныбыз.
Киртә булып танк астына яттык,
Ышаныгыз!

Ут эчендә күп тайдык һуштан,
Таштан каты иде вөҗданыбыз.
Ярым үлек хәлдә алды дошман,
Ышаныгыз!

Байрак тотып кайталмадык илгә —
Җан сыкранып көн-төн пошканыбыз.
Шәһит булып яткан соры күлгә
Ышаныгыз!

## Шәрип урманы

> Тирә-ягын яшел куак була,
> Шау урманнар үскән як була;
> Урман шавы төшләренә кереп,
> Уйландыра торган чак була...

Әллә нәрсә булды бу күңелгә,
Төмердә юк болай булганы.
Сагындыра мине
айлы төндә
Шаулап торган Шәрип урманы.

Гирбәлешеп торган чыршыларга
Куна иде кунак җырчылар,
Шулар җырын тыңлап, күңелләрдә
Тараладыр күпме борчулар...

Үзем генә йөргән сукмакларда
Баштан сыйпап калды ботаклар.
Кайтып килсәм,
каршы алыр кебек,
Таныр кебек таныш усаклар.

Урман, урман,
Аланнарың ачык.
Ярдәм көтеп яшел агачтан,
Үги ана каһәреннән качып,
Ятим кызлар кереп адашкан.

Бабайларның,
Печән чапкан чакта,
Егет чагын күргән чаганның
Төпләрендә генә посып ята
Әкиятләре үткән заманның.

Анда гына көләч яз кебек тә,
Анда гына мәкер аз кебек,
Анда гына айлар аяз кебек,
Анда гына күңел саф кебек.

Сандугачлар килә,
Җыр яшәрә,
Яз гөлләре керә әсәргә:
Минә киләем инде таш шәһәргә
Шул урманны сагынып яшәргә.

●

Кояш нуры сенеп безнең канга,
Ал тамырлар буйлап йөгерде.
Яшәү ямьле булган бу заманда
Шагыйрьләр дә озын гомерле.

## Тәнкыйтьчегә

Ник язасың, дисез, юк-барны,
Ник чокыйсың, дисез, чүп-чарны:
Шул заманның төрле чүп-чарына
Түзәп атам инде укларны.

## Авылда авырып яту

Тау артына китеп кояш бата,
Күреп туймас яшел җәй тора.
Өстәлемдә бер бит кәгазь ята,
Бер стакан салкын чәй тора.

Туры юлдан чапкан пар атларым,
Алтын күпер урман өстендә,
Диңгезләргә чыккан корабларым —
Бары да шушы кәгазь өстендә.

Дәрья кичәм, кыяларга менәм
Һөҗүм итеп барган чакта мин.
Илләр инләп, давыл булып киләм,
Чигенүне белмәс патша мин.

Ярсу хыял инде күккә ыргый
Йолдызларны тотып карарга.
Мич артында чикерткәләр җырлый,
Хәл генә юк торып язарга.

—●

*Газиз Мөхәммәтшин*

# ХӨСӘЕН АБЗЫЙ

*Хикәя*

Мин быелгы ялымны Кама буендагы бер авылда үткәрдем. Килүемә атна була дигәндә, без: колхоз председателе Галимов Исхак, партоешма секретаре Закиров Исхак, инде мине дә кушып санасак — тәгәл өч Исхак — басуларга чыгып киттек. Машина, авыл башындагы бәләкәй күперне үтеп, калкулыкка атылып менүгә, ялтырап Кама күренде. Аның аръягында, еракта, зәңгәрсу урманнар җәелеп китте. Су өстендә ак теплоходлар, озын-озын саллар моннан караганда бер урында хәрәкәтсез торган кебек тоела, ә урман итәгендә рәшә тирбәлә иде.

Мин юлдашларыма:

— Мондый матурлыкны әлегә кадәр кешенең кулы да, акылы да ясый алганы юк! Сокланып туймассың! — дидем.

Председатель Исхак, йокы тимәүдән шешенгән күз кабакларын күтәреп:

— Ә, ни әйттең? — дип сорады. Мин баягы сүзләремне кабатлагач, исе китми генә: — Әйе, матур, — диде. — Мин әле узган ел Кавказда булдым. Тау да таш. Алдында да таш, артында да таш. Бездәге шикелле унар чакрымга сузылган тигез болыннар күрмәссең. Агачлары да бәләкәй, кәкре-бөкре. Кая инде безнең зифа каеннарга житү! Ләкин аның белән хозурланырга безнең вакыт калмый. Эш, диләр, давай, диләр. Обком райкомны кытырдата, райком безне, без бригадирларны, бригадирлар колхозчыларны... Кайчакларда кырыкка ярылырга житәсең...

Ул хаклы иде. Мин эчемнән үземне әрләп алдым. Тик кенә, лыгырдамый гына барсаң ни булган! Кайдан килгән табигать сөюче! Ә алар бүген төнге 12 дә яттылар, өченче яртыда тордылар...

Арыш басуына житкәч, машина туктады. Озак та үтмәде, басуның аргы башында комбайн күренде. Исхакларның йөзләре ачылып, нурланып китте.

— Хөсәен абзый агрегаты, — диде секретарь Исхак. — Унбиш агрегат арасында иң беренче. Безнең Кече Чулпыга сигез ел элек килде. Атлы эшкә куйсак та, риза булмады. Комбайн даулап аптыратты. Баштарак әллә ни майтара алмаса да, соңгы бер-ике елда эшнең рәтенә төшенде. Икмәктән, акчадан тыш, тегү машинасы, бер тана, өч сарык белән бүләкләнде. Суд заседателе. Узган ел Казанга барып түшенә орден тагып кайтты. Төпчек малаен да үз агрегатына алды. Уналты яшьлек, ә инде өч ел помкомбайнер.

Комбайн безнең турыга житкәч туктады. Мин комбайнчыга текәлдем. Тәбәнәк гәүдә. Кыска ап-ак чәч, тузанга манчылган сары майка. Малае да әтисенә тарткан. Алма агачыннан ерак тәгәрәмәгән. Ләкин шунсы гаҗәп: мин белгән, миңа таныш ниндидер сызыклар бар Хөсәен абзыйның йөзендә. Тик әйтә генә алмыйм, исемә генә төшерә алмыйм.

Исхаклар, камылларны чаж-чож китереп, аңа таба атладылар.

— Хөсәен абзый, төш әле. Сүз бар.

— Исхак, ускәнем, күп тотма. Минуты алтын, — диде комбайнчы һәм сул кулы белән уң колагын тартып куйды.

Мин дөрт итеп киттем. Хөсәен дигән исем дә, исем хуҗасының йомшак тавышы да, колак тарту хәрәкәте дә мина, нишләптер, бик таныш кебек, әгәр аны белсәм, бик тә әйбәт булыр шикелле тоелды.

Мин шулай уйланып торганда, Хөсәен абзый күперчегеннән төшкән иде инде. Менә ул, уң аягын ничектер катырак басып, безнең янга атлады, һәм шунда нәрсәдер шыгырдап янгырый башлады: шыг-гырт, шыг-гырт! Нәрсә шыгырдый соң? Нәрсә бу?..

Кинәт, караңгы күктә нәҗәгай атылган төсле, фикерем ачылып, хәтерем яктырып китте:

— Протез... Безнең Хөсәен абзый ич бу!.. Чөелдерек Хөсәен!..

Танышыргамы? Исемемне әйтергәме? Эш кешесен эшеннән аеру булмасмы? «Минуты алтын», -- ди бит. Бәлки үзе таныр!..

Тиз генә шуларны уйлап алдым. Юк, танымады. Миңа күз салып алды да Исхакларга эндәште:

— Төшкә хәтле бу участкыны бетерик дигәниек, ускәннәрем!

— Хәзер, Хөсәен абзый, — диде секретарь Исхак. — Сезне бүгенге бюллетень белән таныштырырга килдек. Менә тынла.

Исхак сумкасыннан кәгазь алды, тавышын тантаналы итәргә тырышып, укый башлады:

«Бюллетень № 3.

Игеннәрне урып-җыю буенча «Кама буе» колхозы правлениесе һәм башлангыч партия оешмасы карары.

Шушы елның егерме беренче июленә игеннәрне урып-җыю буенча механизаторлар арасында оештырылган социалистик ярышта җиңүче дип иптәш Гаптелхаков Хөсәен агрегатын санарга. Бу агрегат егерме беренче июль көнне, смена нормасын 165 процентка үтәп, 33 гектар урды. Колхоз правлениесенең һәм партоешманың күчмә вымпелын бу агрегатка тапшырырга һәм җиде сум акча белән бүләкләргә».

Секретарь Исхак язуны укып бетерде дә, Хөсәен абзыйның кулын кысты, аңа вымпелны тапшырды. Председатель Исхак бүләк акчасын тоттырды.

— Рәхмәт, Хөсәен абзый. Киләчәктә дә махы бирмә, — диде.

— Искә алып килүегез өчен үзегезгә рәхмәт, ускәннәрем, — диде Хөсәен абзый, сул кулы белән уң колагын чеметеп. — Шәт, махы бирмәбез... Ә иң артта кем?

— Мурзин. Кичә КЗН белән борчак чапты. Норма — җиде. Ә ул көч-хәл белән бер гектарны ергалап чыккан.

— Әйттем мин сезгә, башлык иптәшләр, ул сәрхүшкә техника тоттырмагыз, дип әйттем... Мин китим инде, рәхмәт сезгә!.. — диде Хөсәен абзый һәм шыгырт-шыгырт атлап комбайны янына китте...

Кире кайтканда Исхаклар миңа:

— Әйбәт тә кеше инде. Нык.лап танышсаң үзен дә күрер идең, — диделәр.

— Мин Хөсәен абзый белән күптән таныш инде. Без — авылдашлар. Дөресрәге, элек, авыл күчкәнче, — дидем мин.

Исхаклар берьюлы:

— Кит аннан! Чынмы? — дип сорадылар.

— Чын! — дидем мин һәм аларга Хөсәен абзый турында кыскача гына сөйләп бирдем...

Хөсәен абзыйны белә башлавымны, урамнарда очраганда исәнләшеп үтүләремне, әле ул вакытта беренче класста гына укысам да, мин яхшы хәтерлим. Сугышның икенче елы киткән, басуларга менә бүгенге шикелле уттай урак өсте хуҗа булган иде. Бер көнне иртән бөтен авыл: «Хөсәен кайткан!» дип шаулашырга, йөгерешергә тотынды. Ярты сәгать үтте микән, Хөсәен абзыйларның авыл уртасындагы жил-

пуч чаклы гына ике тәрәзәле, искереп беткән өйләре безнеңише бала-чага, йон оекларына кырмавык ябышкан уракчы хатыннар, карткорылар белән шыгрым тулды.

Хөсәен абзый өстенә иске генә яшел гимнастерка киеп, аны брезент каеш белән буып куйган иде. Башында каралып беткән пилотка, бер аягында тузанлы итек, икенче аягында... Әйе, аның икенче аягы юк иде.

Минем аяксыз кешеләрне күргәнем юк иде әле. Сугыштан кайткан беренче кешенең шушылай булуы йөрәгемә шом салды. Әниләр мич арасына кереп шыпырт кына еладылар, бабайлар сәке йөзлегендә башларын иеп тын гына утырдылар, без — бала-чагалар ишек төбендә этешә-төртешә басып тордык. Сугыштан әллә гел аяк өздереп кайталар микән, дип уйладык.

Хөсәен абзый үзе авылдашлары белән исән-аман күрешүенә бер яктан сөенсә, икенче яктан, аягы өчен уңайсызланган шикелле тоелды.

— Минекен күрмәдеңме?

— Безнеке очрамагандыр бит?!. — дигән сорауларга, сул кулы белән уң колак яфрагын тарта-тарта:

— Юк шул...

— Кая инде ул!..

— Туры килмәде, — дип, кыска-кыска җаваплар биреп утырды.

Ләкин ни генә әйтмә, Хөсәен абзыйның исән әйләнеп кайтуы күңелләрне күтәреп, өметләрне үстереп җибәрде. Бәй, сугыш хәтле сугышны да алдап була икән ләбаса. Яуга чыккан ир егетләр «туп!» итеп кайтып та төшәләр икән бит!..

Халык, бура төпләренең такы-токылыгын сизмәгәнгә салышып, Хөсәен абзыйны өй борынча кунакка йөртте. Өстәлләргә арыш көлчәсе белән катык, яшь бәрәңге белән юа тәкәсе куелды. Үрмәкүч пәрәвезләренә чорналып еллар буе караңгы базларда яткан «чүлли»ләр кояшка чыкты. Хәллерәк өйләрдә әчегән баллар табылды. Авылның әле бу, әле теге очында тәрәзәләре томаланган өйләрдән Хөсәен абзыйның җыры яңгырап торды:

Бер мең дә гөнәлә-ай тугыз йөз кырык беренче еы-ылда-ай
Герман — тәре сугышла-ай башлады-ый...

Карурманны чыккан чакта
Кисеп алдым ку-уш ка-аен,
Э-эйх!..
Кызылармеец кыеп йөри
Немецларның башка-аен...
Э-эйх!..

Иманыnны ла-ай гына ла-ай өшкерерләр
Кызыл Армиянең кызылармеецлары-ый...

Карурманны чыккан чакта
Атым чапты болынна-ан,
Э-эйх!..
Фашист ятадыр җан биреп
Кызылармеец кулынна-ан!..
Э-эйх!..

Бераздан аны районга чакырдылар. Хөсәен абзый үзебездә һәм күрше-тирә авылларда сугыш турында истәлекләр сөйләп йөри башлады. Аны басуларга, кыр станнарына, амбар алларына ат белән килеп алалар һәм китереп куялар иде. Моңа халык та, Хөсәен абзый үзе дә бик канәгать иде. Тик ай тулганда аны кабат районга чакырдылар. Хөсәен абзый бу юлы кәефе кырылып кайтты, һәм аларның капка төбендә җигүле атлар күренмәс булды.

Без моның сәбәбен — Хөсәен абзыйның көлчәсе көлгә төшүен соныннан белдек. Ул, тора-торгач, үз сүзләренә су кушып, күзгә төтен

җибәрә башлаган икән. Баштарак, походный кухняга ботка алырга барганда аягыма пуля тиде, дип дөресен сөйләгән. Атна үтүгә, герман окопларын атаковать иткәндә өстемә кырык потлы снәрәт төшеп аягымны өзде дип, таякка таяк ялгарга тотынган. Тагын бераздан, немецның бик олы генералын плен төшереп торганда, шул сволочь кылыч белән аягыма чапты, дип куык очырган. Соңгы көннәрдә, Гитлерны чәнчелдерергә секретный приказ алып, Берлинга очканда аэропланымны бәрделәр, егылып аягым сынды, дип ярма яра башлаган. Райондагылар шуны сизә торып ничек сөйләтсеннәр инде! Тыйганнар, билгеле...

Ә без моңа гаҗәпләнмәдек. Чөнки Хөсәен абзыйның кабык сугып, чәүкә очыртучы адәм икәнен күптәннән белә идек. Һәр авылның, гадәттә, үз алдакчысы һәм үз ялкавы була. Безнең авылда исә аның тегесе дә, монысы да әлеге дә баягы Хөсәен абзыебыз иде.

Аның саламнары череп, бастырыклары коелып беткән юка түбәле, тишек-тошык читән өйалдылы, чүлмәк морҗалы, хан заманыннан калган иске өе хуҗасының ата ялкау бер адәм икәнлеген әллә кайдан кычкырып тора иде. Яртылаш җиргә сеңгән өй эчендә дә яшел аш табагы, аның янында, сабасына күрә пешкәге дигәндәй, алты җанга бер агач кашык, бер сапсыз тимер кашык, баш асларына салырга ике-өч мендәр, асларына җәяргә катып беткән иске бозау тиресе һәм тезелешеп ятарга как сәкедән бүтән җиһаз юк иде. Элегрәк туганнары, таныш-белешләре, аларның теле үтмәгәч — бөтен авыл аңа кинәш биреп, орышып карады:

— Хөсәен, дим, Хөсәен туган! Ир башкайларыңны страм итеп шушы нәстәкәйдә торасыңмы? Оят кирәк!

— Кирәк, бик кирәк! Кирәкмәгән нәрсә юк бу дөньяда! Прәме аптыраш!

— Милекмени бу?! Тфү, әлгаязыбилла, ташка үлчим! Авылның бар бәрәкәтен очырып тора!

— И-и, ташка түгел, тимергә үлчәсәң дә юк... Үлчәүле әйбер — беткән әйбер инде ул...

— Телең булмаса, күзеңне күптән карга чукыр иде. Ник мантырга теләмисең, алла бәндәсе, ә?

— Алла бәндәсе булганга. Алла үз бәндәләрен оҗмахта бесплатны ашатачак ди бит. Монда ташлап китү өчен нишләп мантып азапланыйм. Җүләрмени мин?

— Үзең үлсәң, җиде ят кулына түгел — балаларыңа калыр ие.

— И-и, ул шайтаннар үзләренә үзләре тапмас дисеңме?

Моныңише чәкәләшүләр кабатланып торганга, Хөсәен абзый аңа ияләнеп беткән һәм исенә дә кертми башлаган иде. Таштан юкә суйса да, шаярып, кеше көлдереп, алдар борчагын уңлы-сullы чәчеп яши иде. Авылдашлары да, берәрсе кеше ышанмаслык нәрсәләр сөйли башласа:

— Хөсәенләнмә!..

— И Хөсәен!.. — дип, ул кешенең авызын ябалар иде.

Менә шуңа күрә аның генералларны плен алып йөрүенә гаҗәпләнүче булмады. Олы кешеләр көлемсерәп баш чайкый-чайкый:

— Көрпә чәчүен сугыш та ташлата алмаган икән мескеннен, — дип куйдылар да онытсылар.

Истәлек сөйләүдән туктау, дөресрәге, туктатылу белән, Хөсәен абзый яңа эш эзли башлады. Аны, бик сөенеп, төрле эшләргә димләделәр. Тик Хөсәен абзый андый вак-төяк эшләрнең берсенә дә риза булмады. Аның уенча, «Гитлерның үзе белән якалашып кайткан герой фронтовикка, җитмәсә, герой инвалидка» беренче үк булмаса да, райкомның икенче, я өченче секретаре яки райисполкомның председатель урынын үзләре чакырып бирергә тиешләр иде. Шуннан ким түгел!..

Районнан хәбәр җибәрүләрен яшерен өмет белән бер ай көтте Хөсәен абзый, ике ай — хәбәр килмәде. Өченче айда өмете киселде, һәм ул, күкрәк сугып:

— Мәскәүгә барам, Кремльгә керәм! Безнең ише суга төшми, утка пешми торган фронтовикларны санга сукмыйлар! — дип күркәләнеп йөрде.

Эче сызып интектергән шушы көннәрдә Хөсәен абзый үзенә «чөелдерек» кушаматы таккан мәзәк кенә нәрсә эшләп куйды. Идарә капкасы төбендә председательнең җигүле аты тора икән. Хөсәен абзый кызыбрак барган да, кадерен белмәүләренә үч итеп, шул атның сары каеш чөелдереген чишеп алып биленә бәйләгән.

— Нигә кирәк ул? — дип гаҗәпләнгән председатель. — Бир чөелдерекне?

— Бирмим! — дигән Хөсәен абзый, карышып.

— Бу нинди иске авыздан яңа сүз! Бир инде, шаярма!

— Әһә, иске авыз дип мыскыл итәсезме, кылтаясызмы! — дип күтәрелеп бәрелгән Хөсәен абзый. — Без анда кара тиргә төшеп сугышып яттык. Сез тылда, пунимаешь, ирәеп өр-яңа чөелдерекләр тагып йөргәнсез. Безнең дә буасы килә каеш чөелдерекләрне!

Шуннан ул тынычланып өенә кайтып киткән. Председатель авызын ачып аның артыннан карап калган һәм:

— Вәт син, малай! Менә сиңа Чөелдерек Хөсәен! — дигән.

Кушамат кушарга авыл халкына әйт инде. Икенче көнне үк җинел кулдан китте дә барды — Хөсәенгә «чөелдерек»не өстәп, Чөелдерек Хөсәен дип йөртә башладылар. Өмет иткән зур эшләр урынына бәләкәй генә кушамат эләккәч, Хөсәен абзый тынды. Район башлыкларына һәм авылдашларына үч итеп, үзенчә, тешсез картлар гына эшләрлек иң җиңел эшкә — амбар каравылларга керде.

Ул авыр һәм ач елларда безнең авылның салам түбәле иске амбарлары язын да, көзен дә, юк шул, кодагый, дигәндәй, буш була иде, бары ишегенә тире бияләй хәтле йозак эленгән зур амбарда гына отход оны һәм көрпә-фәлән саклана иде. Хөсәен абзый тигез балчык түбәсен куе алабута каплаган, мунча кадәр генә каравыл өен рәткә китерде. Җир идәнендәге чүп-чарны көрәп чыгарды, урталай ярылган бүрәнәләрдән түргә сәке ясады, иске калай мич китереп куйды. Шул көннән амбарлар тирәсен калай мич түбәсеннән чыккан кызгылт ялкын яктыртып җибәрде, ул яктан шакылдавык шакылдаткан, әче итеп сызгырган тавышлар ишетелә башлады.

Бәләкәй классларда гына укысак та, безнең җәй көннәре башак, дару үләннәре җыеп, зелпе тамыры төшереп, ашлык утап, борчак алып һәм зурлар кулы җитмәгән башка меӊ төрле эшләр эшләп үтә иде. Кич өйгә эт булып арып кайта идек, чыгып йөрерлек түгел — кыл кыймылдатырлык та хәл калмый иде. Ә кышкы озын кичләрне, һәр көн диярлек, каравыл өендә — Хөсәен абзый янында кыскарта идек. Клуб юк, булса да барып күңел ачу табылмас, табылса да безнең ише «кәбестә күчәннәрен» кертмәсләр иде. Шуңа күрә каравыл өе безгә «ходай биргән» җылы бер урын иде.

Без, кып-кызыл калай мич тирәли тезелешеп, Хөсәен абзыйның искиткеч кызык әкиятләрен, бетмәс-төкәнмәс ялганнарын тыңлый идек. Хәзер дә искә төшереп көләм: уйдырма һәм фантазия дигәндә Мюнхаузеннан ким түгел иде аның мәзәк-ялганнары. Немец танкларыннан качып барганда Кара диңгезгә басма салып чыгып китүләрен, шулай итеп кенә исән калуларын, бурсык тишегеннән шуышып кереп дошман ДЗО Тын шартлатуларын, бер атка җиде кеше атланып разведкада йөрүләрен — барысын-барысын бүген дә малай чагымдагы шикелле авызымны ачып тагын бер тыңлар идем, рәхәтләнеп көләр идем!..

Хөсәен абзый безне шул кышкы озын кичләрдә әкият тыңларга,

халык мәзәкләрен аңларга өйрәтте, чын күңелдән көләргә өйрәтте. Әмма оят булса да әйтим: ул безне, үкенечкә каршы, тагын бер һөнәргә — тәмәке тартырга өйрәтте. Сугыш елларында һәр кеше бакча тутырып тәмәке белән көнбагыш чәчә һәм көз көне Ижау, Пермь якларына китеп, капчык-капчык сатып кайта иде.

Хөсәен абзый башта ук безгә бер шарт куйды:

— Әкият тыңлыйсыгыз килсә, мине тәмәкедән өзмәгез. Авызымда тәмәке пыскып тормаса, башыма җүнле уй керми, — диде. Каравыл өенә кесә тутырып самосад ташыдык. Үзебез дә суырып карадык. Тора-бара тәмәкегә ихлас белән тотынучы батырлар табылды. Батырлар гына батырмыни — без дә батыр ич! Хөсәен абзый алдында көлкегә калмаска тырышып, тончыга-тынчыга, чәчи-чәчи булса да бу яңа һөнәребезне һаман камилләштерә бардык һәм, кыш урталары кергәндә, каравыл өен чыннан да каравыл өе итәргә өйрәнеп җиттек.

Ләкин ни генә булмасын, без — малайлар бу кешегә бик нык ияләштек. Әгәр ул без баруга үзенең бүрәнә сәкесендә утырмаса, гаҗәпләнә һәм борчыла идек. Агач аягының уентык-уентык эзләре буенча барып, әкиятчебезне тәки эзләп таба идек...

Ел үтте, икенче кыш җитте. Хөсәен абзый кушамат таккан кешеләргә үч итепме, каеш чөелдерегеннән бер дә аерылмады, җәй көне шинелен, кыш көне толыбын буып йөрде. Ә икенче кышта аны, һич уйламаган чакта, тотты да мылтык каешына әйләндерде. Дөньяда бер эш тә сәбәпсез эшләнмәгән шикелле, моның да сәбәбе бар иде.

Бәрәңгеләр алган чорда Хөсәен абзыйны Осоавиахим җитәкчесе итеп куйдылар. Мелкокалибр белән ничәдер пачка патрон бирделәр. Бу җитәкче Осоавиахимга членнар җыя алгандырмы-юкмы, эшен гөрләтеп җибәрү өчен ниләр кылангандыр — белмим, хәтердә сакланмаган. Ә менә аның авыл буйлап, тисә-тиенгә, тимәсә ботакка дигәндәй, күзенә ни чалынса, шуңа чырт-чырт атып йөрүен яхшы хәтерлим. Кай көннәрне без борын очларын тирләтә-тирләтә класста мәсьәлә чишеп утырабыз. Мәсьәлә, ниһаять, чыкты дигәндә генә, тышта кинәт чырт-шыңң! иткән тавыш ишетелә. Без парталардан дәррәү сикереп торабыз да ялвару тулы күзләребезне карт укытучыбызга текибез. Сизов абый мәрхүм уйлап-уйлап тора да:

— Барыгыз инде, черти! Биш минуттан керегез, — ди.

Без ду кубып ишеккә ташланабыз, текә баскычтан кар өстенә коелабыз. Ишек алдында Хөсәен абзый. Корт күче шикелле аны сарып алабыз. Ул, күзен бик тырышып кысып, бик озак төзәп тора. Түземебез шартларга җиткәч кенә, шарт итеп атып җибәрә. Шыңң! итеп манара очындагы (без мәчет бинасында укый идек) калай ай шыңлап куя. Шатлыктан сикергәлибез, кычкырышабыз:

— Тиде, Хөсәен абзый, тиде!..

— Билләһигазыйм, әләкте!..

— Ә-әнә тишеге, ә-әнә!..

— Хөсәен абзый, мин дә атып карыйм әле, Хөсәен абзый?!.

Ул безне әллә ишетә, әллә юк. Кулын каш өстенә куеп айга карый. Ай да, астындагы шарлар да, ата торгач, иләк шикелле челтәрләнеп беткән. Хөсәен абзый шулар арасыннан бүгенге тишекләрне эзли. Ләкин чамалый алмый. Чертләтеп төкерә дә авыл очындагы әрәмәгә саескан атарга китә.

Хөсәен абзый тиздән авылдагы бөтен сыерчык ояларын, калай мич торбаларын, мунча ишекләрен, агач көрәкләрне атып тишкәләп бетерде. Көннәрдән бер көнне мылтыкны аның бәләкәй малае күтәреп чыкты. Тик бу батырлыкның ахыры күңелсез тәмамланды. Малайның чыпчык өеренә төбәп атылган пулясы лапас алдында кушәп торган тананың мегез очын бәреп сындыргач һәм аннан чаптырып кан ага башлагач, Хөсәен абзый яраткан улының теге... утыра торган җирен кыз-

дырып алды. Шуннан мылтыгын яшергән иде, ниндидер малай амбар астын бораулап бер куырырлык борчак агызгач, тагын дөньяга чыгарды. Чөелдерекне мылтык каешы итте. Тирә-якка даны таралган чөелдерек икенче вазифаны үти башлады. Хөсәен абзый, бәләкәй мылтыгын җилкәсенә асып, төн буе амбарларны әйләнде. Моңа хәтле могжиза белән генә дигәндәй атылмый калган соңгы патронын тәмәке янчыгында йөртте. Ләкин бу патрон да тиздән югалды. Каравылчының буш мылтык күтәреп йөрүен бөтен авыл сизеп көлә башлагач кына, Хөсәен абзый аны каеш чөелдерәге-ние белән каядыр тыгып куйды. Шулай итеп чөелдерек гаип булды, күзгә-башка бүтән күренмәде. Ә кушамат, законлы исем шикелле, Хөсәен абзыйга ябышып калды.

Тагын еллар үтте. Сугышлар бетте. Авылга кайткан солдатларның саны ишәйде. Без үсә, калҗка төштек. Җир идәнле, сыңар тәрәзәле каравыл өеннән яңа клубка күчтек. Хөсәен абзыйның тылсымлы әкиятләрен тыңларга вакыт кысанланды...

Урамның икенче ягында, амбарларга каршы, салам түбәле, шул түбәдән ике метр чамасы калкып торган такта каланчалы янгын сарае бар иде. Аның хуҗасы бераз бөкрерәк гәүдәле, ике авыз читеннән дага шикелле бөгәрләнеп асылынып төшкән салынкы мыеклы Өметбай бабай иде. Ул һәр иртәне сарай ишеген ачып куя да мичкә салган чытыр арбаны тәртәләреннән тартып тышка чыгара. Аны башын чайкый-чайкый дүрт-биш әйләнә дә мичкә ярыкларына бармагын тыгып-тыгып карый, авыр сулап тәмәке кабыза. Чытырдатып бер суыргач, каравыл өенә аркасын сөяп, үзе кебек үк самосад пыскытып утырган Хөсәен абзыйга урам аша сәлам бирә:

— Исәнме, энем!

— Бер көе, Өметбай бабай! Үзең ниһәл, исәнме!

— Шөкер... Дөньяда ниләр бар? Ниләр сүләйләр?

— Дөньялар бер көе, Өметбай бабай. Пока иминлек...

— Ә, алай икән! Ярый алайса, энем, бик әйбәт. Иминлек булсын, иминлек кирәк...

Беразга тынып калалар. Һәр икесе, үзалдына уйланып, тәмәкесен тартып бетерә. Шуннан соң алар еллар буе һәркөнне сөйләшә торган темаларына — һава хәленә күчәләр. Янгын сакчысы мыек очын бөтерә-бөтерә һавага карап тора да келәт сакчысына:

— Кояш иртән агарып чыкты, бүген-иртәгә аяз булыр, — дип кычкыра.

— Әйе, әйе! Мин тоже хәтергә алдым: кояш чыккан чакта күк йөзе аяз иде. Кояш үзе дә кечерәк кебек күренде, читләре аермачык якты иде. Һавалар коры булыр, — дип, Хөсәен абзый аның сүзенә куәт бирә.

— Айны әйтәм — басып туды. Бу да аяз көн галәмәте...

— Әйе, әйе! Кичә кояш баегач, безнең этәч мунча түбәсенә менеп кычкырды. Бөтен нәрсә аязны күрсәтә, Өметбай бабай. Чиләк, насус ише нәрсәләреңне хәстәрләбрәк тор. Пүжар-мазар чыкса, авылыңны буйдан буйга ялмап алыр. Самай пүжар вакыты. Алла үзе сакласын!..

— Һәй телеңә тилчә чыккан нәрсә!.. Ир башың белән каркылдап тормасаң...

Алар, озын көннәрен бергә кыскартып, шулай тату гына гомер итәләр. Тик кайчакларда гына, һич көтмәгәндә, пыр тузып китәләр, күтәрелеп бәреләләр. Бу, гадәттә, шулайрак була: Өметбай бабай, исәнлек-саулык сорашканнан соң:

— Бүген сыер саугaнда имчәген калтыратты — салкыннар булыр,— дип сүз башлап җибәрә. Тик Хөсәен абзый аңа әйтеп бетерергә дә ирек бирми:

— Юк, юк! Иртән безнең мәче идәнгә төшеп су эчте — көннәр җылы торачак, — ди. Шушылай башланган бәхәс кичкә кадәр сузыла...

Яки Хөсәен абзыйның:

— Каен агачында бөре күп — быел тары уңачак, күр дә тор, — дигәненә Өметбай бабай теше-тырнагы белән каршы төшә:

— Белер-белмәс көенә сөйләмә юкны, энем. Аягына бозау басмаган әле, яшьлегенә барасың... Яз көне балык тотканда күрдеңме?.. Ни күбрәк капты? Алабуга белән юрша. Значитса, бодай, арпа, арыш, борай уңар... Ә тары дигәнне... Ай, энем, белмәем, белмәем!..

— Әйтәләр бит сиңа. Бар ана, каен бөреләрен кара!.. Карт башың белән карышып утырмасаң!..

— Ай, энем, белмәем, белмәем!..

Гауга бик зурга китеп, бу ике гасаби бәндә бер-берсенең ата-аналарына күчкәч, тавышка җыелган халык аларны аралый.

— Тарысы да уңсын, арыш-бодае да, диегез, ике җүләр. Тамагыгыз туяр... Эшегез юк шул, эшегез. Шуңа күрә эчегез поша, — дип әрләп ала. Ике арада атна-ун көнгә тынычлык урнаша...

Хөсәен абзыйның җәйләре һәм кышлары менә шулай үтә иде. Тик аяк астыннан килеп чыккан бер бәхетсезлек аның тормышын үзгәртеп җибәрде.

Ул көнне иртән Өметбай бабай:

— Җидегән йолдыз карасу булып күренде, мөгаен, яңгыр явар, — дигән иде, Хөсәен абзый да:

— Әйе, әйе. Өермә җир өстендә төрле якка йөри — һавалар бозылу билгесе! — дип, аның сүзенә кушылган иде. Тик бу юлы ике «барометр» да ялгышты. Кояш калыкканда ук кызу булып калыкты. Озак та үтмәде, һава ипи салган өй шикелле бөркүләнеп китте. Өметбай бабай мыек очын чәйнәп утырды-утырды да:

— Уф!.. Мунча ләүкәсендә утыргандай утырам. Чыдар чамам калмады, энем. Каланчага менеп ятып торыйм әле, өстә җиләсрәктер, — дип каланчага үрмәләде. Хөсәен абзый да каравыл өенең җир идәненә шинелен ташлап шуның өстенә сузылды. Әмма озак та үтмәде, Өметбай бабайның:

— Хөсәен энем, Хөсәен энем! — дигән борчулы тавышына мәҗрәп яткан җиреннән сикереп торды.

— Ә!..

— Хөсәен энем, чык әле! Танавыма көек исе кергән төсле тоела. Шуңа уянып киттем. Бик яхшылап кара әле, берәр-яры пужар-фәлән янып ятмасын!..

Хөсәен абзый ишектән башын сузды һәм күзен киереп катып калды: янгын сарае дулый-дулый янып ята иде, ялкын инде каланчаны ялый башлаган иде. Хөсәен абзый, аңына килеп, титаклый-титаклый сарайга ташланды, куркудан һәм төтен йотудан аңын югалткан янгын сакчысын ут эченнән күтәреп урамга чыгарды. Дагадай кәкрәеп торган мыек очлары өтелсә дә, Өметбай бабайның сәламәтлегенә зарар килмәде. Ә янгын сарае, алар чыгуга, гөрселдәп җимерелеп төште. Коргаксыган мичкәсе, көпшәсенә тычкан оялаган тутык насосы, атфәләп бирсәләр дигән яшерен өмет белән Өметбай бабай кайтарып куйган пот ярым әрәмә печәне белән бергә бөтенләй янып бетте.

Урам аркылы булса да сөйләшер кеше калмагач, Хөсәен абзыйның көннәре тагын да күңелсезрәк үтә башлады. Ул, янгын сарае урынындагы саргылт көл өеменә, кисәү башларына карый-карый, иртәдән төшкә, төштән кичкә хәтле каравыл өенең тупсасында утырды. Юк, шәп булмады, күңелле булмады амбар сакчысының бу елы!..

Икенче язда янгын урынында тракторлар, комбайннар ремонтлый башладылар. Кара комбинезон кигән яшь егетләр, ак тешләрен ялтыратып, Хөсәен абзыйга еш кына сүз куштылар:

— Хөсәен абзый, кеше эшләгәнне карап тору рәхәтме?

— Кил әле, менә бу шөрефне бергәләп борыйк әле...

Хөсәен абзый бу шаяннарга ачуланмады. Теләгән кадәр шаярсыннар. Аңа кеше тавышы ишетү, яшьләрнең машиналар арасында кайнашуларын карап тору кызык кына. Тик кычкырсыннар шунда!.. Менә, карга санап утырасың, диполәре гена!.. Эштә лә ул. Каравылны кайчан эшкә чутламас булдылар әле?!. Андый законны кем чыгарды? Кирәкмәсә хезмәт көне язмаслар иде. Язалар ич. Димәк, бу эш кирәк!..

Шулай әкрен-әкрен җиңел генә кабынган уй соңга таба Хөсәен абзыйның кәефен җибәрде. Ул тынды. Авызыннан артык сүз чыкмас булды. Көннәр буе башын иеп көрсенә-көрсенә уйланып утыра башлады. Бу вакытта аның башында нинди фикер каршылыклары бәрелешкәндер, нинди уйлар кайнагандыр, белмәдек. Ләкин тынычсызлануы, эчтән януы хак. Гомере буе урамнарны шаулатып, халыкны көлдереп, үз тирәсенә бала-чага җыеп йөргән Хөсәенне юк өчен дә гауга куптаручы, юк өчен дә кешеләрне ачы сүзләр белән бик җиңел әрләп ташлаучы кашы-күзе җимерек Хөсәен алмаштырды. Туктаусыз тәмәке тартудан тамагы карлыкты, тавышы катыланды.

Без каравыл өенә бөтенләй аяк басмый башладык. Хөсәен абзый да безне очратканда күрмәгәнгә салыша иде.

Бу хикмәтләр — толып чабуы уып ятудан туюы һәм авыл халкыннан ояла башлавы иде аның. Без моның шулай икәнен бик яхшы күреп һәм сизеп тора идек, чөнки дөньяны дер селкетеп үкергән чагында да аның күзләренә генә карарга кирәк. Хөсәен абзый, никадәр тырышса да, күзләренә усаллык чыгара алмый иде.

Без, малайлар, бер кичне җыелып Хөсәен абзый турында сөйләштек. Соңыннан шундый нәтиҗәгә килдек:

— Болай озак түзмәячәк ул. Күр дә тор, бер хәл чыгарачак...

— Әйе, нәрсәдер кыланырга җыена шикелле...

Юравыбыз юш килде. Шуннан соң тагын ярты ел чамасы уйланыпсызланып, кем әләксә, шуның белән талашып йөрде дә хәлләрне чыгарды Хөсәенебез. Бүгенгедәй урак өсте кызып килгән чак иде. Басу тулы комбайн, кояшны айга ялгап, тыр-тыр иген ура. Юл тулы машина элеваторларга ашлык ташый. Амбар алдында таудай көшелләр өелеп ята. Көшелләр тирәсендә кырмыскадай халык кайнаша. Икмәкне кояшта киптерәләр, җилгәрәләр, келәтләргә тутыралар, машиналарга төйиләр. Берәү дә тик тормый. Бөтен кешенең маңгаеннан тир тама, бөтен җирдә эш кайный.

Хөсәен абзый, бу ыгы-зыгыны бөтенләй күрмәгән шикелле, каравыл өе янында тәпке белән тәмәке чаба иде. (Ул әле һаман, кибет папиросының юне юк, дип, самосад үстерә иде.) Тәмәке сабакларын агач ялгашта ит чапкан кебек чаба-чаба да, калай иләктән иләп, буш капчык өстенә киптерергә илтеп сала... Менә бер чакны зернопульт үкерергә тотынды, һәм яңгырдай яуган эре бодай ташкыны Хөсәен абзыйның тәмәкесен «ә» дигәнче күмеп тә куйды.

Иртәдән бирле кемгә бәйләнергә белмичә төсен бозып утырган каравылчыга шул җитә калды. Ул, эченә җыелган ачуын бушатырга җай чыгуына куанып, урыныннан сикереп торды, агач аягы белән җиргә типте һәм акырып җибәрде:

— Каһәр суккыры!.. Чукынган нәрсәләр!.. Күзегез чыкканмы әллә?!.

Зернопульт кадәр зернопульт бу тавыштан шөлләгәндәй шып туктады. Ләкин, гаҗәпкә каршы, кешеләр курыкмады. Телле генә бер апа, бөерләренә таянып, Хөсәен абзый алдына килеп басты.

— Я, ни үкерәсең... Чөелдерек?!.

— Үкерермен әле мин сезгә!.. Тәмәкене нишләттегез, тәмәкене!.. Именно шушы якка сиптермәсәгез җир беткәнмени?!

— Тәмәкене, бик кадерле булгач, өенә кайтып киптерергә кирәк, Хөсәен абзыкаем. Монда эш кешесенә мишайть итеп, чишелгән чабата киндерәседәй аяк астында чуалып йөргәнче!..

— Ә?!. Ни?!. Чабата киндерәсе?!. Авызыңны җәеп торасың!.. Уйнапмыни... Эштә утырам... Каравыллап!..

— И абзыкаем, абзыкаем, — диде теге апа, Хөсәен абзый балык кебек авызын ачып еш-еш сулап торган арада, — ни каравыллыйсың син алай тырыша-тырыша? Кемнән? Нигә ул каравылчы?.. Икмәк бүлеп торабыз. Шуның өстеннән кем амбарга төшсен!.. Каравыл, каравыл, диеп шушында картайдың — тоттыңмы хет берәр карак?

Хөсәен абзыйның исе китте. Соңгы айларда сүгенү мәсьәләсендә бик остарган кеше булса да, гарьлегеннән бөтен сүгенү сүзләрен онытып җибәрде. Урынында таптана-таптана:

— Ә мин!.. Ә син!.. Бу эшмени... Ә бу эш түгелмени!.. — дип мыгырданды.

— Ирдәй ирләр эше түгел шул. Ир булган ирләр мал-туар үрчетә, ашлык чәчеп, ашлык ура. Ә син, абзыкаем, толып якаңнан борча чүпләп гомер итәсең... Ха-ха-ха!.. — дип көлеп, теге апа борылып китте. Аңа бүтәннәр кушылды, амбар түбәсендәге чыпчык өере пырылдап һавага күтәрелде. Хөсәен абзый йодрыкларын төйнәп баш очында селекте дә ачуыннан буылып тырык-тырык кайтып китте...

Ул, авыл өстенә кичке эңгер-меңгер җәелгәч кенә, шактый исереп капкаларыннан чыкты.

Стаканның төпләрендә
Алма кисәкләре бар;
Алыр исәпләрең булса,
Барыр исәпләрем бар, —

дип җырлый-җырлый урамнарны урап йөрде. Ике-өч өйне үткән саен, туктап як-ягына каранды һәм йодрыгы белән дөп-дөп күкрәгенә сугып:

— И-их!.. Нигә мине әбиҗәйт итәләр?!. Мин кемнән ким!.. Кемнән ким мин, ә?!. — дип кычкырды. Каравыл өенә кереп, агач аягы белән яньчек калай мичне тибеп очырды. Каравыл өенең ишеген күгәне-ние белән суырып алып бер бәрәңге бакчасына илтеп ташлады. Без аның артыннан калмый карап йөрдек тә кереп йокладык. Ә ул әле буш урамнарда төн буе ялгыз башы шаулап-тузып йөргән. Таң алдыннан председатель өе янына тагын урап килгән. Шык-шык тәрәзә каккан тавышка күлмәк-ыштаннан гына атылып чыккан председательгә:

— Каравылыңда тормыйм!.. Комбайн кирәк, комбайн бир!.. Урам... Арыш урам, бодай урам... Теләсә нәрсәне, теләсә кемне урам! — дип ультиматум куйган.

Председательнең, аптырауга калып:

— Ә?!. Ничек инде?.. Аягың... Бер аяк беләнме?.. — диюенә каршы:

— Ә Мересьев?!. Аны беләсеңме? Ишеткәнең бармы, пеләш?!. — дип җикергән...

...Мин ике Исхакка менә шул тарихны сөйләп бирдем. Алар:

— Шуннан соң ничек булды? — дип сорадылар.

— Шул ук көзне су баса дип безнең авылны күчерделәр. Хөсәен абзый бала-чагасын төяп сезнең якларга китте. Монда аның ниндидер туганы булырга тиеш.

— Әлегә кадәр күрешмәгән идегезме?

— Әйе, күргәнем юк иде.

— Я, хәзер ничек соң Хөсәен абзый?

— Тәки сүзен сүз иткән икән!.. — дидем мин.

Мин шул ук көнне кичен, дөресрәге, төн урталары җиткәндә (көннәр коры, иртә-кичләр чыксыз торганга, алар тәүлегенә егермешәр сәгать уралар икән) Хөсәен абзыйларга бардым. Үткән вакытларны сагына-сагына, хәзергесенә куана-куана таң атканчы сөйләшеп утырдык. Октябрь бәйрәменә семьям белән бергә кунакка чакырдылар, үзләре безгә яңа елда килергә вәгъдә бирделәр. Ә без Хөсәен абзый белән икенче җәйдә, сабан туйлары чорында, туган-үскән якларга бергәләп кайтырга һәм каравыл өе турысына көймә белән кереп кармак салырга сүз куештык...

1965

*Самат Шакир*

## Миләүшә

Палатадан чыкты яшь кенә кыз,
Өнемме бу, әллә төшемме?
Ничек охшаган, дим, күз алдына
Китереп шунда якын кешемне.

Шомырт күзләр, кыйгач кара кашлар,
Таныш миңа кара чәчләре...
Якын исем белән эндәштем мин,
Тик кыз миңа берни дәшмәде.

Бераздан соң:
— Мин — Миләүшә булам,
Сез әйткәне — әни исеме.
Ул сугышта үлгән... — диде дә ул,
Кинәт шунда сүзе киселде.

Күз яшьләрен сөртеп, атлады ул,
Озак карап тордым китмичә.
Ник җибәрдем, диеп өзгәләндем,
Сүзләремне дәвам итмичә?

Сугыш елларында сөйгән кызым,
Ишетәм синең моңлы җырларын.
Ах, нигә соң алар тиз өзелде?
Җырла инде... Өзелеп тыңлармын.

Тын бакчада иң беренче тапкыр
«Сөям» дигән идең, кадерлем.
Ә аннан соң... Кавказ итәгендә
Очраттым мин синең каберне.

Төшләремә кереп йөдәттең син,
«Хуш, хуш», диеп кулың изәдең.
Кызың Миләүшә дип белмәсәм дә,
Рәсемеңне
Миләүшәләр белән бизәдем.

## Бер легенда

Юлчы чүлдән бара...
Алда — бакча.
Шау чәчәктә утыра бананнар.
Күл читендә нәфис мәрмәр сыннар
Су аттырып уйга калганнар.

Сары комның монда бөртеге дә
Җилләр белән очып килмәгән.
Эссе чүлдә мондый күренешне
Бәлки, әле беркем күрмәгән.

Аллы-гөлле бизәк төшерелгән
Келәм кебек бакча итәге.
Кул изиләр гүя зур пальмалар:
«Тизрәк, тизрәк килеп җит әле».

Юлчы уйлап алды: «Нинди бакча!
Күпме авыр юллар үтелде...»
Аның мираж икәнлеген белми
Запас суын эчеп бетерде.

*Радик Фәизов*

# ӘНИЕМНЕҢ КУЛЛАРЫ

*Хикәя*

Мин тагын туган йортымда.

Үзем дә олыгая төшкән кеше инде. Хатыным, ике балам бар. Ерактагы зур шәһәрдә, сарай кебек йортта торабыз. Тормыштан зарлану гөнаһ булыр. Ләкин мин үземне тик туган йортымда гына балаларча гамьсез бер бәхет иясе итеп, ниндидер иркенлектә итеп тоям. Монда әллә ничә елга бер әйләнеп кайтасың. Ә тагын ерак җирләргә киткәч, өйдә үткәргән һәр минутны, өйдә сөйләшкән һәр сүзне сагынып, кат-кат исеңә төшерәсең. Монда яшәгән берничә көнлек гомер сиңа еллар буена җитәрлек истәлек бирә. Җан азыгының иң татлысын бирә.

Барыннан да куанычлысы шул була: син дөньяда үзең өчен иң кадерле кешене, әнине күрү бәхетенә ирешәсең. Күңел түренә мәңгегә урнашып калган, еллар агымы юудан инде таушала башлаган иң сөйкемле сурәт тагын яңара. Син әни өчен әле һаман да салкын тидерергә, авырып китәргә мөмкин булган, даими күзәтүгә мохтаҗ бер бала икәнеңне сизеп, күңел нечкәрә.

Әнә ул — әни. Әле һаман да үзенең яраткан урынында, мич буендагы озын эскәмиядә утыра. Картайган, бик картайган инде. Кайчандыр кош канатыдай ялтырап торган кара, куе чәчләре сирәкләнгән. Бу чәчләргә хәзер бәс кунган кебек. Әнинең йөзе дә кипкән грушадай җыерчыкланып, нәниләнеп калган. Тик йон язган куллары, буыннары кабарып беткән бармаклары гына нәкъ элеккечә җитез хәрәкәтле. Тик алар гына мәңге картаймаслар, хәлдән таймаслар кебек.

Оекбашларымны күргәч, әни мине дә, ерактагы киленен дә тиргәп ташлады. Хәзер миңа яңа оекбашка йон яза ул.

Вакыт соң инде. Бүгенгә сөйләшәсе сүзләр сөйләшенеп бетте кебек. Мин юрган астында ятам. Иртәгә мин йокыдан торганчы киемнәрем чистартылып, бушаган төймәләр тагылып куелган булачак. Төнлә өстем ачылса, әни килеп юрганны ябачак. Тынычлап йокларга мөмкин. Ләкин йокы алмый. Күзләремне яртылаш йомып, әнинең кулларын күзәтәм. Аларның минем өчен никадәр кадерле, никадәр газиз икәнен хис итеп, хәйранга калам. Бу куллар мине күкрәккә кысып имезмәделәр, бишеккә салып тирбәтмәделәр. Үземне дөньяга китергән әнине бик тоныкь кына хәтерлим мин... Ләкин бу куллар мине аркамнан сыйпап үстерделәр, җил-яңгырдан сакладылар. Туры юлга озатып җибәрделәр. Тормышта үз урынымны табардай, киртәләрне җимереп алга атлардай кеше булганым өчен мин шушы кулларга бурычлы.

...Мине дөньяга китергән әни бик яшьләй вафат булды. Аның тик үлем түшәгендә яткан җиреннән безгә — карават янында тезелешеп торган балаларына текәлгән, соңгы чаткылары сүнә барган күзләре генә хәтеремдә. Әнидән җиде бала калдык без. Иң кече сеңелебез Асия сигез айлык, ә иң олы апабыз унбиш яшьлек иде. Әни үлгән елны су-

гыш башланды. Әтине солдатка алдылар. Безне ни сәбәп белән балалар йортына бирмәгәннәрдер? Бу сорауга шушы көнгә кадәр төпле җавап алганым юк. Бәлки әтинең һәм әнинең туган-тумачалары безне тәрбияләүне үз өсләренә ала алмаганнардыр. Һәрхәлдә сугыш елларын без өйдә ялгыз булып, олылар тәрбиясен күрмичә, бик авыр хәлләрдә торып үткәрдек. Сеңелебез Асия һәлак булды.

Әти сугыштан исән-сау әйләнеп кайтты. Ул кайтып берничә көн үтүгә, каршыдагы тыкрыктан күзлек кигән бер ямьсез хатын безгә килеп җитте.

— Атагыз өйдә хәзер, мәлгуньнәр. Менә ул тиздән сезгә үги әни алып кайтыр. Күрмәгәнегезне күрерсез! — дип янады ул безгә. Без аның яшелчә бакчасына шактый зыян китердек. Шуның ачуы булгандыр инде бу. Шулай да бу хәбәр безне тетрәтеп җибәрде. Җан калтырап өйгә үги әни килгәнне көтә башладык. Әкияттәге аждаһадай авызыннан утлар чәчеп, кулына уклау таягы тотып, безнең төшкә үги әни керде. Үзара яшерен планнар корып, без аны утын агачы күтәреп каршы алырга әзерләндек.

Мин почмактагы сәкедә бәрәңге әрчи идем. Кечкенә сеңелләремнең берсе идән юа, икенчесе шул ук идәнне икенче баштан пычрата килә. Менә ишектән әтигә ияреп бер ят апа керде. Тәбәнәк буйлы, тифтән соң кыскарып калган кап-кара чәчле бу апа килеп керүенә өс-башын чишенде. Башларыбыздан сыйпап, безнең барыбыз белән дә күреште. Сеңелебез кулыннан чүпрәкне алып, әллә ни арада идәнне юып чыгарды. Аннары, идән уртасындагы урындыкка килеп утырды да ни өчендер елап җибәрде. Аның яшьле күзләрендә озак вакыт югалтып торганнан соң балаларын тапкан ана шатлыгын, безнең мөшкел хәлгә тирәнтен борчылу күрдек без. Ике кечкенә сеңелем, борыннарын еш-еш тартып, аның тезләренә килеп сыендылар. Ә ул, күзләрен бер ноктага текәп, аларның сары чәчләрен аралый башлады. Күпме еллар үксез булып яшәгәннән соң, ниһаять, безнең янга әни әйләнеп кайтты.

Әни сүзсез генә минем кулдан пычакны алып, бәрәңге әрчергә тотынды. Бәрәңге әрчеп бетерүгә, учак янына килде. Учак янында зарыгып утыруга күнегеп беткән энем Рифат шунда ук урамга уйнарга шылды.

— Чалбарыңны сал, улым. Ямап бирим, — диде миңа әни, кулларь аш-су әзерләүдән, өй җыештырудан аз гына бушана төшкәч. Ертык чалбарымның тез башларына ямау салынгач, минем шатлыгымның чиге булмады. Бу чалбар белән мактанасым килеп, мин дә капка төбендә шаулаган иптәшләрем янына ашыктым. Мин хәзер туйганчы уйный, шаяра алам. Минем бәрәңге әрчисем, аш пешерәсем юк. Безнең өйдә дә әни бар хәзер!

Еллар үттеләр. Безнең киемнәргә күпме ямау салды, безнең өчен күпме ашлар әзерләде, юды, бәйләде икән әнинең куллары?! Без алардан күпме шәфкать-ярдәм күрдек икән? Үткән көннәр минем күңелдәге үземне тудырган әни белән тәрбияләп үстергән әнине аера торган хисләрне күптән юып алып киттеләр. Минем күңелемдә хәзер бер генә әни калды. Әнә ул, мич буенда утыра.

Мин әнинең кулларын күзәтәм. Аларның минем өчен никадәр кадерле, газиз икәнен хис итеп хәйранга калам. Нигә мин бөек бер рәссам булып тумадым икән? Көчемнән килсә, мин шушы кулларга һәйкәл куяр идем. Әнинең йөзен дә, гәүдәсен дә сурәтләмәс идем. Тик менә шушы ярылып беткән кулларны гына сурәтләр идем. Һәйкәлгә караган һәрбер кеше бу кулларның бөек ана куллары икәнен таныр иде.

*1966 ел.*

——◆——

*Галимҗан Насыйров*

## Сүз

Сүз фикернең көзгесе,
Сүзнең була төрлесе:
Ташка уелганнары,
Утта коелганнары,
Очрый әле аннары
Суга язылганнары.

## Больницада

Көн тууын хәбәр итсә кош-нарасый,
Тәрәзәдән кояш кереп обход ясый;
Беркемгә дә теләмимен мондый хәлне,
Күңел ташый, күңел ташый, күңел ташый...
Авырлыкның чамасы юк, юктыр кебек,
Авыруымның дәвасы юк, юктыр кебек.
Палатада ак мендәрләр, кара уйлар...
Кара уйларны бүлдерде доктор кереп.
Кулларымнан тотты да ул йомшак кына
Ишарәләп күрсәтте ишек ягына:
Әйтерсең лә, бөтен авыл килеп баскан...
Сикереп тора яздым кинәт шул чагында.
Дусларыңнан җылы караш дәва икән,
Җан шуңардан үзенә шифа таба икән.

## Мәхәббәт

Чәчкә чал кергәч мәхәббәт
Оят түгелме имеш?
Янмаган булсаң бу утта
Син бер янарга тиеш.
Күпме газаплар чикмәдем,
Менә бу газап — газап!
Мондый ләззәтле газаптан
Итмәгез зинһар азат.

•

Тормышны жыр дисәк әгәр дә,
Без тик сүзләр генә эсәрдә.
Ташланмаса идем сызылып
Мин шул жырдан артык сүз булып.

## Игенче

*«Иген иккел, рәхмәт өмид*
*итәр' булсаң»*
*Мәула Колый.*

Җирне кайнар
Тиргә манчып,
Минем әти
Иген иккән:
Авыр эштән
Беткән йончып,
Холкын дөнья
Кырыс иткән.

Шигърияттен
Ләкин эти
Күңеленнән
Югалтмаган:
Әфтияге арасында
Ижат итеп
Жыр саклаган:

«Улым, сиңа
Теләгем зур —
Гомер буе
Рәхәт чик син:
Рәхмәт өмет
Итәр булсаң,
Васыятем шул:
Иген ик син!»

## *Гомәр Хәйям шигырьләре*

*Мәрхүм шагыйрь Зыя Мансур озак еллар буена каты авыру белән җәфаланса да, күп эшләгән, тынгысыз иҗат иткән. Көнчыгыш классиклары поэзиясеннән иң якты үрнәкләрне татарчага тәрҗемә итүдә дә соклandыргыч матур хезмәтләр калдырган.*

*Журналыбызның бу санында без Көнчыгышның бөек шагыйре Гомәр Хәйям шигырьләрен урнаштырабыз. Аларны Зыя Мансур тормышының соңгы айларында — үлем алдыннан тәрҗемә иткән.*

●

Су тамчысы күлгә төште һәм — вәссәләм,
Ком бөртеге чүлгә төште һәм — вәссәләм.
Бу дөньяда килү ни дә, китү ни ул? —
Очтың бездән чебен төсле һәм — вәссәләм!

●

Чәчәкләрдә иртәнге чык балку яхшы,
Үзәннәрдә иркәң йөзе балку яхшы.
Үткән көнне күп сөйләмә, яхшы түгел,
Гүзәл булып бүгенгесе балку яхшы!

●

Боргалыйсың, тәңрем, безнең язмышны син,
Без елыйбыз, син көләсең, табышлы син.
Яхшыны — чит, яманны үз күрә күңелең,
Әйт, ишәкме, акылыңнан язмышмы син?..

●

Җирне, күкне, бөтенесен тудырды ул,
Йөрәкләрне хәсрәт белән тутырды ул.
Тулган ай күк гүзәлләрне туфрак итеп
Җир астына азмы сәфәр кылдырды ул!

●

Мин гыйбадәт кылырга бик әзерләнмим,
Тик мәчеткә килдем менә хәзер дә мин:
Янарак бер келәм табу иде исәп,
Бик кыршылды чөнки былтыр чәлдергәнем.

●

Шашкан җилдәй исеп җанны нигә җактың,
Ник җамымны алып кулдан җиргә аттың.
Мин эчәмен, син йөрисең дөнья бутап,
Аекмын дип әйтерсеңме син дә, раббем?..

●

Әчмисеңме, исерекләрне йөрмә тиргәп,
Алдалавың, хәйләләвең кемгә кирәк?
Мактанасың: имеш, хәмер капканың юк,
Ә бит эшең аннан мең кат әшәкерәк!

●

Аң-белемне ят күрмәде һич тә күңелем,
Күп түгелдер мин ачмаган сере Җирнең.
Җитмеш ике ел йөздем мин уйда көн-төн,
Бернәрсә дә белмим икән, шуны белдем.

●

Бу заманда дус-ишләрнең азы яхшы,
Алар синнән ерак булса тагы яхшы.
Дус дигәнең дошман булып чыгу мөмкин,
Акыл күзе дигәнеңнең сагы яхшы.

●

Бу дөньяның күпләр әзли сер ачкычын,
Куй уеңны, җитмәс синең моңар көчең.
Чык болынга, чум шәрапка, көтмә оҗмах,
Дөньялыкта үзең тудыр оҗмахны син!

●

Җәннәткә дип яратканмы мине хода,
Тамугкамы — башым җитми минем моңа.
Юк, оҗмахны көтәсем юк, үзеңә ал,
Бир хәзер үк шәрап, яр һәм болын миңа!

●

Намуссызга бу тикле мал нигә тактың,
Тегермән дә, мунча да һәм өй дә таптың.
Бер сыныкка тилмерәләр намуслылар.
Күгенә карап төкерәсем килә, раббем!..

•

Без киләбез һәм китәбез, нинди файда,
Бу дөньяның аркылысы, буе кайда?
Яндыра күк җирнең азмы гакыл күзен,
Ә төтене кайда аның, көле кайда?

•

Диләр миңа: капма хәмер син шәгъбанда,
Рәҗәп ае изге ай ул, эчмә анда,
Ходайныкы булса әгәр дә бу айлар,
Эчик әйдә үзебезнең рамазанда!..

•

Мин тудан нинди файда тапты бу күк,
Мин үлүдән аның күрке арттымы күп,
Әйтсәгезче, ни хакына тудыра да,
Ник соңыннан җиргә салып таптый бу күк?

•

Табынымда бер ак көлчә әгәр булса,
Шәрап белән булса яшь куй ите — бер сан,
Яшәсәм дә иркәм белән җимерек өйдә —
Дөньяда мин булыр идем иң бай солтан!

•

Дөнья серен уйладык күп — син дә, мин дә,
Сүтәлмәдек йомгагын тик — син дә, мин дә,
Гәпләшәбез кара чаршау артында без,
Ул ачылыр, булмабыз тик син дә, мин дә.

•

Әйтмә, мөфти, эчкече дип безне — юк сүз,
Күп эчәбез, әмма синнән күп аек без,
Без эчәбез йөзем канын, син — безнекен,
Кем соң ерткыч, әйтеп кара бер аек сүз!

•

Картка да бер, яшькә дә бер вакыт җитә,
Әҗәл килеп берәм-берәм алып китә,
Мәңгелеккә тумый һичкем, без китәрбез,
Алмаш килер һәм аны да табут көтә...

•

Мең фатиха кылыр идем күккә мин дә,
Булса икән бер кыерчык наным[1] көн дә,
Беркемнен дә патшасы һәм колы булмый
Торсам икән үз куышым дигән җирдә!

•

Изге йөзем суын эчми куя күрмә,
Хәрам каннан башка һични коя күрмә,
Кой, теләсәң мең ялганчы суфый канын,
Ә моның бер тамчысын да җуя күрмә!

•

Гөнаһлы мин, изге бер җан булганым юк,
Әмма куркып артык аһ та органым юк.
Баш авыртса, яр һәм шәрап сорыйм иртән,
Мәчет яки чиркәү диеп торганым юк...

•

Аң туенда юл ачты баш бер дәлилгә,
Йөртә дөнья шул дәлилне илдән-илгә:
Мәй хәрам ул, эчмә диләр, ник ышаныйм,
«Мәйсәрә» дип язылган ич Коръәнендә!

•

Бу дөньяның иң зур максат кыясы — без,
Акыл күзе нурларының кояшы — без,
Әгәр галәм түгәрәк бер йөзек икән,
Шиксез, аның мең алтынга тиң кашы — без!

•

Эчкәнне дә һәм хатын-кыз кочканны да
Сала диләр ходай тамуг учагына.
Һич шигем юк, ләкин оҗмах дигәне дә
Хәрабәдәй буш булачак ул чагында.

---

[1] Н а н — икмәк.

## *Хәлил Аппаз*

*Шагыйрь Хәлил Аппаз 1913 елда Кырым өлкәсенең Симферополь шәһәрендә туа. 1921 елдагы ачлыкта ата-анасыз ятим калып, алты ел балалар йортында тәрбияләнә.*

*Җидееллык мәктәптән соң, 1930 елда Симферополь педагогия училищесын тәмамлый.*

*Беренче шигыре «Яшь куәт» исемле өлкә газетасында басылып чыга. Шуннан башлап Хәлил Аппаз шигырьләре газета-журналларда еш күренә башлый.*

*Соңгы елларда ул Татарстанның Саба районында укытучы булып эшли. Без журналыбызда аның шигырьләрен тәрҗемә итеп урнаштырабыз.*

# Авыр еллар истәлеге

**Сау бул, туган шәһәребез,**
**Соң тапкыр син каршымда.**
**Мин үземне горур тоям**
**Туфрагыңда, ташыңда.**
**Урамнарың, бульварларың**
**Яшеллеккә күмелгән.**
**Әйтче, моңа халкыбызның**
**Әзме тире түгелгән?**
**Бу заводлар, бу корпуслар —**
**Бишьеллыклар җимеше.**
**Хезмәт түгеп, халкыбыз күп**
**Могҗизага иреште.**
**Синдә тудым, синдә үстем,**
**Җырын мин сандугачның**
**Тыңлап, синдә гөлләр өздем,**
**Иркәмә серем ачтым.**
**Тантаналы мәйданыңда**
**Ватаныма ант итәм.**
**Ант итәм дә чын күңелдән,**
**Изге сугышка китәм.**

**...Тик сиңа да дошман килде,**
**Җимерде, вәйран итте:**
**Кырау суккан чәчәк кебек**
**Сулды тормышың, кипте.**
**Халык тудырган байлыкны**
**Талады фашист кулы.**
**Таш кыялар сөйләп тора**
**Дәһшәтле, канлы елны...**
**Кәеф табалмады дошман,**
**Йотым суга сусады.**
**Бер минут син тынычлыкта**
**Калдырмадың дошманны.**
**Адым саен лаек җәза**
**Явызга бирә килдең.**
**Еран булсам да, шәһәрем,**
**Мин синең белән идем:**

**Онытылмас һич ул еллар,**
**Онытылмас зур юллар,**
**Онытылмас фашистлардан**
**Халык күргән золымнар.**

Барысы аша да, шәһәрем,
Үттем синең белән мин:
Майданекның җәфаларын,
Бухенвальд җәһәннәмен.
Әле дә саклый күңелем
Миллионнарның сыкравын.
Күңелемдә җәйрәп ята
Җимерелгән йортларың.
Һәм узам мин дөнья буйлап,
Тәкрарлап бар телдә:
Мәңгегә ләгънәт укылсын
Фашизмга һәр илдә!

Ә. ДАВЫДОВ тәрҗемәсе.

## Борчуым

Гомер дәрья булып ага,
Яшьлек калышмый аннан.
Сабый булып туар идем,
Мөмкин булса, яңадан.

Торган саен бу хәятның
Арта мәгънәсе, яме.
Киләчәккә өмет бирә
Көрәштә җиңүләре.

Ничек итеп бу бәхетле
Яшьлеккә сокланмаска:
Без беренче булып ачтык
Юлны ерак космоска.

Мин борчылам, сагышланам
Чал керде дип чәчемә:
Йолдызларга сәяхәткә
Баралмам бу яшемдә...

## Ватан улы

Бөек Ватан сугышында һәлак булган шагыйрь А. Алимгә багышлыйм.

Син бүген дә элеккечә күз алдымда торасың,
Йөзең алсу, якты иде, нурлы иде күзләрең...
Якын дустым, син яңадан хыялымда туасың,
Бер дә чыкмый исләремнән синең әйткән сүзләрең.

Бәлки Карпат итәгендә, бәлки Чонгар чүлендә,
Бәлки карлы һәм буранлы салкын төньяк илендә,
Хыялыңда бер-бер артлы сабыйларың үткәндер,
Сөйгән әткәсен алар да төшләрендә үпкәндер...

Рәсемеңне куеган чакларда сагыш ала йөрәкне,
Ниләр килеп, ни китмәде, ни кичмәде башыңнан...
Син яшәрсең күңелләрдә мәңге бергә, хөрмәтлем,
Үлемсезлек нуры балкыр синең кабер ташыңнан.

Н. АРСЛАНОВ тәрҗемәләре.

# Яшьләр иҗаты

*Фәнис Яруллин*

## Караңгыда йортлар калкалар

Төзелеш бара төнлә. Карангыда
Сваркалар ялт та йолт килә,
Алар яктысына энҗе тешен
Җемелдәтеп эшче кыз көлә.

Айны элеп кран ыргагына
Яктыртырга куйган кранчы.
Этаж арты этаж күтәрелә
Йокысыннан кешеләр торганчы.

Караңгы дип тормый, төзелеш бара,
Күтәрелә өскә ак бина.
Төн пәрдәсен ертып өйләр үсә
Кешеләр торсын өчен яктыда.

## Читтән караганда

Самолетта очам. Югарыдан
Күзне кысып җирне күзәтәм.
Җир тип-тигез, бары киеме генә
Төрле җирдә төрле бизәктән.

Кырлар белән кырлар тоташалар,
Юллар белән юллар үрелә,
Сизелмиләр ярлар, чокырлыклар,
Бар төш матур, тигез күренә.

Юллар шома, җирләр тигез төсле,
Читтән торып кына күзәтсәң.
Тормышны бит дөрес аңлап була,
Чокырларны үзең төзәтсәң.

## Кышкы көндә

Туным тәннең жылылыгын саклый,
Салкын базмый янга килергә;
Ә мин, юләр, изүләрне ачам
Өергәндә салкын өермә.

Теләмимен булган ялкынымны
Чыгармыйча эчтә сакларга.
Мин телимен йөрәгемне ачып
Бураннарга каршы атларга.

## Теләк

Үлсәң иде кешеләргә
Кирәгең беткәч кенә.
Ә кирәгең бетсен иде
Дөньядан киткәч кенә.

## Сабый чак

Барысына да өлгерүчән
Ваемсыз сабый идем.
Коймак пешерсә әнкәем,
Бәйрәмгә саный идем.

Безнең өстәге күлмәкләр
Бик сирәк яңардылар,
Бик сирәк яңардылар да
Шактый еш ямалдылар.

Һаман шулай күз алдымда
Кечкенә чагым тора.
Сәләмәләр сагындырмый,
Бала чак сагындыра.

## Карт һәм үлем

*(Әкият)*

Тау башында таш кыя бар,
Таш кыяда таш сарай.
Шул сарайда гомер итә
Өч йөз яшьлек бер бабай.
Бабай шунда гомер иткән
Явыз үлемнән качып,
Үлем керә алмый икән
Сарай ишеген ачып.
Ә бер көнне үлем килгән
Кыз сурәтенә кереп.
Бабайның йөрәк кузгалган
Бу чибәр кызны күреп.
Кыз көлгән дә янгыратып,
Аннан дәшкән бабайга:
— Куеныңда жылыт мине,
Кертче, егет, сарайга.
Чибәр кызның сүзләренә
Бабай жаны эрегән.
Кызны кочагына алган
Һәм шунда ук жан биргән.

*Рөстәм Мингалимов*

## Кайту

Төнлә кайтам,
вагон тәрәзенә сарылып кереп киләм,
Татарстан, синең чигеңнән.
Иңнәреңә салган
төнге аяз күгең кем бүләге?
Шау йолдызлы,
ак ай чигелгән.
Якты планетага,
яшәү көче белән тибеп торган планетага
урнашканың төсле
урнашсаң да минем йөрәккә,
шундый олы бүләк
биралмадым үзеңә,
күпме теләп тә.
Дөрес,
синең күңелең кебек,
синең күгең кебек киң булалса фикерем
Синең хакта
йолдыз-йолдыз сүзләр генә сайлап
жыр язармын сыман тоямын,
бер бүләгем булыр иде сиңа,
бу да әле —
бары хыялым.
Кем бүләге икән,
кем бүләге икән
иңнәренә салган төнге күгең?
шау бизәкле,
ак ай чигелгән.
Вагон тәрәзенә ябыштырып куйган
рәсем кебек
кереп киләм,
Татарстан, синең чигеңнән.

## Ярлар хакында

Ага икән елга, аксын әйдә,
Әйдә, аксын ярларына тулып.
Гомеремдә бер тапкыр да әйтмәм:
«Ах, агарга, — диеп, — елга булып».

Азмыни соң «Уем елга» дигән,
«Уем океан» дигән шагыйрьләрне күрәм?
Азмыни соң
Минем башта уйлар?
Дулкыннары актарыла, үкерә;
Упкыннары
небоскреблар йота,
таулар йота,
йота жирнең үзен,
Һәм иң биек дулкын төбәсендә
Бер калкавыч булып калам үзем.

...Елгаларга артык исем китми.
Мине ярлар, ярлар кызыктыра
Ярлар шашкан дулкыннарны тотып,
Бер юнәлеш биреп, кысып тора.

Тирән фикер сыйган сүз шикелле
Ярлар ята горурланып, тулып.
Гомеремдә бер тапкыр да әйтмәм:
«Ах, агарга, — диеп, — елга булып».

*Гәрәй Рәхим*

## Рас

— Юк, мин үлемгә ышанмыйм! — дидем.
Катафалклар мыскыллап көлде.
— Юк, мин үлемне теләмим! — дидем.
Хәрби заводлар сүземне бүлде.

— Яшәү үлемнән көчлерәк! — дидем.
— Рас! — диде миңа төнге земфира.[1]
— Кешеләр үлем теләми! — дидем.
«Соңгы хәбәрләр» — Рас! — диде миңа.

— А-а-а, яшәү рәхәт! — диеп кычкырдым.
Җирдә һәрбер җан тын торды бераз.
Аннан көчле бер давыл шикелле
Кайтаваз килде:
Р-а-с!
Р-а-а-с!!
Р-а-а-а-с!!!

## Мәхәббәт

Мәхәббәт!
Мин шәрабка кушып эчәм сине.
Җырларыма кушып җырлап йөрим.
Төннәр буе сөйгәнемнең күзләреннән
Күз карашым белән сине урлап йөрим.

Кирәк чакта йөрәгемне сүгә-сүгә
Еллар аша һаман сине таптырам мин.
Очрашулар көткән чакта
Минутларга сине кушып
Поездларның тизлекләрен арттырам мин.

Җәйге кичнең шәфагына кушсам сине,
Зәп-зәңгәр күк кызылланып яна башлый.
Язгы кичнең җылысына кушсам әгәр,
Таулар буйлап гөрләвекләр ага башлый.

Кайчак сине күз яшемә кушып елыйм;
Чәчәкләрдән синең исне иснәп йөрим.

[1] Земфира — кичтән туып, иртән үлә торган төн күбәләге.

Һәм тагын да серле булсын болар диеп
Йолдызларга синең серне өстәп йөрим.

Төннәрендә сине онытып йоклап китсәм,
Төшләремә кереп мине табасың син.
Ничә еллар инде минә минем тәндә
Каным белән бергә кушылып агасың син.

Мин үземдә сине мәңге саклый алам;
Синең белән яши алам —
үлә алмыйм.
Тик шулай да һаман әле
Төсең нинди,
сының нинди икәнлеген
Белә алмыйм.

*Дифгать Сирай*

## Болытлар ашыга

Болытлар ашыга,
Җир шарын
Тизрәк әйләнеп чыгарга
Омтылган шикелле.
Тик кире әйләнеп аларның
Чабыша-чабыша бу якка
Кайтуы икеле.
Юлларда кыш та бар, җәй дә бар,
Кайсына баш ияр болытлар,
Тез чүгәр кайсына?..
Шул турыда уйлыйм мин
Басканда
Тормышның иң хәтәр, давыллы
Көннәре каршына.

●

Карагызчы, күкрәкләрен киереп,
Күгәрченнәр йөри җим чүпләп.
Шагыйрь дә бит
Шигъри юлларына
Сүзләр сайлый шулай бөртекләп.

●

Күчтәнәчең өчен рәхмәт, әнкәй,
Какъ җибәреп бик шәп иткәнсең.
Һөнәреңне белмәгәнмен яшьләй,
Үзең бигрәк оста икәнсең.
Маңгаема тирләр бөркелделәр,
Шифасыдыр инде кагыңның...
Бар бакчасын,
Карлыганы белән,
Кочтым гүя туган ягымның.

# *Замандашларыбыз*

*Фаик Мостафин*

## БӘХЕТЛЕ КЕШЕ

> Кешеләр, бигрәк тә авыру кешеләр өчен кирәк булуыңны тою, аларга кечкенә генә булса да ярдәм күрсәтә белү — тиңдәше булмаган зур бәхет ул.

**Х**орда тавышы аерылып ишетелеп торсын өчен солистның барысыннан да яхшырак җырлавы кирәк. Бу фән дөньясында да шулай. Галимнәр күп, ләкин чын галим булу өчен күп эшләргә һәм күпкә ирешергә кирәк.

Диләвер Зөбәеровка 34 кенә яшь әле. Институтны бетергәненә дә 10 ел гына. Ләкин ул шул кыска гына вакыт эчендә дөнья галимнәре танырлык хезмәтләр тудырды. Фән өчен дә, авырулар өчен дә күпне эшләргә өлгерде ул. Фән дөньясында яктылыгы күзне чагылдырырлык ук булмаса да, шифалы нурларын еракларга сибеп торган үзенә бер йолдыз кабызды. Аңа карата мондый караш галимнең хезмәтләре белән танышкач, дусларының һәм «дошманнарының» фикерләрен тыңлагач туа.



Аның фәнни хезмәтләрен социалистик ил галимнәреннән башка Англия, Америка, Канада, Бельгия, Германия Федератив Республикасы, Италия, Япония, Швеция, Франция һ. б. капиталистик ил галимнәре дә җентекләп өйрәнәләр, үз ил журналларына күчереп бастыралар. Бөтендөнья физиологиясенең житәкчесе Гейманс (Бельгия) Диләвер Зөбәеровка хезмәтләре өчен рәхмәт белдереп һәм һәр хезмәтен җибәрүне сорап хат яза. Ә немец галиме Э. Перлик үзенең 1965 елда басылып чыккан «Антикоагулянтлар» дигән китабының кереш сүзендә, китабы иртәрәк басылып чыгу сәбәпле, Совет галиме Зөбәеров хезмәтләрен файдалана алмавы өчен үкенеп һәм гафу үтенеп язган. Ләкин шунысы характерлы: үзенең ачышлары белән бөек галимнәргә билгеле һәм практик врачларның иң авыр минутларында киңәшчесе булган бу докторны авырулар ишетеп тә белмиләр. Ул башка врачлар кебек рәхмәт сүзләреннән торган хатлар, бәйрәмнәрдә котлау телеграммалары һәм чәчәкләр бәйләме алмый. Хәер, ул авыру янында төннәр буена утырып та чыкмый, йөрәк тибешләрен дә тыңламый, операцияләр дә ясамый. Аның эше врач өчен күңелсезрәк шартларда, лабораториядә, кечкенә генә кабинетында, китапханәләрдә эзләнеп үтә.

Хезмәтләре буенча ул инде яшь түгел. Илледән артык фәнни хезмәт һәм медицинаның иң авыр тармагы — кан оешу процесслары буенча язылган китап авторы ул.

Сирәк булса да, актуаль булмаган тема өстендә эшләүче кешеләр бар бит әле. Аларның хезмәт җимешләре корыган агачны хәтерләтә. Андый хезмәтнең хәзергесе дә һәм киләчәге дә юк. Зөбәеровның исә китабы да, фәнни хезмәтләре дә иң актуаль, иң кирәкле темага язылганнар. Менә шуңа күрә дә аның хезмәтләре басылып чыккан журнал тиз таушала. Аларны яшьләр дә, олылар да укый. Бөтен торышы белән студентка охшаган бу кеше трибунага менгәндә, зал тынып кала.

Күп кенә кафедраларда, гадәттә, старостадан студентларның лекциядә булу-булмавын күрсәткән исемлек таләп итәләр. Хәтта ул исемлек белән кафедра житәкчесе үзе кызыксына. Шул вакыйга хәтеремдә калган: студент вакытта дустым белән икебез, гафу ителерлек сәбәп аркасында, биохимия буенча ике лекциягә бармый калган идек. Шуның өчен мәрхүм профессор, башка студентларга да гыйбрәт булсын диптер инде, безгә: «Сез имтиханны стипендиягә бирә алмаячаксыз», дип кисәтте. Хәзер шул ук кафедраның житәкчесе — Диләвер Зөбәеров. Ә аның өчен мондый исемлекнең кирәге юк. Чөнки ул лекция укыганда, залда болай да буш урын калмый. Аның лекциясен тыңларга студентлар гына түгел, врачлар, аспирантлар, доцентлар һәм хәтта профессорлар да килә. Ул лекция укыганда, йоклап утыручылар юк. Зөбәеров лекциясе фикергә йокларга ирек бирми. Ул иң «күңелсез» биохимия фәнен иң күңелле фәнгә әйләндереп укый. Диләвер үз фәнен мөмкин кадәр клиникага якынайта, практика белән бәйли. Ул үзенең барлык хезмәтләрендә, барлык эшендә, иң элек — врач.

Яшь галимнең тиз арада шундый дәрәҗәгә ирешүен төрле кеше төрлечә юрый. Берәүләр: «Шулай булырга тиеш тә, ул фән өчен яратылган», дисәләр, икенчеләре: «Тормышның тәмен дә сизмичә, ямен дә күрмичә, көне-төне фән өстендә утырганга гына», дип көнләшәләр, өченчеләре исә: «Бәхетле кеше», дип сокланалар. Минемчә, бу фикерләрнең барысы да диярлек ачыклауны таләп итә. Ләкин бәхетле диючеләр хаклы. Чыннан да, ул бәхетле. Мондый бәхеткә ирешү өчен берәүләр күп вакытларын югалталар. Ә бик күпләр андый бәхеткә гомер буе да ирешә алмыйлар.

●

...Кайбер семьяларда баланың сәләтенә һәм нәрсә белән кызыксынуына игътибар итмәстән, аңа һөнәрне ата-аналары сайлый. Мондый очракта, еш кына ата-ана һәм бала арасында тавыш куба.

Алар семьясында бу мәсьәләдә икеләнүләр дә, ыгы-зыгылар да булмады. Урта мәктәпне тәмамлаганчы, Диләвер үзе дә, әти-әнисе дә киләчәктә кем булу, нинди һөнәр сайлау турында сүз дә катып карамады. Чөнки башта әле аттестат аласы бар иде.

Диләвер, соңгы дәүләт имтиханыннан кайтты да:

— Я, әти, әйт, әлегә кадәр кем буласын да белмәгән кеше ничек итеп өлгергән була инде ул? — диде һәм, елмаеп, алтын хәрефләр белән язылган «Өлгергәнлек аттестаты» белән бер генә «өчле» билгесе дә булмаган табелен сузды.

— Юк, улым, кем булырга теләгәнеңне мин дә, үзең дә яхшы беләсең. Ә әниең син туганчы ук кем буласыңны сөйли иде, шулай бит, анасы, — дип, Мирзабдулла абый Сәкинә апага карады.

— Врачмы?

Өчесе дә елмайдылар.

Дөньяда һөнәре дә һәм үзе дә тыныч кешеләр була. Андый кешеләр, эшләре беткәч тә, кәгазь-каләмнәрен өстәл тартмасына ташлыйлар да, киләсе көнгә кадәр эш турында уйлап та карамыйлар. Аннан бүтәннәргә дә, производствога да һәм ул кешенең үзенә дә зыян килми. Ә иҗат кешеләре, аерым алганда, врач, киресенчә, өенә кайткач та эше турында, авырулар турында уйлана, төшләрендә күреп, шулар белән саташа. Башкача ул булдыра да алмый һәм хакы да юк. Тынгысыз һәм авыр, шул ук вакытта мавыктыргыч һәм гүзәл бу хезмәтнең бөтен асылы да нәкъ әнә шунда. Бу хезмәт сәләт һәм талант сорый, шуңа күрә аңа теләсә кем өйрәнә дә алмый.

Күп кенә профессия вәкилләре, шулай ук сәнгать кешеләре, мәсәлән, скульптор, үз эшен бераничә ысул белән эшләп карый ала. Берсе канәгатьләндерми икән, икенчесе

барып чыга. Ә врачка андый ирек бирелми. Ул җан иясе, җан ияләренең дә иң олысы, иң төгәле — Кеше организмы белән эш итә. Димәк, нибары бер ысул, иң дөрес булган ысулны гына кулланырга кирәк. Ә моның өчен күпне белергә, күп укырга, эзләнергә, үзең ачышлар ясарга кирәк. Ләкин шунысы бар: сугышта куркакның да батыр булып калган очраклары була, ә фәндә алай түгел. Сабан туенда батырлар гына көрәшергә тиешле булган кебек, фәндә дә нибары хезмәтне яратучы көчле кешеләр, зур ихтыярлы кешеләр генә үз урыннарын таба. Һәм алар гына зур файда китерә ала. Фән ул җиңелчә карашны яратмый. Утыз ел буена врач булган ата врач булырга җыенган улына шуларны сөйләде һәм өстәп: «Вакытың, көчең һәм хәтта үзең дә кызганмаган кеше генә врач була ала. Күрәсең бит, өйдә дә халатым бар», — диде һәм чөйдә эленеп торган ак халатына карап ымлады.

●

Институтка кергәннең беренче көненнән үк, Диләвер, әтисе киңәшләрен исендә тотып, тырышып укыды. Укытучыларның, олы белгечләрнең сөйләгәннәрен отып калу өчен бөтен игътибарын биреп тыңлады. Күп укыды, һәр теманы тирәнтен үзләштерергә тырышты. Имтихан вакытларында аның фәннәрне бер-беренә нык бәйләп биргән җаваплары укытучыларны сокландыра иде. Хәтта укытучылардан аның белемен билгеләү өчен «бишле» билгесе түбән булудан зарланучылар да була иде.

Тәҗрибәле педагог Ишимова киңәше буенча, ул патологик физиология түгәрәгенә йөри башлады. Анда Диләвергә кан оешу процессын аңлаткан теорияләргә (ә алар күп) күзәтү докладны ясарга куштылар. Докладка әзерләнү чорында өченче курс студенты алдында дистәләгән «Ник?», «Нигә?» дигән сораулар туды. Ләкин бу сорауларга укытучылар да, хәтта фәннең ул вакыттагы торышы да төгәл җавап бирә алмый иде. Кафедра җитәкчеләре ул сорауларга җавап эзләп карауны Диләвернең үзенә йөкләделәр. Бу йөкләмәне шактый уңышлы ерып чыкты Диләвер. Темасы актуаль һәм хезмәтнең нәтиҗәле булуы аркасында, студент Диләверне илебезнең барлык медицина институтлары диярлек доклад ясарга чакырдылар. Аның бу фәнни доклады да, шулай ук аннан соңгылары да, I нче дәрәҗә дипломнар белән бүләкләнде. Ләкин бу уңышлар студентның башын әйләндермәде, ул яңадан-яңа көч белән эзләнүен дәвам иттерде. Һәм институтның алтынчы курсында күчкәч, кафедра утырышында студент Диләвер Зөбәеровның эшен кандидатлык диссертациясенә лаеклы дип таптылар.

Медицина буенча аспирантурага керү алдыннан, кимендә, 2 ел врач булып эшләргә кирәк. Бу гомуми кагыйдә. Дөрес, бу кагыйдәдән тайпылу очраклары да булгалый, ләкин бик тә, бик тә сирәк очракларда гына. Шундый сирәк очракларның берсе Зөбәеровка кагылмаска мөмкин түгел иде, һәм ул берсүзсез аспирантурада калдырылды. Аспирантурада укуының икенче елында ук Диләвер диссертациясен зур уңыш белән яклады. Аның хезмәте кан оешу сәбәпләренә карата ике фикернең берсен фаш итеп, икенчесен тагын да тулыландырды.

Гадәттә, кайбер кешеләр кандидатлык диссертациясен яклагач та, фән өстендә эзләнүне берничә елга туктатып торалар. Янәсе, баш ял итсен. Мондый нәрсә Зөбәеров өчен ят. Ул диссертациясен яклаганчы, аспирантурада укыганда ук, докторлык диссертациясе өстендә эшли башлаган иде инде.

— Вакытны оту гомерне озайта ул, — ди Зөбәеров.

Чыннан да, гомерне яшәгән вакыт белән генә үлчәмиләр бит. Эшең, хезмәтең — тормышның мәгънәсе. Бездә вакытның агышы алдан ук планлаштырыла. Һәм матур киләчәгебезнең кыска вакыт эчендә яулап алынуы да Зөбәеров кебекләрнең хезмәтенә, эшенә бәйле.

Ул кайбер галимнәр кебек үткән гасыр темалары белән мавыкмады. Физика һәм югары математика фәннәрен тирәнтен үзләштергәнгә күрәдер, аны электроника һәм кибернетика кызыксындырды. Хәзерге медицина фәнендәге иң актуаль теманы сайлап ала белүе, һәм ул теманы дөрес итеп хәл итүе, эшкәртүе һәм практикага кертүе аны галим буларак алгы сафка чыгарды.

Түбәндәге вакыйга килеп чыкмаган булса, Зөбәеров шул өлкәдәге фәнни эшен тагын да дәвам иткән булыр иде.

Көннәрнең берендә Диләвергә Казанның дәвалау клиникаларының берсендә булырга туры килде. Анда ул врачларның акыллы ярдәмчеләре: энцефалограф, ясалма бөер-

лэр, ясалма йөрәк һәм башка бик күп медицина фәне казанышлары белән таныштц. Операция бүлмәсендә Зөбәеров наркоздан әле уянып житмәгән авыруны һәм студентларга бу авыру турында сөйләп торган борчылулы хирургны күрде.

— Галимнәребез соңгы елларда кибернетика, электроника мәсьәләләренә нык кына игътибар юнәлтәләр, — диде хирург. — Бу бик яхшы, әлбәттә. Ләкин тормышта бик еш очрый торган авырулар күләгәдә кала. Шуның аркасында, кешеләр үлә яки, бүген күргәнегезчә, тегe я бу әгъзасын югалта. Менә бүген бу 23 яшьлек егетнең ике аягын да кисеп ташладык. Сәбәбе — кан юлында кан оешкан. Кан килмәү аркасында, аяклар үлә. Рак һәм башка рәхимсез авырулар рәтендә булмаса да, меңләгән кешенең тормышын бу авыру куркыныч астына куя. Үзегезгә мәгълүм, дошманны җиңү өчен аны яхшы белергә кирәк. Ә без әлегә кадәр кан оешуның сәбәпләрен белеп бетермибез. Шуны исегездә тотыгыз, сәбәбе беленгәч, авыруны пычак ярдәмендә түгел, дару ярдәмендә генә дәвалап булачак...

Бу сүзләр Зөбәеровның үзенә карата әйтелгән кебек булды. Хирургның һәр сүзе аның йөрәгенә пычак булып кадалды. Аның хирург сөйләгәнне ахырына кадәр тыңларга көче җитмәде, башын аска иеп, бүлмәдән чыгып китте. Әлеге бәхетсез егет һәм хирург, кая гына барса да, ни генә эшләсә дә, күз алдыннан китмәде. Берничә көн шулай уйланып йөри торгач, Зөбәеров: «Бу авыруның сәбәпләрен өйрәнү бүгенге көн һәм киләчәк өчен мөһимрәк», дигән ныклы карарга килде. Фән өчен генә түгел, бигрәк тә авырулар өчен мөһим иде бу тема. Чыннан да, бер генә кешене үлемнән алып калу да кирәге ашыгыч булмаган уннарча теоретик фикерләрдән өстенрәк бит. Зөбәеров инде нәтиҗәләре күренә башлаган бер еллык хезмәтен дә кызганмады, киләчәктә эшләр өчен калдырып торырга булды. Ул бу теманың үтә авыр булуын белә иде. Хәер, бернәрсә дә җиңел бирелми бит. Аннары ул җиңел уңышларга өйрәнмәгән дә. Һәм Диләвер, җиңен сызганып, бу авыруның серенә төшенү өстендә эшләргә керешә.

Бу мәсьәләне чишү буенча күп галимнәр тырышып карадылар. Бу авыру симпозиумнарның, съездларның көн тәртибеннән төшмәде. Ләкин һаман авыру үз серләрен яшереп килде. Алай гына да түгел, эзләнә барган саен, бу авыруга карата «Нигә», «Ничек?» дигән сораулар өстәлеп кенә торды. Бу өлкә тоташ күтәрелмәгән чирәм була килде. Билгесез тирәнлектәге һәм киңлектәге чокырлар аша күпер салу җиңел түгел иде, әлбәттә. Димәк, ул бу өлкәдә моңа кадәр тир түккән зур галимнәрдән дә ераграк күрергә тиеш иде.

Шуңа күрә дә: «Олы галимнәргә дә бирешмәгән өлкәдә эзләнеп көлкегә генә калуы бар», дип уйлаучылар булмады түгел. Тагын шундый нәрсә сөйлиләр: имеш, медицина галимнәренең берсе мәрхүм профессор Н. В. Соколовка: «Мин бу темага һич тә бәйләнмәс идем», дигән. Профессор үзе дә: «Мин дә», дип җавап биргән һәм: «Беләсезме нигә? Сез дә, мин дә бу өлкәдә бернәрсә дә тудыра алмас идек. Ә ул ерып чыгачак», дип өстәп куйган.

Зөбәеров үзенә бала чактан ук хас булган тырышлык белән бу авыруның үзенчәлекләрен өйрәнергә, медицинаның бу өлкәсе буенча белемен киңәйтергә керешә. Көнгә 15—17 сәгать буена китапханәдә, лабораториядә утыра, уйлана, эзләнә. Тормыш иптәшенең киногa дип алган билетлары галимнең кесәсендә калган очраклар да еш була. Күршеләрнең яңа һәм бөтен коммуналь шартлары булган квартираларга күчүләре дә аның игътибарын җәлеп итми. Күп кенә төннәрен көнгә әйләндереп эшли ул. Бу темага кагылышы булган хезмәтләр белән танышу өчен инглиз һәм немец телләрен бөтен нечкәлекләре белән өйрәнә. Советлар Союзындагы белгечләр һәм чит ил галимнәре белән киңәшә. Лабораториядә күп кенә приборларны һәм аппаратларны үзе ясый. Шунысы характерлы: күпләр өчен үтә авыр булган бу катлаулы хезмәт аңа шатлык кына китерә.

Аның таланты, үзен-үзе кулга ала белүе, үзенә карата үтә таләпчән булуы бу авыр бурычны гамәлгә ашырырга мөмкинлек бирде: авыруның күп кенә яшерен серләре ачыкланды.

Ачыш зуррак булган саен, аны ачыклау өчен сүз азрак кирәк. «Аның ачышы — үз өлкәсендә яңа чор», диделәр докторлык диссертациясен яклаганда оппонентлары. «Киләчәктә салыначак мәгърур бинаның нигез ташлары», дип бәяләделәр өлкән галимнәр аның хезмәтен.

Ә галим һәрвакыттагыча һаман үз-үзеннән канәгать түгел иде. Бу хезмәтен ул үзе киләчәктә алга бару өчен старт сызыгы итеп карады. «Эзләнү бетмәде, киресенчә, баш-

лана гына», — дип йомгаклады ул диссертациясен яклаганда үзенең соңгы сүзен. Чынлыкта исә, аның бу хезмәте авыруның чын йөзен ачыкларга ярдәм итте һәм аның белән көрәшү өчен иң яхшы ысул күрсәтте.

Гадәттә, галимнең уңышларын укытучысыннан, житәкчесеннән күрергә тырышалар. Бу очракта бөтен хикмәт тә шунда: Зөбәеровның укытучысы да, житәкчесе дә булмады. Чөнки бу өлкәдә анардан да яхшырак белгеч юк иде әле.

Шулай итеп, Диләверне эшкә житди караш, хезмәткә чиксез мәхәббәт танылган кеше итеп үстерде. Аның эш көне алдан планлаштырган эшләре беткәч кенә бетә. Һаваның начар яисә яхшы булуы да, күңеленең шат яисә кайгылы булуы да аның өчен киртә түгел. Ул һәртөрле шартларда да эшен дәвам итә ала.

Кимчелексез кеше булмый, диләр. Ә менә Зөбәеровны яхшы белгән кешеләр бу фикер белән бик үк килешеп бетмиләр. Чыннан да, бу кеше, ничектер, кимчелексез кебек. Аның турында сөйләгәндә, кешеләр иң якыннары, дуслары, туганнары турында сөйләгән кебек ягымлы итеп, яратып һәм олылап сөйлиләр. Зөбәеров бервакытта да тавышын күтәрмәс, һәркемгә ягымлы, мөлаем. «Аның белән эшләве жиңел һәм күңелле», диләр шәкертләре.

Ләкин бер кимчелеге бар икән: үзе турында да, эше турында да Диләвер сөйләргә яратмый. Шуңа күрә дә аны аз сүзле, күңелсезрәк кеше, дип уйлаучылар да юк түгел. Әмма ул бер дә күңелсез кеше түгел: эш һәм фән турында сүз барганда, Диләвернең йөзе яктырып китә, сәгатьләр буена син аны ялыкмый тыңлыйсың. Фән дөньясына атлаучы яисә күбрәк белергә тырышучы кеше белән сәгатьләр буена сөйләшеп утыруын аклап, ул: «Алар белән сөйләшү, аларга киңәш бирү минем төп эшем», — ди. Үзе янына Диләвер бервакытта да берничә кешене чакырмый. Киңәшкә килгән кешегә кимсетеп карамый, ә киресенчә, үзенә тиң һәм якын кешесе итеп сөйләшеп утыра. Бәлки, сүзне тизрәк җайга салу өчендер, башта кешене тыңлый. Шуннан соң гына үзе сөйли башлый. Галимне баскычта да, залда да һәм хәтта урамда да туктаталар. Күп кенә олы галимнәр үзләренең укучыларын аңа киңәшкә жибәрәләр, үзләре дә киләләр. Диләвернең, болай караганда, һәрнәрсәгә вакыты житә кебек, ләкин һич алай түгел, аның һәр минуты исәпле.

Галимнең эш көне иртәнге алтыдан башлана. Вакытны әрәм итмәс өчен, иртәнге гимнастика ясаганда, чит ил телләрен кабатлый. Аннан балаларын яслегә илтә. Аннары инде, үзе әйтмешли, «чын хезмәте» башлана: кафедра эшләре, лекция уку, китапханәдә утыру, «Казан медицина журналы» редакциясендәге эшләр, (ул бу журналның редактор урынбасары), тәжрибәләр... Кичен өйгә кайткач, беркадәр балаларның күңелен таба да төннәрен укый. Өендә аның зур китапханәсе бар. «Хәзерге заманда иске багаж белән яшәп булмый, һәр көн күз ияремәслек яңалыклар китерә», — ди ул.

Галимнең хәзерге планы — эшлекле коллектив булдыру. Менә ул ирешеп тә килә инде. Аның шәкертләре дә уңышлы гына тикшеренү эшләре алып баралар. Мәсәлән, аспирант Тимербаевның ике хезмәте Америка журналларында да басылган инде. Шунысы характерлы: аның кафедрасына бары эш сөючә кешеләр генә килә. Ялкау кешеләргә аның янында урын юк. Аның шәкертләре дә, биохимия түгәрәгенә йөргән студентлар да онытылып эшләргә сәләтле кешеләр.

Әйе, ул ирешелгәннәр белән генә канәгатьләнеп яши торган кеше түгел. Чөнки бәхет бит ул башкарылган эштә генә түгел, ә башкарылачак эштә, киләчәктә.

———◆———

*Җәмил Мостафин*

# БӘЛӘКӘЙ БУЛСА ДА...

*Очерк*

## «Үзем дә... белмим»



Беркайчан да редакциядән мондый кыен эш алганым юк иде әле минем. Беренче карашка бик гади генә кебек: атаклы футболчы, якташыбыз Галимҗан Хөсәенов турында очерк язарга. Әйе, бары тик шул гына. Ләкин...

Ике ай вакыт үтеп китте инде, минем әле Хөсәеновны күрә дә алганым юк. Ә редакциядән: «Очерк көтәбез!» — дип әледән-әле шалтыратып торалар һәм миңа бик үк ышанып җитмичә:

— Мәскәүдә яшәп, ничек инде шушы вакытка тикле Хөсәеновны күрә алмаска?» — дип гаҗәпләнәләр. Көн аралаш диярлек шалтыратып, Галимҗан хатыны Любаның теңкәсенә тиюемне белсә иде алар! Соңгы көннәрдә ул: «Мин үзем дә аның кайда икәнлеген һәм кайчан кайтачагын белмим. Футбол федерациясенә шалтыратып карагыз»,— дип кыска гына җавап бирә башлады. Ә федерациядән: «Әгәр алай-болай үзгәреш килеп чыкмаса, җыелма команда апрель ахырларына кайтырга тиеш. Үзегез беләсез, төрле хәлләр була бит», — дип җавап бирделәр.

«Алай-болай үзгәреш килеп чыкмаса...» Күрәсез, минем хәл шәптән түгел иде. Редакция очерк көтә. Ә Хөсәенов исә, СССРның җыелма футбол командасы члены буларак, инде дүрт ай буенча чит ил футболчылары белән көч сынашып йөри.

## Алтын зур булмый

Ниһаять, газеталарда: «... СССРның җыелма командасы егерме тугызынчы апрельдә Мәскәүгә кайтачак...» дигән хәбәр басылып чыкты. Һәм мин, бу кайтуында Хөсәеновны ничек тә эләктерергә кирәк, дигән ныклы карарга килдем. Чөнки ике-өч көнгә генә соңарсам да, Хөсәеновны июнь айсыз очрата алмаячак идем. Бәйрәм көне булуга

карамастан, өенә шалтыраттым. Трубканы Люба алды. Аның «сине сорыйлар» дип Галимҗанга дәшүен ишеткәч, йөрәк ешрак тибәргә тотынды: әләкте бит болай булгач. Сарып чыга бит эшләр!

Мин Галимҗанга ни өчен шалтыратуымны әйттем һәм минем белән очрашуын таләп иттем. Әйе, чын-чынлап таләп иттем, чөнки башкача мөмкинлегем юк иде.

Аптырата торгач, аны өченче майда очрашырга ризалаттым. Дүртенә калдырып булмый: ул Киевка очачак иде.

Таң алдыннан сибәләп үткән янгыр асфальт урамнарны, әйтерсең, ялтыравыклы кара буяу белән буяп куйган. Мәскәү һаман саен җанлана, күңелләнә бара. Горький урамы халык белән шыгрым тулы. Ял көне булуга карамастан, троллейбуслар буш диярлек йөри. Кешеләр яз һавасын иснәргә телиләр, шуңа җәяү йөриләр иде, күрәсең. Мәскәү урамнарында бөре исе, яфрак исе, агач исе аңкый.

Бер сүз белән генә әйткәндә, ул көн минем өчен уңышлы булырга охшаган иде. Ләкин... килешү буенча, нәкъ кичке җидедә шалтыратсам да, Галимҗан:
— Гафу итегез, иртәгә калдырырга мөмкин түгелме? — димәсенме.

Икебез дә сүзсез торабыз: Галимҗан миннән җавап көтә, ә мин нишләргә, нәрсә дип җавап бирергә аптырап торам.

— Юк, без бүген очрашырга тиеш, Галимҗан. Мин сезне аңлыйм, әмма сез дә минем хәлне аңлагыз! — дим мин, үтенеп тә, бер үк вакытта таләп тә итеп.

— Ярый, очрашыйк алайса, — ди Галимҗан, ниһаять, миннән котылырга чара таба алмыйча.

Хөсәеновның буе футболчы өчен әллә ни мактанырлык түгел. Иптәшләре аны, яратып һәм үз итеп «Бәләкәч» дип кенә йөриләр. «Футбол кырына чыккач, үзеннән озын кешеләрдән бер башка югары торырга, туп өчен көрәшкәндә шул ук озын һәм зур гәүдәле кешеләрдән өстен чыгарга нинди көч ярдәм итә икән соң бу «Бәләкәч»кә? Хөсәеновларга барганда менә шушы сораулар борчыды мине. Минемчә, даны дөньяга таралган футболчы шактый таза һәм озын буйлы булырга тиеш иде, һәрхәлдә, мин шулай күз алдыма китерә идем. Ә каршымда... оялчан гына елмаеп, уртача гына буйлы гап-гади бер кеше. Коңгырт-кара күзләре, салынкы куе кашлары аны җитди, хәтта бераз кырысрак та итеп күрсәтә. Әгәр ирен читләрендәге елмаюы һәм иягендәге борчак салып куярдай чокыры булмаса, Галимҗан турында шактый күңелсез кешедер бу дип уйларга мөмкин булыр иде.

Миңа Хөсәенов турында кызыклы итеп, аның тормышыннан ниндидер гадәттән тыш хәлләр табып язарга кушканнар. «Гадәттән тыш»ны кем ничек күз алдына китерә торгандыр — анысын белмим, әмма мин ул «гадәттән тыш» нәрсәне Галимҗан ишек ачуга ук күрдем. Чыннан да, буе нибары 164 см., авырлыгы 64 килограмм гына булган гади татар малаеның бөтен дөньяга танылган атаклы футболчы булуы «гадәттән тыш» хәл түгелмени? Мондый дәрәҗәгә ирешү бәхете бөтен кешегә дә тәтеми ләбаса!

Мин Галимҗанны футбол кырында алты тапкыр гына күргәнем бар. Соңгы тапкыр узган елның июнь аенда Бразилия җыелма командасы белән уйнаганда күрдем. Соңыннан бразилиялеләр тренеры, безнең җыелма члennарыннан өч яхшы футболчының берсе итеп, Галимҗан Хөсәеновны атады (калган икесе — Воронин, Метревели). Ә бөтен дөньяда тиңдәше булмаган легендар футболчы Пеле, Галимҗанга карап: «Кечкенә булса да — төш кенә» дип елмаеп куйды.

Футбол тәртипләрен бераз аңлаган һәр кеше бу уенда буй һәм авырлыкның шактый зур әһәмияткә ия булуын яхшы белә. Әйтик, буй — югарыгы тупларны баш белән эләктереп алу өчен кирәк булса, авырлык — көндәшең белән җирдәге туп өчен көрәшкәндә бик мөһим. Ә Галимҗанда, инде әйткәнебезчә, авырлык та, буй да чамалы. Әмма уен вакытында аның кечкенәлеге дә, җиңеллеге дә сизелми. Үзеннән күп озын футболчылар белән югарыгы туп өчен көрәшкәндә дә, җирдәгесе өчен тартышканда да югалып калмый гына түгел, хәтта һәрвакыт диярлек җиңеп чыга ул. Ә аның тупны почмактан бирүе? Белмим, безнең футболчылар арасында тупны почмактан Хөсәенов кебек төгәл һәм нәтиҗәле итеп бирә белүче кеше күпме икән? Кыскасы, әлеге бәләкәй генә Галимҗаныбыз футбол кырына чыктымы — бермә-бер үсеп киткәндәй була. Моның шулай икәнлегенә ышану өчен, Хөсәенов катнашында үткән берәр футбол мат-

чын карап тору да бик җиткән. Шикләнмичә әйтергә мөмкин, каршы як уенчылар капкасы төбендә матч барышында ун кискен момент була икән, шуларның, ким дигәндә, дүртесе Галимҗан Хөсәеновкә бәйле булыр.

Хөсәеновларга мин бер сәгатькә дип кенә килгән идем, бактың исә хәтсез утырылган икән. Без аның белән футбол турында гомумән генә сөйләштек шикелле. Сүз, нигездә, Лондонда үткәреләчәк дөнья беренчелеге, хәзерге футбол уены тактикасы, бүгенге әйбәт футболчылар турында барды. Люба безгә бик күп һәм кызыклы фоторәсемнәр күрсәтте. Галимҗанның футбол уйнау тарихын чагылдыручы ул рәсемнәрне карагач, үземне атаклы футболчы белән берничә ел бергә яшәгәндәй хис иттем.

## Ул да урам командасыннан башлаган

Атаклы булу өчен, кешегә биш процент талант һәм туксан биш процент хезмәт кирәк, дигән Толстой. Үз гомерендә беренче мәртәбә тупка типкәндә, Галимҗан бөек фикер иясенең бу сүзләрен белгәндер дип тә әйтә алмыйм. Ихтимал, аның бу хакта ишеткәне дә булмагандыр әле. Ләкин ничектер шулай килеп чыккан инде, табигать эш сөю талантын Галимҗанга бик яшьли биргән. Унөч яшьлек чагында Галимҗанның авырлыгы нибары 30 килограмм, буе исә метрдан чак кына артыграк була. Үз иптәшләре арасында иң кечкенә һәм иң ябык Галимҗан йөгерүгә килгәндә, дөрес, сер бирми, әмма менә тупка тибүенең һич тә рәте булмый инде.

— Галимҗан, тупка син түгел, туп сиңа тибә бит! — дип көлгәннәр аннан иптәшләре.

Башка берәү булса, мондый хәлләрдән соң, ихтимал, тупка бөтән әйләнеп тә карамас иде. Әмма Галимҗан аның саен үҗәтләнебрәк туп куарга керешә. Иптәшләре өйләренә таралышкач та әле Галимҗан берәр сәгать чамасы, үзе генә калып, туп тибә. Хыялындагы «дошман» капкасына гол кертә, туп куып бөтен урамны әйләнеп үтә һәм бары тик шуннан соң гына тәмам арып өенә юнәлә. Белмим, бу хәл күпме шулай дәвам иткән булыр иде икән, әмма көннәрдән бер көнне урам командасының «патша»лары «Динамо» стадионына юнәлгәч, Галимҗан да алар артыннан иярә. «Синең, Галим, барып йөрмәвең хәерлерәк булыр, анда тикшереп карыйлар бит», — диләр аңа, дусларча киңәш итеп. Ләкин үзсүзле Галимҗан һич тә аптырап калмый, кашларын җыера да: «Тикшерә бирсеннәр», — дип, «патша»лардан калмыйча, стадионга бара. Мәсьәлә менә болай хәл ителә: тренер Михаил Андреевич Санин әлеге «патша»ларның бик азын гына калдырып, күбесен бракка чыгарып кайтарып җибәрә. Калучыларның берсе Галимҗан Хөсәенов була. Ләкин Галимҗанның шатлыгы озакка бармый. Михаил Андреевич аны саф алдына чыгарып бастыра да, төртеп күрсәтеп:

— Менә син әйт әле, фамилияң ничек? — дип сорый.

— Хөсәенов, — ди Галимҗан, каушап.

— Менә Хөсәенов сезнең арада иң йомшагы. Буе да мактарлык түгел, көче дә бик чамалы. — Аннары тренер еларга җитешеп торган Галимҗанның иягеннән тота да:

— Әмма зыян юк, сөяге булса, ите үсәр, — дип өстәп куя.

Менә шул көннән башлап Хөсәенов футбол уйнарга тренер кулы астында өйрәнә башлый.

Халыкка танылгач, спортчылар гадәттә үзләренең беренче тренерларын нигәдер онытучан булалар. Ә менә Галимҗан Михаил Андреевич турында зур хөрмәт белән сөйләде:

— Әгәр дә Михаил Андреевич ул чакта берничә ел рәттән мине өйрәтмәгән булса, — диде ул, — белмим, мин футболчы булып китә алыр идемме икән? Соңыннан да онытмады мине Михаил Андреевич. Бер заман мин хоккей, җиңел атлетика белән мавыга башлагач, ул миңа төрле якка чәчелмәскә кушты. — Спортның бар төре дә әйбәт, — диде ул, — әмма синең өчен иң мөһиме — футбол.

Башта Галимҗан Куйбышев шәһәрендәге балалар, аннары яшьләр командалары арасында иң яхшы һөҗүмче булып танына, аннары мастерлар командасы — «Крылья Советов»та уйный. Ә 1961 елда ул илебездәге футбол командалары арасында иң билгеле һәм көчлеләреннән берсе булган «Спартак» командасында уйный башлый.

Мин ул елны яхшы хәтерлим әле. Ул чакта күп кенә болельщиклар «Спартак»ның бәхете юк дип уйлый башлаганнар иде. Әмма хикмәт бәхеттә түгел, «Спартак»ның

«картаюында» иде. Дөньяда һәрнәрсә үзгәреп тора, ә футболда бигрәк тә. Хәзер инде «Спартак»ны данлыклы футболчы Игорь Нетто да коткара алмый иде. Команда һәрвакыт җиңеп кенә килгәнлектән, тренерлар аңа вакытында алмаш әзерләү турында онытып җибәргәннәр иде.

Әле беркемгә дә билгеле булмаган унберенче номер ул командага «Спартак»ның хәле менә шундый авыр чакта килеп керде.

Мәскәү болельщиклары футбол уенының рәтен дә бик яхшы беләләр (кирәк икән, тот та теләсә кайсын судья итеп куй!) һәм уенчының осталыгын да тиешенчә бәяли алалар.

Галимҗан үзен ничек хис иткәндер — белмим, әмма диктор унберенче номерлы майкада егерме дүрт яшьлек Галимҗан Хөсәенов уйнаячагын белдергәч, «Спартак» болельщиклары шаулашып-куркышып алдылар. Галимҗан үзе: «Ул турыда онытгым инде», — ди. Аннары көлемсерәп өстәп куя: «Дулкынланганмындыр инде, әлбәттә. Ни әйтсәң дә, «Спартак» бит!»

Ә читтән караганда хәл менә болай булды ул уен вакытында: Галимҗан башта ничектер үзенә урын таба алмыйча йөргән сыманрак күренде. Һич көтмәгәндә уң яктан сул якка чыкты, я сакчы вазифасын үтәргә тотынды, ул да түгел, кыр уртасы буйлап җан-фәрманга алга ыргыла иде. Аның болай һәр урында «буталып» йөрүе, сул һөҗүмче өстенә йөкләнгән бурыч ноктасыннан караганда, шактый сәер тоела иде. Уенны тамаша кылучылар бу хәлне башта тыныч кына карап тордылар, аннары борчылып сызгырырга керештеләр.

Уенның беренче яртысы тәмамланып, калган яртысы да башланып китте. Әмма сул һөҗүмче әле һаман житез, көчле иде. Хәзер инде тамашачылар да сызгырмыйлар, киресенчә, «авыл малае»ның «буталуында» ниндидер үзенә бертөрле тәртип, өметле яңалык күреп, ара-тирә кул чапкалый башладылар. Галимҗан тупны көндәшеннән бик оста итеп эләктереп алган яисә аны көтмәгәндә алдап куйган чакларда:

— Шулай кирәк ул күсәкләргә! Тырыш, Бәләкәч, тырыш! — дип кычкырып, куәт биреп торалар иде...

Ул көнне зур футболга, үзенең яңа уен алымы белән, Галимҗан Хөсәенов дигән талантлы футболчы өстәлде. Яңа спорт йолдызы калыкты. Аннары Галимҗан кебек һәр линиядә дә бик оста уйнау алымын без бразилиялеләрдә күрдек.

Шул көннән башлап, Галимҗан Мәскәү тамашачыларын үзенә әсир итте. Хәзер аның буе кыска булуын беркем дә сизми инде.

Һәр атаклы спортчының бөтен тормышында якты эз калдырган истәлекле вакыйга була. Беренче карашка ул вакыйга әллә ни әһәмиятле дә булмый, чөнки, гадәттә, озак та үтми, спортчы үзе ирешкән уңышны тагын да арттырып җибәрә һәм аның беренче уңышы соңгылары янында бик кечкенә булып кала. Даны бөтен дөньяга таралган йөгерүче Владимир Куц белән дә шулай булган. «Минем өчен иң кадерле, иң әһәмиятле җиңү — 1947 елда хәрби часть беренчелегенә үткәрелгән кроссга беренчелекне алу булды, дип, ул миңа үзе сөйләгәне бар. Ә аның ул чактагы нәтиҗәсе икенче разряд йөгерешченекеннән чак кына өстен була. Аннан соң Куц бик күп җиңүләргә ирешә, хәтта бөтен дөньяда беренчелекне яулап ала, әмма шулай да теге беренче җиңүе аның өчен иң кадерлесе булып калган.

Шул ук турыда миңа дөньяда тиңе юк дип саналган америкалы Андерсенны 1960 елны Римда җиңеп кайткан штангачы Юрий Власов белән дә сөйләшергә туры килгәне бар.

— Зур җиңү бу, әлбәттә, — диде ул чакта Власов, кулындагы магнезияне сыпыргалап. Аннары күзлеген сөрткәләп бераз уйланып торды да, елмаеп: — Ә шулай да минем өчен иң кадерле җиңү — моннан дүрт ел элек академия беренчелеген оту булды, — диде.— Дөрес, ул чакта өч төр буенча нибары өч йөз килограммнан аз гына артыграк күтәргән идем мин...

Ә безнең Галимҗанның иң истәлекле уены... беренче мәртәбә Мәскәү командасында уйнау дип уйламагыз тагын. Юк. Европа кубогы өчен темпераментлы испанлылар белән финал уенында катнашу да түгел. Аның өчен иң истәлекле көн — 1962 елгы СССР беренчелегенә көрәш вакытындагы бер уен.

Ул чакта «Спартак», иң алда баручы командадан 8 очкога калышып, арттагылар рәтендә килә иде. Хәтта «Спартак»ның иң дәртле болельщиклары да аның хәле яхшы-

руга өметләрен өзгәннәр иде инде. Өзәрлек тә шул: хәлне яхшырту өчен, ярты очкоиы да кискен көрәшсез бирми торган Мәскәү һәм Киев «Динамо»ларын, ЦСКА һәм «Торпедо» командаларын җиңәргә кирәк иде бит.

Менә шундый кискен моментта «Спартак» кинәт танымаслык булып үзгәреп китә. һәм ул үзгәрешнең сәбәпчесе «Спартак» өчен бары тик икенче генә сезонын уйнаучы әлеге дә баягы шул Галимҗан Хөсәенов була.

## Бер, ләкин берәгәйле

Ташкентта «Пахтакор» белән очрашу уңышсыз башланды: уенның беренче яртысы ташкентлылар файдасына 2:0 белән тәмамланды.

Үз кырында башта ике туп отып та икенче таймда оттыруга дучар ителгән командалар футбол тарихында бик сирәк. Дөрес, безнең «Динамо» командасы 1946 елны Лондонда беренче таймда өч туп оттырып, икенче таймда 4—3 исәбе белән җиңгән иде җиңүен. Ләкин, кабатлап әйтәм, и п т ә ш л ә р ч ә очрашу иде ул. Ул чакта Всеволод Бобров аеруча яхшы уйнаган иде.

Ташкентта да шундый ук хәл булды: икенче таймда «Спартак» «Пахтакор»ны отып җиңүгә иреште һәм ул җиңүнең сәбәпчесе Галимҗан Хөсәенов булды.

Беренче таймда ике туп оттырып, тәмам аптыраштa калган «Спартак» икенче таймга төшенке күңел белән чыкты. Уенчыларның кыяфәтләре «бу кырык биш минутны ничек кенә үткәрергә» инде дигән сыман иде. Бары тик иң арттан чыккан уенчының гына йөзе тыныч иде. Менә ул, сөйкемле елмаеп, «Пахтакор» болельщикларын сәламләде, аннары үзе белән рәттән баручы каршы як уенчысына ниндидер кызык сүз әйтте һәм кычкырып көлеп алды. Стадион табагы ниндидер кызу һава белән тәеп тутырылгандай тоела, хәтта яшел футбол кыры да эссе бөркеп торган сыман иде. Болельщикларның кыяфәтеннән үз командалары җиңүенә шикләнмәү, мәсьәләне хәл ителеп беткән санау бик ачык сизелеп тора. Хәтта, уен башлануын белдереп, судья сыбызгысын сызгырткач та, трибуналарда шактый вакыт гадәттәге үзенә бертөсле сак тынлык урнаша алмыйча торды: ташкентлылар үз урыннарына таба акрын гына атлый һәм бик җанланып үзара сөйләшәләр иде. Мәскәүлеләрнең ярсып-ярсып һөҗүм итүләренә алар бөтенләй игътибар да итмәделәр. «Спартак»ның кыса башлавын «Пахтакор» футболчылары гына сизә иде әле. Аларны аеруча сул һөҗүмче борчый. Тизлеге, бер урыннан икенче урынга туктаусыз күчеп, каршы як уенчысын оста гына алдап китә белүе Галимҗанны һич тә тотып булмаслык итә иде. һәм аның әнә шундый «буталчык» рейдларының берсе гол кертү белән тәмамланды. Уенчылар да, футбол сөючеләр дә нәрсә булганын рәтләп төшенә дә алмый калдылар. Андый чакта гадәти хәл булган кул чабулар да, сызгырулар да ишетелмәде.

Ә чынлыкта барысы да гап-гади эшләнгән иде югыйсә! Галимҗан башта тупны кыр уртасыннан бик тиз генә каршы як капкасына таба алып китте, аннары аны артындагы иптәшенә тапшырды да үзе уң яккарак күчте һәм, «Пахтакор» сакчысын алдап, ялт итеп, үзенең яраткан сул ягына килеп чыкты да иптәшләре җибәргән тупны эләктереп алды. «Пахтакор» сакчысы өненә килергә өлгергәнче, тупны капкага тибеп тә кертте...

Уенны кыр үзәгеннән башлау өчен, судья сыбызгысын сызгыртса да, туп әле һаман, ауга эләккән кыр тавыгыдай, ятьмә эчендә тырпылдап ята, чөнки ташкентлылар бу көтелмәгән голдан аптырап калганнар иде.

Галимҗан үзе күренми. Аны иптәшләре урап алганнар һәм һәркайсы котлап үбәргә тырыша иде.

Спартаклыларны, әйтерсең, алыштырып куйдылар — беренче таймдагы уенчыларга һич тә охшамый иде хәзер алар. Уен кызганнан-кыза барды. Әлегә бер якның да өстенлеге сизелми. Нәкъ сабан туенда бертигез көчле ике кеше таяк тартышкандагыча. Ләкин «Спартак» ныграк тырыша, ялгышларны азрак җибәрә һәм әлеге тигезлек бозылып, үлчәү тәлинкәсе мәскәүлеләр ягына авышып китә. Моның сәбәпчесе тагын шул ук безнең Хөсәен була — нәкъ беренчесендәгечә диярлек комбинация ясап, «кыр тавыгын» ауга ул куып кертә. Исәп 2:2! Трибуналарда утыручы ташкентлылар, ни эшлә-

гәннәрен үзләре дә белмичә, кычкыралар, сызгыралар — откан «Пахтакор» оттырып ята лабаса!

Уенны кыр үзәгеннән тагын «Пахтакор» уенчылары башлый. Хәзер инде бер Галимҗанны ике «Пахтакор» уенчысы сакларга керешә. Ә Галимҗанга шул гына кирәк тә: ул үзен саклаучыларны ымсындырып читкә алып китә дә тупны ялт кына үзәк һөҗүмче Рейнгольдка бирә һәм... уен нәтиҗәсен хәл кылучан өченче туп каршы як капкасына барып та керә.

Бу матч турында бөтен газета-журналлар «Хөсәенов матчы» дип язып чыктылар. Һәм алар хаклы иделәр. Әлеге уенда җиңеп чыкканнан соң «Спартак» бер командага да оттырмады һәм 1962 елны «СССР чемпионы» дигән исемне яулап алуга иреште.

## 240 минутка сузылган уен

Футбол уенында мондый хәл була, әмма бик сирәк.

Кубок уеннарының кагыйдәләре үк матчның кискен булуын билгели. Кубок бер як та җиңмәгән уеннарны сөйми, аңа бары тик җиңү генә булсын.


Бу юлы финалга Минск «Динамо»сы белән «Спартак» чыкты.

Яшь һәм әйбәт уенчылардан торган Минск командасы уенны бик кызу темп һәм төрле комбинацияләр белән башлап җибәрде. Өченче минутта ук минскилылар үз иптәшләре Арзамасцевны котларга, кочакларга керештеләр. Тупны өрлек астына бик оста тибеп кертеп, ул Минск командасын алга чыгарды. «Спартак»ның кунакларга күзмә-күз оттыруы иде бу. Шул кыен минутта үзенең салкын канлылыгы, каушап калмавы белән Галимҗан Хөсәенов кенә аерылып тора иде. Өстенлек үз якларында икәнлеге күренеп торуга карамастан, минскилылар уен чылбырын кай җиреннәндер йомшартып җибәрделәр һәм бу хәлне дә иң әлек Галимҗан тоеп алды.

Галимҗан үзәктә хәйләкәр комбинацияләрне һаман саен күбрәк «үрә» барды. Ә икенче таймның егерме өченче минутында исә Рейнгольд штраф мәйданчыгына биргән тупны башы белән бәреп, бик матур гол кертте. Шулай итеп, Галимҗан Хө-



Г. Хөсәенов «Динамо» сакчысы В. Царевны узып бара.



Галимҗан Хөсәенов (сулдан беренче) Казан туристлары белән Париж урамнарының берсендә.

сәенов бу юлы да командалар арасында тигезлек урнаштырды һәм иптәшләренең ышанычын арттырып, күңелләрен күтәреп җибәрде.

Ул көнне алтмыш минутлык өстәмә уен нәтиҗә бирмәде. Бәхәсне хәл итү икенче көнгә калдырылды.

Икенче көнне дә «Лужники» халык белән шыгрым тулы иде. «Спартак» командасы футбол кырына килеп чыгуга, мәскәүлеләр бер авыздан: «Хө-сә-енов! Хө-сә-енов!» дип сузып кычкырырга керештеләр...

Хәзер мин ул уеннан соң спорт күзәтүчеләр язган отчетны китермәкче булам. Бик кыска һәм матур язылган ул: «9 нчы минутта, Хөсәенов биргән тупны алып, Фалин бик тиз генә алга ыргыла, һәм, аның бик каты тибүеннән соң, штангага бәрелеп, туп читкә атыла. Ә аннары? Аннары менә нәрсә була: флангта «аксаган» Лагофет әлеге тупны эләктереп ала да, бик төгәл итеп, үзәктә торган Фалинга бирә. Фалин — Янишевскийга, Янишевский үзәктән чабып баручы Хөсәеновка бирә һәм — Галимҗанның тибеп җибәрүе була — туп каршы як капкасына барып та керә. Исәп 2:1...»

Кубокның язмышы менә шулай хәл ителә. Ул минутларда кырда бер Хөсәенов кына уйный иде шикелле, чөнки йөз меңләгән болельщиклар бер авыздан: «Хө-сә-енов! Хө-сә-енов! — дип тәкрарлыйлар иде.

«Спартак» кубок яулап алгач, Алма-Атада гастрольдә булган Мәскәү Художество театры артистлары менә шушы котлау телеграммасын җибәргәннәр иде: «Спартак»ны котлыйбыз! Кубок белән тәбрик итәбез. Бигрәк тә Хөсәеновны котлыйбыз!

СССР халык артистлары: *М. Кедров, В. Станицын, М. Яншин, С. Блинников, А. Грибов».*

●

Галимҗан Хөсәенов — дөньяның бик күп илләрендә булган һәм һәркайда үз иленең спорт флагын югары йөрткән спортчы. Шуның өстенә гаҗәеп тыйнак та ул. Үзе турында сөйләтергә ничек кенә тырышсам да, Галимҗан күбрәк иптәшләре — Яшин, Воронин, Метревелиләр хакында сөйләде.

— Ләкин сезнең үз тәҗрибәгез дә аларныкыннан ким түгел бит! — дидем мин, аны бераз «кыздырып» җибәрмәкче булып. Әмма ул кыза торган кеше түгел икән шул.

— Мин бары тик башкалардан күбрәк тырышам гына, — диде Галимҗан, минем соравыма туры җавап бирүдән читләшеп.

Без бу ел үткәреләчәк дөнья беренчелеге турында да сөйләштек. Мин бары тик шуны гына әйтәм: безнең «Бәләкәч» анда ярымсакчы булып уйнады. Хәзер футболда универсал уенчыларны яратарак төшәләр. Тренерлар Галимҗанның 90 минут буена бөтен көчен куеп тырыша алуы, иң кыен моментларда да югалып калмавы, оста уен техникасы һәм акыллы тактик фикер йөртә белүе яхшы нәтиҗә бирер дип ышаналар.

Безнекеләр ничек кенә уйнамасын (ә алар начар уйнамаячак), мин бер нәрсәгә бик нык ышанам: безнең якташыбыз — Татарстанның Октябрь районы Яңа Игълай авылында туган Галимҗан Хөсәенов — үз иленең намусына тап төшермәячәк.

Хөсәенов кебек атаклы футболчы турында сөйләп тә, аның нәрсәләр белән мавыгуы хакында берничә сүз әйтми үтсәм — хикәям тулы булмас дип уйлыйм. Галимҗан музыканы, аеруча җиңел музыканы бик ярата. Музыка нервларны тынычландыра ди ул һәм музыка пластинкалары да җыя икән. Әгъзам Фәттах көйләрен аеруча нык ярата. Әдәбиятка килгәндә — тарихи әсәрләрне күбрәк укый. Бу ел Көньяк Америкага барганда үзе белән «Степан Разин»ны алып барган. «Бик шәп язылган. Көчле характер сурәтләнгән. Менә кем ихтыяр көченә ия булган! Аннан гыйбрәт ахырга була!» — ди Галимҗан.

Һәм Галимҗан Лондонда булачак очрашуларның, барыннан да элек, нервлар ярышы булачак икәнлеген әйтте. Кем психологик яктан яхшырак әзерләнгән булса, шул беренче урынны яулап алачак. Әлбәттә, яхшы физик әзерлек һәм оста уен техникасын да истән чыгарырга ярамый...

Менә илебезнең иң яхшы форварды, якташыбыз Галимҗан Хөсәенов турындагы очеркның ахырына да җиттек. Җиттекме икән? Ихтимал, СССР җыелма командасы өчен утыз тапкырлап уйнаган һәм алтмыштан артык туп керткән һөҗүмче Галимҗан Хөсәенов турындагы очеркның ахырыдыр бу. Ә менә 1966 елда дөнья беренчелегенә Лондонда катнашкан һөҗүмче Галимҗан Хөсәенов турындагы очерк башлана гына әле. Бөтен дөньяга танылган «Бәләкәч» турында без әле күп мәртәбәләр ишетербез дип ышанасы килә.

## СЕЗ ҮЗ ИСЕМЕГЕЗНЕҢ МӘГЪНӘСЕН БЕЛӘСЕЗМЕ?

Каюм — мәңгелек, нык, үзгәрми торган.
Камәр — ай.
Камәрия — ай хәрәкәтенә бәйләнешле.
Карим — якын.
Касыйм — бүлүче.
Кафия — рифма.
Кифая — җитәрлек, кирәк кадәр булу.
Котдус — бик изге, бик кадерле.
Корбан — берәр эш өчен фида булу.
Кыям — аягүрә басып тору.
Камил — тулы, бөтен.
Кашиф — ачучы, мәйданга чыгаручы, уйлап табучы.
Кәбир — олы, мөһим.
Кәмәр — билбау, эзәр.
Кәрим — юмарт, рәхимле.
Кәрәм — сорамастан бирү, киң күңеллелек күрсәтү.
Ләмига — нур чәчүче хатын-кыз.
Ләйлә — кичә, ялгыз бер кичә, төн.
Латыйфә — күңелле, көлкеле.
Малик — милек иясе, хуҗа.
Мәҗит — дан иясе.
Маһирә — оста, мастер.
Минһаҗ — тоткан юл, программа.
Мирза — яза белүче, секретарь.
Мисбах — шәмдәл, лампа.
Мифтах — ачкыч.
Могыйн — ярдәм итүче.
Мозаффар — җиңгән, теләгенә ирешкән.
Мохсинә — намуслы, гыйффәтле хатын.
Мохтар — ирекле, ихтыярлы.
Мәгъруф — билгеле, танылган.
Мәгъсүм — гөнаһсыз, керсез.
Мәлик — патша хөкемдар.
Мәннаф — өстен булу, өстенлек.
Мәрви — фәлән әйтте, дип сөйләнгән сүз.
Мәрдан — кешелекле егет, ир.

# ПУБЛИЦИСТИКА

*Фаяз Дунай*

# ЭКРАНДА КҮРСӘК ИКӘН...

Күптән түгел мин Мәскәүдән, кинематография институтында укучы бер танышымнан хат алдым. «Чын мәгънәсендә кинорежиссер була алырмынмы? — Киләчәк күрсәтер. Тиздән диплом алам. Казан киностудиясе ни хәлдә? Татар халкының кино сәнгатен үстерерлек мөмкинлекләр бармы?..» — дип язган, киңәш, тәкъдимнәр сораган ул.

Җавап хатымны язарга ашыкмадым. Уйланырга, иптәшләрнең дә фикерләрен белергә, реаль шартларны, мөмкинлекләрне өйрәнергә кирәк булды. Чөнки үз теләк, хыялларымны гына язсам, бу яшь иптәшне ышандырып житкерә алмам, мине Манилов хыялы белән мавыгуда гаепләр дип курыктым.

Әгәр бездән: «Тарих сәхифәсенә язып куяр өчен халкыгызның милли сыйфатларына кыскача гына аңлатма бирегезче?» — дип сорасалар, без, иң әүвәл, бөек Тукаебызны искә төшерер идек тә, аның үлемсез сүзләрен зур горурлык белән кабатлар идек: «Без сугышта юлбарыстан көчлебез, ә тынычта аттан артык эшлибез». Бу сүзләрнең дөреслеген раслау өчен дәлилләр эзләп торасы юк. Тарих аларны белә, тормыш аңа мондый дәлилләрне туктаусыз өстәп тора. Ватан ирешкән бик күп җиңүләрдә һәм казанышларда татар халкының үз өлеше бар. Бу тарихи дәлил белән шатланабыз, хаклы горурланабыз без. Безнең халыкның кайнар патриотизм һәм кешегә мәхәббәт белән сугарылган бай әдәбияты, сәнгате бар. Ә кино сәнгатебез?.. Тукта, ничек болай булган соң әле? «Могжизалы камера» егерменче еллар ахырында ук татар халкы тормышына «күз сала» башласа да, нигәдер сагынып телгә алырлык бер әсәр дә иҗат ителмәгән. Совет кино сәнгатенең үсешендә, әгәр Казанда пленкалар эшләп чыгаруны искә төшереп үз-үзебезне юатмасак, бүтән өлешебез юк икән ич безнең...

Рус һәм украин халыкларының бөек кино сәнгатен беләбез без. Бай совет фильмотекасы киштәләрендә хәзер белорусларның, Балтик буе республикалары халыкларының, молдаваннарның, грузиннарның, әрмәннәрнең, Урта Азия республикалары халыкларының үз телләрендә һәм үз кинозалларында гына түгел, бөтенсоюз экраннарында миллионнарча тамашачыларның йөрәкләрен әсир иткән документаль һәм художестволы-нәфис ленталары бар. Ә без исә, вакыт сынавын узып, хәтердә калган нәфис фильм хакында әйтмибез дә инде, үзендә кешелек дөньясының даһи уллары Ленин, Пушкин, Лев Толстой, Лобачевский Герцен, Бутлеров, Горький, Шаляпин, Тукай, Җәлил һәм

башкаларның үлемсез истәлекләрен саклаган Казаныбыз турында да әлегәчә, ичмаса, азмы-күпме сәнгатьчә эшләнгән публицистик киноочерк та төшерә алмаганбыз. Аяныч хәл, ачы хакыйкать бу. Кайберәүләр бу күнелсез хәлне республикабызда 1961 елга кадәр киностудия һәм кинобелгечләр булмау белән аңлаталар. Әлбәттә, бу ике мөһим шартны булдырмый торып, зур мәшәкатьләр һәм зур чыгымнар таләп итүче катлаулы кино сәнгатен тудыруы бик кыен. Ләкин бу сәбәпләр генә акланырга нигез була алмый әле.

Беренчедән, хәзер без, яшьләр дә, сокланып укыйбыз ич: татар совет әдәбиятының Бөек Ватан сугышына кадәр үк экранлаштыруы җинел һәм аңа лаеклы классик әсәрләре булган. Г. Ибраһимовның «Казакъ кызы»н, «Безнең көннәр»ен, «Тирән тамырлар»ын, «Алмачуар»ын, М. Әмирнен «Агыйдел»ен, Г. Гобәйнең «Маякчы кызы»н, К. Нәҗми, Ш. Камал, И. Гази, Ф. Хөсни хикәяләрен, К. Тинчуринның, Т. Гыйззәтнең, Н. Исәнбәтнең драма әсәрләрен хәтергә төшереп узыйк әле... Кинокамера «карап туя алмаслык» никадәр гүзәл сәхифәләр бар бу әсәрләрдә!

Ул чакта ук уннарча талантлы яшь язучыларыбызның, драматургларыбызның, режиссерларыбызның һәм журналистларыбызның кино сәнгате серләрен өйрәнергә атлыгып йөрүләрен дә укып-ишетеп беләбез без.

Икенчедән, татар совет театр сәнгатенең ул чакта ук инде рус һәм көнбатыш бөек драматургиясенең дә үлемсез образларын зур осталык белән гәүдәләндерә алган сәхнә йолдызлары шактый булган. Хәтта аларның кайберләре яшь совет кинематографиясенең беренче бишьеллыклар чорында экранга чыккан кайбер әсәрләрендә кыю гына «канат кагынып алырга» да өлгергәннәр.

Теге яки бу фильмны иҗат итү өчен кирәк булган булса, ул чакта ук инде без музыкаль һәм вокаль мөмкинлекләргә дә мохтаҗлык кичермәгәнбез. С. Сәйдәшев, С. Габәши, Ю. Виноградов, Л. Хәмиди, Ф. Яруллин һәм башка композиторларыбыз бүген дә күңелләрне тибрәндереп яңгырый торган әсәрләрен иҗат иткәннәр, уннарча җырчыларыбыз танылып өлгергән.

Өченчедән, Казанның үзендә яки якын-тирәдә киностудия булмаса да, Мәскәү студиясе, бигрәк тә Баку студиясе үзенең һәрвакыт ярдәм кулын сузарга әзер булуын әйтеп, әсәрләр сорап һәм башкаручыларны чакырып торган. Хәтта ул чакта ук инде хәзерге танылган язучы Г. Минский, мәрхүм режиссер К. Поздняков кебек кинобелгечләребез дә булган. Заманында җылы гына бәя бирелгән «Булат батыр» кебек берничә фильм да эшләгәннәр алар. Ләкин... шуның белән вәссәлам. Әйтә алмыйм мин: әнә шул чактан ук киносәнгатебезне үстерү эшенә нишләп чын-чынлап керешелмәгән дә, югарыда телгә алынган мөмкинлекләр нигә файдаланылмагандыр? Оешканлык җитмәгән, республикабыз культура-агарту учреждениеләренең, иҗат оешмаларының инициативасы, алдан күрүчәнлеге җитмәгән, күрәсең. Торабара инде шәхес культы еллары, Бөек Ватан сугышы һәм ил хуҗалыгын торгызу еллары кыенлыгы бу эшне тоткарлагандыр. Хәер, әлегәчә хәл ителмәгән бу мәсьәләнең тарихын актарып, сәбәпләрен эзләп маташуның файдасы да, хаҗәте дә юк инде хәзер. Күңел әрнегәнгә, бу өлкәдә культура эшлеклеләребезнең хезмәте «чыпчык тезеннән» генә булуын сызланып искә төшерәбез...

Хәзер исә барлык иҗат работникларыбызны уйландырырга тиешле бу җитди кимчелекләрне төзәтер чак җитте. Кемнеңдер читтән киңәш һәм күрсәтмә биргәнен көтеп ятмыйсы иде, бу эшкә үзебез башлап керешәсе иде. Илебез кино сәнгатенең үсешендә татар халкының лаек өлеше булырга тиеш, һичшиксез, булырга тиеш бит.

Сәнгатькә гашыйк яшьләрнең өлкән киңәшчесе, СССР халык артисты, мәрхүм Хәлил ага Әбҗәлилов бу хакта еш уйлана, берәр татар егетенең яки татар кызының кино

сәнгате уку йортына керүен әйтсәң, әй шатлана торган иде...

... Яхшы сыйфатлы пленкалар чыгаруы белән дан тоткан Казан химия заводын беләсездер. Шуның янында ук, уң кулда, тирә-ягын тополь, каен, нарат агачлары уратып алган шактый зур, матур бер йорт бар. Шушы таш йортка 3—4 ел элек яңа вывеска кадакланды — Казанда кинохроника студиясе эшли башлады. Барыбыз да шатландык без моңа. Сәнгатьнең мәңгелек иҗат чыганагы — реаль тормыштан репортаж булганы өчен генә дә никадәр хөрмәткә, мактауга лаек ич ул, документаль кино! Хәзер документаль кино сәнгатенең тарих сөйләгәннәргә шаһит булып ерак киләчәктә дә экраннарда яшәячәк үлемсез ленталары, Роман Кармен, «Рус могҗизасы» авторлары Аннели һәм Андре Торндайклар кебек атаклы художник режиссерлары, аларның гасырыбыз вакыйгаларын югары сәнгать фокусында нурландырып чагылдырган документаль әсәрләре бар.

Ә кайбер кинематографистлар, шул исәптән, безнең Казан студиясе егетләренең дә кайберләре, бу хакта онытып җибәрәләр, олы сәнгать, якты экран алдында җаваплылык сизмиләр, «могҗизалы камераның» кадерен белмиләр, тамашачының зәвыгын санга сукмыйча, аңа кайчак натураль «хәрәкәтле фоторәсем» тәкъдим итәләр. Залдан берәрсенең «экран тутырып койрыгын күрсәтмәсәләр, сыер сыер булмыймы әллә?» — дип сүгенгәнен көт тә тор. Зәвыксызлыкны, халтураны беркайчан оперативлык, актуальлек белән акларга ярамый. Безнең таләпчән тамашачы моны һич кабул итми. Казан киностудиясенең яшь коллективы үзенең беренче адымнарыннан ук шушы чирдән саклансa — үзе өчен дә, тамашачылар өчен дә куаныч булыр иде. Чөнки «күлмәгеңне яңадан сакла, ә намусыңны — яшьтән» — ди рус халкы. Һөнәреңнең, профессияңнең абруен да, мөгаен, шулай сакларга кирәктер.

Күрә белсә, кинематограф-документалист өчен тормышта гүзәллекнең чиге юк. Туган җиребез — Татарстанны гына күз алдына китерик. Кинематограф өчен никадәр «күтәрелмәгән чирәм» бездә, күпме илһам чишмәләре!..

Кинокамера белән «табигать ауларга» чыгам дисәң, — кайтып керәсең килмәс. Кавказ, Кырым якларына алыштыргысыз үз матурлыгы, үз яме бар туган җиребезнең. Ә иң гүзәле, теләсә кайсы сәнгатьнең мәңгелек төп объекты, табигатьнең иң бөек балалары — кешеләребез, республикабыз хезмәт иярәренең эшләре киноелъязмаларда мәңгеләштерелергә лаеклылар.

Язучылар, журналистлар, сәнгать эшлеклеләребез Татарстанда кино сәнгатен үстерү хакында сүз чыкканда тагын бер мәсьәләгә еш туктaлалар: бай традицияләре, куәтле иҗат коллективлары булган театрларыбызның уңышлы спектакльләрен, халык мәхәббәтен казанган атаклы сәхнә осталарыбызның, композиторларыбызның һәм художникларыбызның иҗат портретларын кинопленкада чагылдырып, бөтен ил тамашачыларына күрсәтсәсе, тарих өчен, киләчәк буыннар өчен дә саклап каласы иде. Хәзер исә Казан студиясендә бу теләкләрне тормышка ашырырлык мөмкинлекләр бар. Коридорлар иркен, бүлмәләр, цех, мастерскойлар күп биредә. Төшерү павильоны да, тамаша залы да кысан түгел. Мәскәүдән, кинематография комитетыннан килгән вәкилләрнең һәм студия житәкчеләренең әйтүләренә караганда, үзенең техник җиһазландырылган булуы белән Казан студиясе хәзер Россия Федерациясендәге иң куәтле студия санала икән.

Студия Идел, Кама буйларындагы берничә автономияле республикага хезмәт күрсәтә һәм аларның казанышларын матур гына чагылдырган тәүге иҗат уңышлары — журналлары һәм кыска метражлы берничә фильмы да бар инде аның.

Яшь режиссер Йолдыз Карамышның диплом эше — «Тормыш — җыр» исемле документаль фильмы илебез экраннарында бара һәм Бөтенсоюз конкурсында почетлы диплом белән бүләкләнде. Халкыбыз-

ның бөек улы Муса Җәлилнең каһарманлыгын гәүдәләндерүгә багышланган бу киноочерк чын-чыннан сәнгатьчә төшерелгән, югары зәвык һәм техник осталык белән монтажланган. Фильмда бераз моңлы, ләкин якты лиризм, я героик патетика, яки урыны-урыны белән драматизм белән сугарылган кадрлар шактый, һәм аларны сокланып, дулкынланып карыйсың. Бу фильм Йолдыз Карамышның сәләтле режиссер булачагына һәм киләчәктә үз мөмкинлекләренең кадерен белеп, даими иҗади эзләнү һәм тынгысыз хезмәт белән яшәсә, кино сәнгатебез үсешенә үз өлешен кертәчәгенә ышандыра.

Фильмда кылганлы Оренбург даласы пейзажын һәм Муса Җәлил тәгәрәп уйнап үскән Мостафа авылы күренешләрен, ат көтүче малайларның төнге учак тирәсендә төн уздыруларын сурәтләгән кадрлар аеруча күңелгә уелып кала. Матур поэтик детальләргә, тәэсирле нәфис рәсемнәргә бай булган кадрларны студиянең яшь операторы Анатолий Стремяков төшергән. «Заповедник сукмакларында», «Мари кошчысы хикәясе», «Эрьзя» исемле кыска метражлы фильмнарда да Анатолийның олы сәнгатькә омтылышын, матурлыкны аңлый һәм күрә белүен, техник яктан остара, камилләшә баруын раслаучы кадрлар шактый. Чын мәгънәсендә сәнгать кешесе булган берәр тәҗрибәле режиссер кулы астында эшләгәндә, дөрес юнәлеш, киңәш бирүче булганда, бу иптәшнең бик тиз үсеп китәчәге һәм чын художник-оператор булып җитлегәсе күренеп тора.

Студиянең «Иптәш Камай» исемле фильмында да отышлы детальләр, игътибарны җәлеп итәрлек күренешләр бар. Әйтик, Гыйлем Камайның Идел пристаньнарында грузчик булып йөргән еллары... Камайның үзе дә, күтәргән йөге дә экранда күренми. Тамашачы күз алдында бары тик авырлыктан сыгылып-сыгылып куючы басма һәм чабаталы берәүнең салмак авыр адымнары гына... Әмма бу күренеш тамашачыга йөк күтәргән тере Камайның үзен күрсәтүгә караганда көчлерәк тәэсир итә. Шәхес культының башбаштаклык елларын, аеруча, талантлы галим бер дә гаепсезгә кыерсытылган хәтәр 1937 елны сурәтләгән шартлы кинодетальләрдә дә иҗтимагый мәгънә һәм сәнгатьчә буяулар бар. Ләкин фильм, тулаем алганда, күпләрне канәгатьләндерми. Студия сотрудниклары белән очрашу кичәсендә бу фильмны карагач, язучы Мирсәй Әмир: «Фильм техник яктан яхшы төшерелгән, ә эчтәлеге — бик ярлы. Әсәр чын Камайны күз алдына китереп бастыра алмый»,— дип бик дөрес әйтте. Чыннан да, фильмда күбебезгә таныш галим, зур иҗат кешесе, тынгысыз җәмәгать эшлеклесе, дөньяга, кешеләргә гашыйк күнелле Гыйлем аганың образы бик тонык һәм схематик чагыла шул. Режиссер И. Ермолаев таләпчәнлек күрсәтмәгән, сценарий авторлары В. Владимиров һәм А. Шлепянов иптәшләр исә галимнең холкын-табигатен, зур эшчәнлеген, иҗат газапларын һәм сөенечләрен җентекләп өйрәнеп тормыйча ашыгып каләмгә тотынганнар булса кирәк. Белмим, Казанның үзендә профессор Камайны якыннан белүче ункарча язучы һәм журналист булганда, сценарий язуны Ленинград журналистларына тапшыру нигә кирәк булгандыр? Гомумән, студиянең җирле иҗат оешмалары белән якыннан аралашмыйча, сценарийларны ерактагы авторлардан яздыруын әйтеп үтәргә кирәк. Студиянең үзендә мондый авторларны «варяглар» дип атыйлар. Ул «варяглар»ның осталык, белем дәрәҗәләре нинчектер — әйтә алмыйм, ләкин шунсы хак: алар язган сценарий буенча төшерелгән фильмнарның берсе дә тамашачыны шатландырганы юк әле. Бик табигый хәл: җирле шартларны белмиләр, язасы материалны җентекләп өйрәнмиләр ич алар. Фильм герое буласы шәхеснең кыскача биографиясен, хезмәт күрсәткечләрен белеп кенә яхшы сценарий язып булмый шул. Студиянең шулай «варяглар» белән генә эш йөртүе, минемчә, яхшыга илтмәс, татар, чуваш, мордва һәм мари халыкларының кино сәнгатен тудыруны тоткарлар гына. Соң, уйлап

карыйк: безнең Татарстанда гына да йөзләрчә сәләтле язучы һәм журналист бар. Күрше республикаларда да аз түгел алар. Шулкадәр каләм батырлары арасында кадр серен өйрәнеп сценарий язарлык сәләтле кешеләр юкмыни? Әлбәттә, бар. Илебездә күп кенә танылган прозаикларның, драматургларның һәм журналистларның бер үк вакытта менә дигән киносценаристлар да булуы мәгълүм ич. Бу хакыйкатьне Казан киностудиясендә дә беләләр, әлбәттә. Ләкин әлегәчә студия җитәкчеләренең җирле язучылар, журналистлар арасында кызыксыну уятырлык, аларны сценарий жанры үзенчәлекләрен өйрәнергә рухландырырлык эшлекле чаралар күргәннәре юк. «Килмиләр, кызыксынмыйлар, студиянең юлын да белмиләр», — дип, әдипләрдән зарланудан уза алмыйлар. Дөрес, Г. Тукай исемендәге клубка килеп язучылар, журналистлар белән очрашу уздырдылар алар. Ләкин бу очрашу әлегә акланмаган вәгъдә бирүдән һәм каләм батырларын сценарий язарга өндәүдән уза алмады. Өндәү белән теге яки бу язучыга, журналистка мөрәҗәгать итеп, конкрет эшкә тотыну арасында зур ара ераклыгы ята ич әле. Әлбәттә, сценарий жанрын үстерү бурычын киностудия үзе генә хәл итә алмый. Бу эштә язучыларыбыз, журналистларыбыз үзләре дә инициатива һәм иҗади активлык күрсәтергә тиешләр. Бәлки, беренче коймаклар бераз көйгән дә булырлар. Нишлисең, сәнгатьтә, шул исәптән, сценарий сәнгатендә дә «күк кабагы ачылган могҗизалы сәгатьләр» юк, берәүгә иҗат уңышы белемсез һәм хезмәтсез килми, бер кич каләм тибрәтү белән генә осталыкка ирешеп булмый. Ләкин кино сәнгате үзенчәлекләрен өйрәнергә читенсенеп, әдәбиятыбызда сценарий жанрын үстерү мәсьәләләренә кул селтәргә, бу эшне язмыш хөкеменә яки «варяглар» ихтыярына калдырырга хакыбыз юк безнең. Белмәгәнне өйрәнеп була. Һәм ышанып әйтергә була: язучылар, журналистлар арасында бүгеннән, кинематография белән бергәләп, җиң сызганып эшкә тотынырга атлыгып торучы иптәшләр аз түгелдер. Сценарийлар әгәр татар телендә языла икән инде, аларны русчага тәрҗемә итүе хәзер безнең өчен проблема түгел ич, менә дигән тәрҗемәче кадрларыбыз бар безнең. Күрше республикаларда да шундый ук сөенечле хәл. Кыскасы, киносценарист булып үсәрлек һәм тамашачы дулкынланып карардай әсәрләр иҗат итәргә сәләтле каләм осталарыбыз бар безнең. Студиянең алар белән эшли белүе генә кирәк.

Фильм өчен кирәк булса, композиторларыбыз, җырчыларыбыз һәм художникларыбыз да кинематографистларга булышырга дәртләнеп, илһамланып хезмәт күрсәтергә әзер торалар. «Тормыш — җыр» фильмының музыкаль оформлениесе хакында шатланып хәбәр итәсе килә. Минемчә, композитор Әнвәр Бакиров әсәрнең музыкаль яңгырашын чын-чыннан сәнгатьчә итү өчен шактый эзләнгән, фильмда сурәтләнгән күренешләрнең, вакыйгаларның эстетик тәэсирен көчәйтергә вокаль һәм музыкаль фрагментлар тапкан. Бу матур башлангыч дәвам итсен, нурлы экран башка композиторларыбызны да иҗатка рухландырсын иде.

Нәфис фильмнарны татар һәм башка милли телләргә тәрҗемә итүдә исә студиянең шактый тәҗрибәсе һәм уңышлары бар инде. Совет кинематографиясенең күпчелек күренекле әсәрләре татарчага тәрҗемә ителгән хәзер. Бу эштә Татар дәүләт академия театрының танылган артистлары, режиссерлары бик актив катнашалар, дубляжның өстәмә акча эшләп алу чыганагы гына түгел, башкару культурасы һәм эрудиция таләп итүче иҗат эше булуын дөрес аңлыйлар. Бу иҗади эш киләчәктә дә шулай уңышлы дәвам итсен иде. «Эшләгәнен кеше өчен булса, өйрәнгәнең үзең өчен» дигәндәй, драма сәхнәсе осталарының «могҗизалы камера» үзенчәлекләрен өйрәнә торулары үзе сөенечле хәл ул. Социалистик реализм сәнгате таләпләрен, көнбатыш культурасының прогрессив әсәрләрен, бөек рус культурасының һәм үз милли

культурабызның казанышларын яхшы белүче, театр сәнгатенең зур реформаторы К. С. Станиславский системасы рухында тәрбияләнгән бу иптәшләр, бәлки, киләчәктә, Казан студиясе нәфис фильмнар чыгара башлагач, менә дигән киноактерлар булып танылырлар.

Студия сотрудниклары кай ара үзләрендә җаны-тәне белән сәнгатькә бирелгән, аны тирән аңлаучы һәм туктаусыз эзләнүче, сәләтле режиссерларның бик аз булуыннан, гомумән, фильмнар эшләүдә әлегә режиссура житәкчелегенең бик йомшак булуыннан зарланалар. Нишлисең, студия яшьрәк шул әле һәм анда очраклы кешеләр дә бардыр. Ләкин эксперимент, сынаулардан курыкмый, тырышып эзләгәндә режиссура кытлыгыннан котылырга мөмкинлекләребез дә бар. Илебезнең күп кенә студияләрендә татар, башкорт, чуваш, мордва һәм мари милләтләреннән булган шактый кинобелгечләр эшли. Әгәр Казан студиясе хөрмәт белән һәм тактикалы итеп, иҗади эш алып барырдай шартлар булдырып, аларны үзебезгә чакырса — кайтмаслар идемени! Минемчә, күбесе шатланып кайтачак.

Икенчедән, Казан театрларында Празат Исәнбәт, Марсель Сәлимжанов, Рифкать Бикчәнтәев кебек талантлы, тирән теоретик әзерлекле, тынгысыз яшь режиссерларның эшләгәнен беләбез һәм алар куйган спектакльләрне дулкынланып карыйбыз без. Ә нигә бу иптәшләрнең берәрсен кино төшерү өлкәсендә дә сынап карамаска! «Алар бит кинобелгечләр түгел, дипломнары юк», диярләрме? Дипломың бармы синең, юкмы, анда «документаль кино режиссеры» яки «драма режиссеры» дип язылганмы — эш анда түгел, талант кирәк, белем, хезмәт кирәк сәнгатьтә... Кино төшерүнең кайбер техник якларын, камера капризларын белмиләр икән — зур кыенлыкмыни, өйрәнерләр. Шәт, берәрсе Мәскәүгә барып, Югары режиссерлар курсында укып кайтырга да вакытын кызганмас. Студиянең киләчәккә карап яшн белүе, кешеләр белән эшли белүе генә кирәк.

Югарыда телгә алынган мөмкинлекләрнең барысын да мин бер мөһим проблеманы хәл итәр өчен — Казан студиясендә нәфис фильмнар эшләр өчен шартлар булганын исбат итәр өчен күрсәтеп, санап уздым. Чөнки бу мәсьәлә белән меңнәрчә иптәшләр кызыксына, күбебез хыяллана. «Барлык Идел буе халыкларының кино сәнгатен үстерәсе иде, ленинчыл милли политиканың тантанасын тулы метражлы, киң форматлы, художестволы кадрларда чагылдырасы иде» — дибез. Бу мәсьәләне хәл итәр вакыт җитте инде. Ләкин «югары оешмалар кайгыртсын, бу — алар эше» дип, «алма пеш., авызга төш» дип утырмаска иде. Барлык иҗат работникларына, язучыларга, журналистларга, театр эшлеклеләренә, музыка, җыр, бию, рәсем сәнгате вәкилләренә кулга-кул тотынырга да уртак тырышлык белән яшь студиянең «зур дингезгә» чыгарга сәләтле булуын хәзердән исбат итә барырга кирәк.

Туган илебез Октябрьның илле еллыгын каршыларга әзерләнә. Бу бәйрәмдә татар совет халкының да шатлыгы зур, табыны мул булыр. Тик бу табында культурабызның яшь алмагачы — киносәнгатебезнең дә алмалары булсын иде. Һәм аз булсалар да хуш исле, матур, сусыл һәм татлы булсыннар иде алар...

50 Бөек Октябрьның еллыгына

*Локман Аитов*

# АРТИСТНЫҢ ТОРМЫШ ЮЛЫ[1]

1917 елның август ае ахырларында, «Нур» труппасы Ижевск һәм Пермь шәһәрләрендә җәйге гастрольдә булып, кабат Уфага кайтты да кышкы сезонга әзерләнә башлады. Шушы көннәрдә җырчы Фәттах Латыйпов белән аның иптәше Сатирә ханым Әхмәдиева Уфага килде. Концертлары, «Новый клуб»та булып, бик күңелле үтте. Алар да безнең труппада кышкы сезонга калырга булдылар. Шулай ук Казаннан, «Сәйяр» труппасыннан, Зәки Баязитский да Уфага килде. Ул карчыклар ролендә уйнаучы осталарның берсе иде. Аны да труппага алдык. Шул көннәрдә Мәхмүт Нуриманов та («Чын мәхәббәт» пьесасының авторы) труппага кереп эшләү теләген белдерде, аны да алдык. Труппабызда көчләр артты. Бик ныклап әзерләнеп, сентябрь ахырында «Саран» комедиясе белән кышкы сезонны ачып җибәрдек. Спектакль ярыйсы чыкты. Чираттагы икенче спектаклебез — «Чын мәхәббәт» әсәре булды. Баш рольне — Гомәр образын автор үзе башкарды.

Шулай, атнасына ике спектакль куя килеп, Октябрь революциясен каршы алдык. Бу революция безне моңарчы хыялларыбызда гына булган яңа иркен тормышка алып чыкты.

Шул көннәрдә Мәхмүт Нуриманов: «Иптәшләр, миндә тагын бер кульъязма әсәр бар. Күптән түгел генә язып бетергән идем. Укып карыйк та, ярарлык булса, куярбыз», — диде. Укып чыктык, куярга тиешле табып, әзерли башладык. Бу әсәр — патша хөкүмәтенең вак милләтләрне җәберләве турында язылган «Керәшен» исемле дүрт пәрдәлек драма иде.

Көзге суык көннәрнең берендә репетиция ясап ята идек, клубка 19—20 яшьләрендәге, аягына брезент башмак, өстенә кыска пиджак, башына җәйге кепка кигән, кечкенә генә буйлы бер егет килеп керде. Үзен Сөләйманов дип таныштырды.

— Мин бер тәкъдим белән килгән идем. Минем язган бер-ике театр китабым бар. Шуларны укып карасагыз иде, — диде ул.

— Вакытың булса, бераз көтеп утыр, менә тиздән репетиция бетә. Шуннан иптәшләр белән бергә сөйләшеп карарбыз, — дигәч, егет көлемсерәде дә:

— Көтәм, көтәм, минем вакыт күп,— дип тыйнак кына елмайды. Мин бу тыйнак егет белән кызыксынып киттем.

— Кайда эшлисең? — дип сорадым.

— Җир белән күк арасында, — диде ул, көлеп.

Репетиция беткәч, бу егетнең «Каторжан» исемле 4 пәрдәлек әсәрен укыдык. Көчле генә драма әсәре иде, яраттык. Тормыштан сөрелгән, базда, баткаклыкта ятучылар тормышыннан алынып язылган әсәр иде. «Бу әсәрне каян алып яздың?» дигән сорауга ул: «Үзем шул тормыш эчендә яшәдем, минем атам да, анам да юк. Мин аларны белмим дә. Менә Октябрь революциясе килеп чыккач, берәр төрле хезмәткә

---

[1] Ахыры. Башы журналыбызның 6, 7 саннарында.

кереп эшләп булмасмы икән дип, Уфага килдем», дип җавап кайтарды. «Әйдә, безнең труппага керәсеңме?» дидек үзенә. «Мин сездә нишләрмен, артист булып уйнарга булдыра алмам»,— диде. «Менә укуың бик әйбәт (чөнки әсәрен үзе укып чыкты), бездә суфлер булып эшләрсең. Буш вакытларыңда тагын театр әсәрләре язарсың», дигәч, егет куанып китте, «Алсагыз, мин бик риза»,— дип куйды. Шул көннән бу егет бездә суфлер булып эшли башлады. Кыш буена тагы «Газизә» исемле драма һәм «Театр чыпчыклары» дигән бер пәрдәлек комедия язды. Бу әсәрләрнең һәркайсын куйдык. Уңышлы гына үттеләр. Бу егетне Мәҗит абзый белән дә таныштырдык. Ул да аның әсәрләрен ятатты һәм язу эшендә күп кенә киңәшләр биреп, ярдәмен күрсәтте. Хәзер бездә репертуар кытлыгы бетте. Атна саен диярлек, яңа әсәрләр куя башладык. Бер яктан Мәхмүт Нуриманов, икенче яктан Сәләйманов яза, мин дә рус әсәрләренең кайсын тәрҗемә итеп, кайсына кәләпүш кидереп, татарчалаштырып куйгалыйм.



Ш. Шамилский 1917 ел.

Декабрь аенда фронттан Шакир Шамилский кайтты. Аны барыбыз да куанышып, кочак җәеп каршы алдык. Труппабыз тагын да көчәйде. Чөнки Шамилский «Нур» труппасының иң зур, көчле, талантлы артистларыннан берсе һәм халык та аны бик ярата иде. Ул кайтып керү белән, аның яраткан «Хөкемдә хаталык» әсәрен әзерләдек тә, Жан Рено ролен Шакир Шамилский уйный дип, афишаларга язып чыгардык. Бу спектакль аеруча зур күтәренкелек белән үтте. Һәр пәрдә саен «Шамилский, Шамилский!» дип кабат-кабат чакырып чыгардылар. Зал халык белән шыгрым тулган иде. Хәтта өстәмә урыннар да сатарга туры килде. Икенче көнне, спектакльнең отчетына җыелгач, иптәшләр белән киңәш иттек тә бу спектакльнең расходыннан артып калган акчаның яртысын Шакир Шамилскийга бирергә булдык. Чөнки Шакир фронттан гына кайткан кеше, аның өстендә искергән солдат шинеле, башында вязанка папаха, аягында обмотка белән иске ботинка гына иде. Аны баштанаяк киендерергә теләдек һәм, шул ук көнне үзе белән магазиннарга чыгып, киендердек. Шинельне, папаханы, ботинкаларны салып ташлап, яңа туи, бүрек, штиблетлар киеп, көзгегә карагач, Шакир: «Мин, иптәшләр, артисттан битәррәк, купецка охшап киттем бугай!» — дип көлеп җибәрде.

Беренче мартта Мәскәүдәге Корш театрыннан[1] килгән артистлар җитәкчелегендә ике еллык драма курслары ачылды. Мин үзем икенче курска укырга кердем. Татар артистларының бу көнгә кадәр укымыйча, бары тик табигый талантка гына таянып уйнап килгәннәрен искә алып һәм киләчәктә татар театрына кадрлар әзерләү нияте белән, шул курста татарлар өчен махсус бер бүлек оештырылды. Ул бүлекнең мөдире итеп мине сайлап куйдылар. Егетләрдән ун кеше язылса да, кызлардан берәү дә булмады.

Укуларны дәвам иттерү белән бергә, җиңелрәк әсәрләр сайлап, курста укучылар катнашында, балалар өчен тәҗрибә спектакльләре куйдык. Берсендә «Вәли революционер» исемле ике пәрдәлек һәм «Шәкерт имтиханга әзерләнә» исемле бер пәрдәлек комедия, икенчесендә «Мескен Фатих» исемле ике пәрдәлек һәм «Буржуйлар» исемле бер пәрдәлек комедияләр куелды. Бу әсәрләр минем тарафтан язылган пьесалар иде. «Мескен Фатих» белән «Вәли революционер»ның сюжеты русчадан алынды, тегеләрен үзем язган идем. Вакытына күрә бу пьесалар кирәкле иделәр.

[1] Хәзерге МХАТ.



М. Гафури. 1916 ел.

Мин үзем курста Островскийның «Гаепсездән гаеплеләр» пьесасындагы Шмага, «Урман» әсәрендәге Аркаша рольләреннән зачетлар әзерләп бирдем. Шулай ук Уфадагы рус труппасында «На дне» (М. Горький) спектаклендә Татарин ролендә өч мәртәбә русча уйнадым. Май аеның башларына кадәр, шушы рәвештә, уңышлы гына эшләп килдек.

Бу сезонда һәркайсыбыз, гадәттәгечә, артистларның елына бер килә торган бәйрәме булган бенефисларын үткәрдек. Шул җөмләдән январь аенда минем дә бенефисым булып үтте. Һәм шунда башка бүләкләр белән бергә типография эшчеләре исеменнән Мәҗит ага Гафури тарафыннан миңа багышлап махсус язылган адрес бүләк иттеләр. (Бу вакытта Мәҗит ага Гафури типографиядә өлкән корректор булып эшли иде.) Бу — бүләкләрнең иң зурысы булды...

Май аенда шәһәрдә тынычсызлыклар көчәя башлады. Шунлыктан, халык театрга йөрмәс булды: кичләрен урамга чыгарга курка башладылар. Бер-ике спектакль куеп карасак та, килер шәп булмады. Спектакльләрне туктатып, сезонны ябарга булдык. Гастрольләргә чыгып китәргә юллар өзелгән иде. Яшь Совет дәүләтенә бер яктан ак чехлар, икенче яктан Колчак, өченче яктан Краснов, Дутов, бандалары һөҗүм итә башладылар. Шуңа күрә, дөньялар тынычланганга кадәр дип, труппаның эшен туктатырга туры килде. Һәркемгә үзе теләгән җиренә китеп торырга рөхсәт ителде.

Шулай итеп, 1912 елның маенда Уфада оешкан «Нур» труппасы 1918 елның маенда шул ук Уфада, үзенә алты яшь тулганда, вакытлы рәвештә эшен туктатып торырга мәҗбүр булды...

## Давыллы көннәрдә

Уфа шәһәренә чехлар якынлаша башлады. Чеверев отрядларының бер часте Уфада калган иң актыккы пароход белән Сарапулга китәргә тиеш иде. Бу кечкенә генә пароходка корал төяп баржа тактылар. Сәхипҗамал Волжская белән мин шушы пароходка эләктек. Сарапулдан Әгерҗегә киттек. Бу вакытта Әгерҗедә тормышлар әллә ничек кенә иде. Кызыллар иде дисәм, — сәүдәгәрләр дә байлар сату итеп яталар; аклар дисәм, — бүрекләренә кызыл лента таккан, мылтык тоткан продотряд солдатлары икмәк җыеп йөриләр. Халык арасында төрле сүзләр таралган. Иж заводы аклар кулында. Әгерҗедәге кулаклар: «Аклар безнең барып чакырганны көтәләр икән, җәмәгать, хәзрәтләрне җибәреп чакыртыйк», — дип сөйләшәләр. «Сюгинск станциясеннән кызыллар килә икән», дигән хәбәрләр дә йөри иде.

Әгерҗедә бер-ике көн тордык та Буби авылына бардык, анда Иж суы буендагы ике кымызханәнең берсенә тукталдык. Июнь башыннан август ахырына кадәр кымызда торып, аннан соң Бубида бер йортка квартирага урнаштык. Бу вакытта Бубида укытучылар курсы бар иде. Курста укучы мөгаллим, мөгаллимәләрнең соравы буенча һәм аларның катнашы белән, Буби мәдрәсәсе бинасында ике спектакль куйдык. Бу вакытларда инде Сарапул, Ижевск, Алабуга аклар кулында булып, Әгерҗе һәм Сюгинск станцияләрендә генә кызыллар иде.

Әгерҗедәге кызыл гаскәрләр өчен дә «Чын мәхәббәт», «Әдәпсезләр арасында хиҗапсыз кыз», «Денщик Гали» спектакльләрен куйдык. Әгерҗе бөҗра эчендә калды, өч яктан кыса башладылар. Бу вакытларда инде Уфада — чехлар, Самарада — чехлар, шулай ук Казанга да чехлар кергән иде. Шул көннәрдә Мулланур Вахитовның,

акклар кулына эләгеп, корбан булуы хәбәрен ишеттек. Бу шомлы хәбәр барыбызны да тетрәтте. Зур революционерны югалту халкыбыз өчен тирән кайгы иде.

Бер-ике көн үткәч, мин Әгерҗедән Бубидагы квартирама кайтып яттым. Иртән сәгать биш-алтылар тирәсендә урамда шау-шу башланды. Караваттан торып, тәрәзәдән карасам, урамда ак солдатлар, өй саен кереп, эзләнеп йөриләр. Күрше йорттан ике кызылармеецны алып чыктылар, берсе яралы иде — кача башлагач, аягына атканнар. Шуннан соң болар безгә дә килеп керделәр. Җиде-сигез солдат, араларында татарлар да бар. Бу вакытта инде Сәхипҗамал да урыныннан торып чыкты.

— Аитов дигән артист син буласыңмы? — дип сорады берсе.

— Әйе, мин булам, — дидем.

— Ә бу кем?

— Артистка Гыйззатуллина-Волжская, — дип җавап бирдем.

— Монда нишләп ятасыз?

— Ялга, кымыз эчәргә килгән идек.

— Синдә наган бар икән дип ишеттек! — диде берсе. — Давай ул наганны бир дә, үзең хәзер үк киен, комендатурага алып китәбез.

— Миндә бер нинди дә корал юк, мин артист кеше, минем бөтен әйберләрем әнә шул кәрзинкәдә, — дип әйберләремне күрсәттем. Шуннан соң болар кәрзинемне актара башладылар. Шунда китаплар, гримнәр арасында сәхнә өчен эшләнгән, эчендә агач наган тыккан клеенка кобура килеп чыкты. Шуны күрү белән болар:

— Әһә, таптык бит, менә бит наганың, нигә алдыйсың? — дип кычкырдылар.

Эченнән агач мылтык килеп чыккач, тагын бәйләнделәр болар:

— Кая яшердең? Наганың булмагач, бу кобураны нигә саклыйсың?

— Мин сезгә әйттем бит инде, мин артист, ә бу безнең сәхнәгә тагып чыгарга кирәк була.

Шуннан соң Волжскаяның да кәрзинен актардылар. Аннан париклар килеп чыкты. Тагын бәйләнергә керештеләр:

— Бу чәчләрне нигә асрыйсыз? Шпион булып, төрле кыяфәттә йөрер өченме? — дип җикеренделәр.

— Алар да шулай ук сәхнә өчен, — дип җавап бирдек.

Солдатлар мине урамга алып чыктылар. Анда нәкъ мәхшәр көне иде, аклар мәш килә, халык җыелган. Өч кызылармеецны тотып алып килгәннәр. Озак та үтмәде, ат килде. Сәхипҗамал да киенеп чыкты:

— Мин сезнең үзегезне генә җибәрмим, мин дә сезнең белән барам, — дип, арбага менеп утырды. Кузгалып киттек. Юл бик пычрак иде. Ак солдатлар барысы да атка атланган, тегe өч кызылармеец алдан җәяү бара. Аягы атылганы аксый-аксый көчкә генә атлый. Шуннан соң без, аны кызганып, арба кырыннан бара торган аклар солдатына:

— Атлый алмый бит ул, арбага утырсын, — дип әйтеп бетерергә өлгермәдек, тегe акырып җибәрде:

— Үзегез утырган җитмәгән, тагын пленныйларны да утыртмакчы буласыз! Тик кенә бармасагыз, үзегезне дә өстерәп төшерербез!

Яралы солдат бераз баргач туктады. Шуннан алдан бара торган ак солдат:

— Качканда бик каты йөгерә идең бит, сволочь, — диде дә атып җибәрде. Тегe бичара егылды.

Мондый вөҗдансыз рәвештә кеше үтерүне гомеремдә беренче мәртәбә күрүем иде...

Әгерҗегә барып җиткәч, ике кызылармеецны һәм мине акларның комендатурасына алып керделәр. Комендант бик зур сакаллы, юан корсаклы бер кеше — Ижевскиның Сапожников дигән кулагы иде. Аның ярдәмчесе булып Муллаҗан Садыйков дигән татар егете утыра иде. (Монысы миңа туган тиешле кеше, үзен биш-алты ел күргәнем юк иде.) Башта ике кызылармеецны чакырып сорау алдылар да миңа тотындылар. Комендант беренче сүзен үк:

— Коммунистмы? — дигән сорау белән башлады.

— Мин артист, — дидем.

— Артист булгач, авылда нишләп ятасыз?

— Ял итәргә, кымыз эчәргә килгән идек. Әнә сезнең белән янәшә утырган кеше мине белә, — дидем. Муллажаннан:

— Нигә бер сүз дә әйтмисең? Мине монда ни өчен алып килделәр? — дип сорадым. Ул:

— Кызыллар барында спектакльләр куеп, митинглар ясап йөргәнсен, диләр. Значит, гаебең бардыр. Бездә гаепсез кешене алмыйлар,— диде дә алдында яткан кәгазьләргә иелде.

Безнең сөйләшүләрне тыңлаган комендант Муллажаннан:

— Танышыгызмыни? — дип сораган иде, ул:

— Юк, таныш түгел, кайдадыр очрашкан идек бугай,— диде һәм икенче бүлмәгә чыгып китте.

Комендант мине контрразведкага илтергә кушты. Шуннан мине коридорга чыгардылар. Коридорда көтеп утырган Сәхипҗамалга: «Мине контрразведкага җибәрәләр, анда бару юньлегә булмас. Сез, зинһар, таныш-белешне күреп, хәлне аңлатыгыз. Алар мине ничек тә коткарырга тырышсыннар», — дип саубуллашкач, янымдагы солдатлар белән контрразведкага киттек.

Кечкенә генә бүлмә, түрдә язу өстәле, бер кеше язып утыра. Погоннар таккан, юнкер формасыннан. Ул башын күтәреп миңа карагач, солдатларга: «Хәзергә бу кешене коридорга чыгарып торыгыз, начальник үзе кайткач чакырыр», — диде.

Элегрәк кулга алынган кешеләрне контрразведка ишек алдындагы амбарга, мунчага тутырганнар. Безне, соңрак кулга алынганнарны, ябарлык бүтән урын булмагач, канцелярия алдындагы коридорда тоттылар.

Баскыч буенда биш-алты солдат мылтык белән каравыл тора иде. Бераз вакыттан соң, начальник кайтты. Утыз яшьләр чамасындагы кеше икән. Бүлмәсенә кергәч, берәм-берәм чакырып, сорау ала башлады.

Миңа да чират җитеп, сорау ала башлаган гына иде, курчак төсле бизәнгән хатыны килеп керде дә:

— Я, тиз буласыңмы инде, аш әзер, — диде.

Офицер миннән сорау алуын дәвам итте. Хатыны мин сөйләгән сүзләрне тыңлап торды. Сорау беткәч, мине тагын коридорга чыгардылар. Сәгать кичке бишләр чамасы иде. Тагын өч-дүрт кешене алып килделәр. Офицер ашагач, каядыр чыгып китте. Бераздан хатыны чыкты да, минем каршыма килеп, сораштыра башлады:

— Сез артистмыни, кайда уйнадыгыз? Кай шәһәрләрдә булдыгыз? Рус артистларыннан кемнәрне беләсез?

Мин белгәннәремне әйттем. Шуннан соң бу:

— Мин дә артистка бит, шуңа күрә мин театр халкын яратам, туганнарны күргәндәй булып китәм, — дип куйды. Мәскәү артистларын белү-белмәвем турында сорагач, мин Уфага Корш театрыннан килгән атаклы ике кешенең — Ольга Дмитриевна Виндинг белән Аркадий Васильевич Шотоцкийларның фамилияләрен атадым. Артистка уңайсызланып китте:

— Мин бит алардан укыган идем, — диде. Шуннан соң, бераз вакыт уйга калып торды да, борылып бүлмәсенә кереп китте.

Кичке уннар тирәсендә начальник кайтты. Тагын чакыртып сорау ала башлады. Бераздан хатыны аны кичке ашка чакырды. Аннары коридорга чыкты да миннән:

— Сезгә бүген ашарга китерүче булдымы? — дип сорады.

— Юк, — дидем мин. — Кем миңа ашарга китерсен...

— Туктагыз, алайса, мин сезгә ашарга бирермен, — дип, бүлмәсенә кереп китте. Бер биш минуттан кире чыкты һәм:

— Әйдәгез әле, сезне ирем чакыра, — диде дә мине үзләренә алып керде. Офицер кызмача иде. Өстәлдә пар бөркеп пилмән һәм аракы тора. Миңа өстәл янына урын тәкъдим иттеләр. Салган пилмәннәрен ашадым. Офицер шактый мәлҗегән иде, караватка барып ятты. Мин дә: «Ашыгыз өчен рәхмәт», — дип урынымнан кузгалдым. Хатын: «Сезнең бу авылда барып йокларга белгән кешегез бармы?» дип сорады, мин: «Аның өчен генә кеше табылыр», дип җавап биргәч, иренә мөрәҗәгать итеп: «Син бу кешене иртә беләнгә кадәр җибәр. Бераз йоклап килсен, җитмәсә үзе авыру да тагын», — диде. Ире миңа төбәп карады да: «Әгәр дә мин сине иртәгә алтыга кадәр җибәрсәм, килерсеңме, качмассыңмы? — дип сорады. «Нигә качыйм, кая качыйм,

күрәсез бит, минем аягым да шешкән, аннан соң минем паспорт та сездә бит!» — дидем. Шуннан ул миннән подписка алып, кечкенә генә пропуск сыман нәрсә язып бирде, һәм үзе янадан караватына барып ятты. Мин, часовойларга шул кәгазьне күрсәтеп, капкадан чыктым да, алдыма-артыма карамыйча, тауга таба йөгердем.

Тау башында әнием белән бертуган Хәнифә исемле апам тора иде, туп-туры шуларның өенә барып кердем һәм башымнан узганнарны сөйләдем дә өй базына төшеп йокладым. Иртә белән сәгать бишләр чамасында торып, бераз ашарга алып, чикләвек урманына киттем. Анда көн буе йөреп, караңгы төшкәндә генә кайттым. Сорап килүче булмаганын белгәч, тагын базга төшеп йокладым.

Шушы рәвештә ике көн үтте, өченче көнне иртән Сюгинск ягыннан туптан ата башладылар. Күрше-тирә бар да торып урамга чыкты. Безнең күрше егет (ул тимер юлда эшли иде) станциядән кайтты да:

— Вокзалда мәхшәр, аклар вагоннарга төяләләр. Качалар бугай. — дип әчкә шатлык кертте.

Атышлар бер-ике сәгать барганнан соң, безнең очтан атлы кызылармеецлар килеп керде.

Әгерженең үзендә атыш-фәлән булмады. Чөнки аклар инде бөтенләй качып беткәннәр, һәм китәр алдыннан кулга алынучыларның барысын да үтереп киткәннәр иде.

Шулай итеп моннан берничә көн элек Әгержене калдырып киткән кызыллар отряды, Сюгинскидагы Азин дивизиясенә кушылып, аның командасында янадан Әгерҗегә кайтып керделәр.

Берничә көннән соң, гражданнар сугышының легендар герое Азин үзе дә Әгерҗегә килде. Әле Сарапулда да, Ижевскида да аклар иде. Һөҗүм Сарапулга таба юнәлтелде. Бу көннәрдә Сәхипҗамал Волжская да Бубидан Әгерҗегә, минем апаларга кайтты.

Азинның кыр штабы вокзалда урнашкан иде. Вокзалны һәм штаб вагоннарын чистартырга, юарга дип, авылдан хатын-кызларны чакырып йөри башладылар. Шуннан Хәнифә апам чүпрәк, себерке, чиләк тотып чыгып барганда, көлеп кенә Волжскаяга: «Әйдә, Сәхипҗамал кызым, барасыңмы минем белән?» — дип әйтүенә Волжская: «Ник бармаска, барам, кая, тагын чиләгең бармы?» — диде дә, кулына чиләк алып, җиде-сигез хатын белән бергә вокзалга вагоннар юарга китте.

Әгерҗе драма түгәрәге егетләре дә минем янга килеп йөриләр иде. Тиз генә сөйләшеп алдык та, армиябезгә ярдәм итәр өчен, барыбыз да җыелып вокзалга төштек. Өч вагон таккан бер «кукушка» тора иде. Безне һәм эшчеләрне шул вагоннарга утырттылар. Без ун кешелек бер бригада булып оештык. Төн караңгы иде. Кузгалып киттек. Юлда барганда шырпы яндырырга да кушмадылар. Бер сәгать чамасы баргач, поезд туктады. Поездан төшерделәр дә туздырып ташланган шпалларны җыйнарга куштылар. Яктыра башлау белән, агач күперләр салырга керештек. Шулай эшли-эшли Сарапулга барып җиттек. Сарапул кызыллар кулында иде инде. Аклар Каманың аргы ягындагы зур бер авылга качканнар. Кама аркылы чыга торган тимер юл күперенең бер пролетын шартлатканнар. Шул сәбәпле, безнең гаскәр, Каманың аргы ягына чыга алмыйча, Сарапулдан Кама аркылы аклар ягына артиллериядән снарядлар яудыра иде. Безнең кирәгебез калмады, Әгерҗегә кайтарып җибәрделәр.

Азин дивизиясе Әгерҗедә бер ай чамасы торды. Шул вакыт эчендә без, Әгерҗе яшьләре катнашы белән, кызыл гаскәрләр өчен спектакльләр һәм концертлар куйдык. Азин дивизиясендә татарлар да бик күп иде. Безнең спектакльләрне бик яратып карадылар. Азин иптәш үзе дә безнең бу эшебезне бик ятратты. Ул шулкадәрле гади кеше, безне сугышчылары кебек якын күрә, очрашкан вакытларда:

— Давай, давай, артист иптәшләр, безнең гаскәрләрнең күңелләрен күтәрегез, Ижевскины тизрәк алырга кирәк! — ди торган иде.

Бөек Октябрьның бер еллыгы көненә Ижевскины алырга дигән приказ булды. Шул уңай белән Казаннан ярдәмгә татар батальоны да килде. Бик каты һөҗүм сугышлары башланды. Нәкъ 25 октябрь көнне (яңача 7 ноябрь) иртә белән иптәш Азин җитәкчелегендәге кызыл гаскәр Ижевскига бәреп кереп, приказны үтәде. Икенче көнне штаб вагоннары да Ижевскига китәргә тиеш иде. Волжская белән без дә шунда киттек. Шәһәр урамнары тып-тын иде. Тау башындагы йортларның күбесе бөтенләй буш калган. Сәүдәгәрләр, кулаклар йортларын ташлап качканнар. Аклар,

китэр алдыннан, завод ишек алдында тоткын коммунистларны, эшчеләрнең барысын атып үтергәннәр. Мәетләрне утын өйгән кебек аркылы-торкылы салып, өемнәр ясаганнар.

Дүрт-биш көн үткәч, шәһәр рәткә салынды, учреждениеләр эшли башлады. Металлистлар клубында рус артистлары спектакль, концертлар куя башладылар. Без дә, Ижевск яшьләрен җыеп, кызыл гаскәрләр һәм эшчеләр өчен бушлай ике спектакль күрсәттек. Беренчесендә «Чын мәхәббәт» драмасын, икенчесендә «Өрәкләр» комедиясен куйдык.

Ревком янында пролеткульт бүлеге төзелде һәм рус артистлары шуның карамагына күчеп эшли башладылар. Бу бүлекнең начальнигы Бажутин безнең спектакльне дә карарга килгән иде. Безне ревкомга чакырып китте. Ревком каршында татар труппасы да төзергә карар иттеләр. Шуннан соң, икенче көнне үк, бу труппага керергә теләүчеләрнең исемлеген төзеп ревкомга тапшырдык. Ревком председателе Шапошников шул исемлеккә кешеләрне приказ аша үткәреп, сметалар төзеп, «Советский Мусульманский театр» дип оформить итәргә приказ бирде. Безгә «Иллюзион» дигән кино-театр бинасын бирделәр. Бу бина әлек аерым хуҗаныкы иде; ул аны бөтен җиһазлары белән калдырып, ишекләрен бик зур йозаклар белән бикләп киткән иде. Комиссия белән шул бинаның ишекләрен ачып кереп, җиһазларга опись ясап, әйберләренең барысын да безнең карамакка тапшырып киттеләр. Волжская моңа бик шатланды.

— Менә, иптәшләр, бу көнне дә күрербез икән. Татар артистлары, ничә еллар буена оясыз казлар кебек аптырап, шәһәрдән-шәһәргә йөри иде. Бүген үзебезнең театр залыбыз булды. Инде безгә, моның кадерен белеп, тырышып эшләргә генә калды, — диде ул. Шуннан театр бинасына бераз ремонт ясап, атнасына бер тапкыр шәһәр халкы өчен билет сатып, ике тапкыр гаскәриләр өчен һәм бер тапкыр балалар өчен бушлай көндезге спектакльләр, концертлар куя башладык.

Бу вакытта сугышлар Воткинский заводы һәм Сарапул тирәсендә бара иде. Көннәрнең берендә Казаннан ярдәмгә татар полкы килде. Командиры Габидуллин, комиссары Ганиев иде. Бу татар полкы өчен Г. Коләхметовның «Яшь гомер»ен куйдык. Бу полкта Казанда театр уйнап йөргән Гази Салтыковский дигән егет бар иде. Командир белән сөйләшкәннән соң, бу егетне безнең труппа карамагына җибәрделәр. Пермь шәһәрендә үзешчән түгәрәктә күп еллар буена уйнаган Насибулла Чикин да Ижга килеп чыкты. Бу иптәшне дә труппага алдык. Труппабыз тагын көчәеп китте: 15—16 кеше булдык. Зуррак әсәрләр дә куя башладык. Галиәсгар Камал әсәрләреннән «Уйнаш» драмасын, «Банкрот» һәм «Саран» комедияләрен дә куйдык. Таҗдаровның «Яшь хатын» әсәрен, Закир Сәетзадәнең «Бичара Бибиҗиһан»ын, Рәүф Шаһидның «Эшәкеләр»ен, Мәхмүт Нуримановның «Чын мәхәббәт» әсәрләрен куйдык. Рус артистлары белән бергә яңа елны каршы алу кичәсе үткәрдек. Шул кичәдә Галиәсгар Камалның «Безнең шәһәр серләре» исемле комедиясеннән «Әдәбият» кичәсендә җәнҗал» пәрдәсен русчага тәрҗемә итеп, русча уйнадык. Спектакль зур алкышлар белән барды.

Шушы рәвешчә матур гына эшләп килеп, 1919 елның февраль аена да кердек. Бу вакытларда инде Воткинский заводлары да кызыллар тарафыннан алынып, бу яктан фронт ерагайган иде. Шунлыктан Ижевскида гаскәрләр аз калды. Көннәрнең берендә Сарапулдагы Икенче армиянең Сәяси бүлегеннән безнең труппаны Сарапулга чакыру кәгазе килде. Без Сарапулда гаскәрләр һәм шәһәр халкы өчен спектакльләр куя башладык. Мондагы спектакльләр алдыннан доклад, митинглар үткәрелә иде. Сарапулда ике атна чамасы эшләгәч, мине штабка чакырдылар. Штабта Икенче армиянең командиры Шорин һәм Азин дивизиясенең комиссары Пылаев утыра иде. Шуннан Шорин миңа:

— Менә Азин дивизиясенең комиссары иптәш Пылаев кайткан. Аның әйтүенчә, дивизиядә татар гаскәрләре бик күп, алар сезне үзләренә чакыралар. Азин үзе дә сезнең труппаны дивизиясенә җибәрүне сораган. Шуңа күрә, без сезнең труппаны 28 нче дивизиянең кыр штабы карамагына җибәрәбез, — диде.

— Мин үзем китәргә риза, — дидем мин. — Коллектив та каршы килмәс дип беләм. Ләкин арабызда авыру кешеләр, шулай ук, хатын-кызлар, бала-чагалы кешеләр дә бар. Алар турында уйлап карарга кирәк.

Шуннан ул фронт шартларында эшли алырлык кешеләрнең исемлеген төзеп китерергә кушты.

Кайтып, иптәшләрне җыеп, мәсьәләне аңлаттым. Гази Салтыковский сикереп торды да:

— Бик шәп, китәбез, иптәшләр! Мине китүчеләр исемлегенә яз, — диде. Насибулла Чикин да язылды. Ирләрдән башка язылучы булмады. Коллективтагы өч хатын-кызның берсенә дә китәргә мөмкинлек булмады. Чөнки Волжскаяның сәламәтлеге бик начарланып киткән иде. Аның китмәвен мәгъкуль күрдек. Инде калган ике артистканың кулларында икешәр-өчәр яшьле балалары бар иде.

Шуннан икенче көнне барып: «Өч кенә кеше китү мәгълүм булды», — дидем. Комиссар: «Давай, татар гаскәрләре арасыннан эзләп карыйк», — дип, мине бер частька ияртеп китте. Сораша торгач, ике татар егете табылды. «Берсе—Кукмараныкы, Хөсәен Хәбибрахманов дигән егет, икенчесе — Хәнәфи Габитов дигән егет, Сарапулдан иде. Икесен дә Сәяси бүлек аша оформить итеп труппага алдык. Кызлардан берәү дә булмагач, Әгерҗегә кайтып эзләп карау фикере туды. Командировка кәгазе яздырып, вокзалга төшеп киттем.

Сарапулда, мәгариф бүлеге янында, Буби кызы Мәрьям Ибәтуллинаны (Зәйнуллинаны) очраттым. Бу кызның Буби драмтүгәрәгендә катнашып, концертларда җырлауларын белә идем. Аны очрату күктән эзләгәнне җирдән табу кебек булды. Мәсьәләне аңлаттым. Ул бераз уйланып торды да ризалыгын белдерде. Шуннан соң, Мәрьям Ибәтуллина Икенче армиянең Сәяси бүлеге карамагына җибәрелә, дигән документны алдым да яшьләрне, кызларны Әгерҗе китапханәсенә җыеп, хәлне аңлатып бирдем. Мөкәррәмә исемле бер кыз чыкты да:

— Мин барырга телим! — диде.

Мөкәррәмәгә Сарапулга китү өчен кайтып әзерләнергә кушып, Ижевск заводына киттем. Анда түгәрәктә җыр-бию кичәләренә катнашып йөрүче бер бик үткен Мәстүрә Абканиева исемле кыз бар иде. (Җырчы Фәттах Латыйповның туганы.) Шул кызны табып, аны да күндердем. Ике көндә әйләнеп кайтып, штабка барып хәбәр иттем(?) Анда тагын Камилә Мәҗитова дигән бер кыз, Сарапул кызы, көтеп утыра иде. Бу кызны Сарапулда калган иптәшләрем табып китергәннәр. Шулай итеп, өмет иткән өч кыз урынына, дүрт кызыбыз булды. Мин шундук бу шатлыкны комиссарга белдердем. Составыбыздагы кешеләр, исемлек төзелеп, приказ аша үткәрелде. Хозчастька барып, барыбызга да кием-салым, азык алдык. Икенче көнне Камбаркага, 28 нче дивизиянең кыр штабы карамагына китәргә тиеш булдык. Приказ буенча безгә «Икенче армиянең Сәяси бүлеге каршындагы Беренче мөселман фронт группасы» дигән исем бирелгән иде. Киемнәр, азыклар өстенә тагы 9 винтовка, 9 граната һәм бер ящик патрон да алдык. Ирләр һәм хатын-кыз — барыбыз да, гаскәри киемнәр киеп, дүрт атка төяләп, Кама бозы өстеннән Камбарка станциясенә киттек.

## Азин дивизиясендә

Камбарка авылына барып җитеп, зур гына йортка урнаштык. Мине шунда ук, броняллы поездга утыртып, кыр штабына, Азин янына җибәрделәр.

Штаб Куяда дигән станциядә, вагонда иде. Анда мине Азин үзе кабул итте. Күптәнге танышын очраткандай, янына утыртып сөйләште. Уеннарыбызның нинди характерда булачагы турында, артист-артисткаларыбызның кемнәр булуы турында аерым-аерым сорашты да:

— Молодцы, татарские артисты! — дип куйды.

Шуннан кайсы авылларга, кайсы частьларга бару хакында маршрут билгеләнде. Шул маршрутны алып, иптәшләр янына кайттым. Сәхнәгә куяр өчен берәр, икешәр пәрдәле әсәрләр сайлап, репетицияләр башладык. Шулай ук концерт номерлары да әзерләдек. Сәяси бүлектә безгә җиңелрәк комедияләр белән рус гаскәрләре дә аңларлык концерт номерлары төзергә куштылар. Программа төзеп, Камбаркадагы гаскәрләр өчен дүрт мәртәбә спектакль-митинг үткәргәннән соң, артык багажларыбызны квартирада калдырып, маршрут буенча, башка авылларга киттек. Уи авылда булып, егерме бишкә якын спектакль, концерт-митинглар үткәрдек. Аннары Куяда станциясенә барып чыктык.

Шушы йөрүдә бер вакыйга булды. Бер кичерәк кенә авылга тукталдык. Монда гаскәрләр күп иде, шулар өчен спектакль куярга тиеш идек. Ләкин бу авылда йөздән артык йорт булса да, сәхнә ясарлык бер генә дә зур йорт юк иде. Кышкы салкынга карамастан, үзебез урнашкан йортның лапасында куярга булдык. Киемнәрне һәм гримнарны өйдән әзерләп чыгарга ниятләдек. Декорацияләрне лапаста төзегәч, пәрдә ачып, уйный да башладык. «Әдәпсезләр арасында хиҗапсыз кыз» комедиясен уйнадык, ахырда русча-татарча номерлар белән концерт бирергә тиеш идек. Беренче пәрдәне тәмамлап, икенчесен генә уйный башлаган идек, балалар: «Пожар, пожар!» дип кычкыра башлады. Мин мулла ролендә уйный идем, аптырап калдым. Шулай да уенны үзем дәвам итәм. Гаскәрләр арасыннан да «Пожар!» дип кычкыручылар булды, ләкин беркем дә урыныннан кузгалмый, көлешә-көлешә карап утыра бирә. Без уйныйбыз, бернәрсә дә сизмибез. Ике гаскәри иптәш, лапас түбәсенә менеп, саламнарны туздыра башлагач һәм сәхнәгә янган салам катыш кар төшкәч кенә аңладык: бу пожар безнең түбәдә икән. Бу хәлне күргәч, уенны туктатып, пәрдәне ябарга мәҗбүр булдык. Моның сәбәбе бик гади иде. Гази Салтыковский мулла малае ролендә һәм аңа спектакль буена көлмәкчән һәм яланаяк уйнарга кирәк иде. Мәрьям Ибәтуллина белән Мәстүрә Абканиевалар да юка күлмәктән һәм туфлядан гына уйныйлар иде. Салтыковский бу ике кызны кызганып, шулай ук үзенең хәлен дә искә алып, лапасның бер почмагына тимер мич куйган, аның морҗасын салам түбәдән чыгарган да ягып җибәргән. Беренче пәрдә барганда түбәдә кар күп булганга, салам пыскып кына яна биргән; соңра, кар эреп беткәч, ут көйрәп киткән. Тимер мичне чыгарып ташлап, сәхнәне себердек тә, пәрдәне ачып, янадан уйный башладык. Түбәдә ачык калган тишектән сәхнәгә якты төшеп торуы театрларда була торган прожекторларны хәтерләтә иде. Бу спектакль әсруча көлке эчендә барды. Куелган әсәр дә көлке комедия булу өстенә, бу хәл дә өстәлгәч, көлми чыдарлык түгел иде. Үзебез дә көчкә генә уйнап чыктык.

Кыр штабы бронялы поезд белән Куяда станциясендә тора иде. Колчакның генерал Гайда полкы Красноуфимск шәһәрендә булып, шушы ике арада каты сугышлар бара иде. Кыр штабында эшләнгән эшләребез турында хисап бирдек. Безгә берике көн ял итәргә куштылар.

Ләкин ял итәргә туры килмәде. Колчак гаскәрләре безне боҗрага калдырып, тылдагы Янаул станциясенә барып чыккан. Безгә тиз генә чигенергә әмер булды. Алда тимер юл өзек булганлыктан, атларга төялеп бөтенләй икенче якка — Гальянга киттек. Бронялы поездда җәяүле гаскәрләр генә калды. Соңра бронялы поездны да, дошманга бирмәс өчен, шартлатканнар. Без, утыз километр чамасы барып, Әлнәш дигән авылга туктадык. Авыл читендә окоплар казылды, пулеметлар куелды. Азин үзе килеп: «Авыр артиллерия белән хуҗалык бүлекләрен ераграк чигендерү өчен безгә монда бер-ике көн ныгып торырга кирәк. Шуңлыктан, монда концертлар оештырыгыз, митинглар үткәрегез!» — дип әмер бирде. Мәйданда митинглар ясалды, русча-татарча концерт үткәрелде. Икенче көнне безгә моннан егерме-утыз километр ераклыктагы авылга китәргә куштылар. Без төялеп киттек тә шул авылга барып туктадык. Бу авыл бер генә урамлы, озынлыгы өч-дүрт километр чамасы булыр, аның бер башында руслар, икенче яртысында башкортлар тора иде, мәчете дә, чиркәве дә бар иде.

Бер җайлы гына йорт табып, сәхнә әмәлләштереп, декорацияләрдән сәхнә төзеп, пәрдә корып митингны башлап җибәрдек. Артистлар гримга утырдылар. «Әдәпсезләр арасында хиҗапсыз кыз» куелырга һәм концерт булырга тиеш иде. Пәрдәне ачып спектакльне башладык. Йорт халык белән тулды. Спектакль барган вакытта кинәт авыл башында атыш башланды. Без башта спектакльне туктатмаска да уйлаган идек. Ләкин атышлар торган саен якынлаша барды. Тамашачылар да таралырга тотындылар. Шуннан гримнарны да бозмыйча, тиз-тиз җыенып, сәхнә киемнәреннән атларга төялдек тә чаптык.

Чикин минем янга килде дә: «Локман дус, безне аклар әләктереп алсалар, син безне коткарырга тырыш инде, яме! Алар сиңа тимәсләр», — диде. Үзе көлә. Эшнең нидә икәнен аңлап алгач, мин үзем дә шаркылдап көлеп җибәрдем. Чөнки минем өстә чапан, башымда чалма иде. Хәтта ябыштырган сакал-мыекны да куптармаганмын. Арттан килгән пулялар сызгыра-сызгыра үтеп китәләр. Чаптыра-чаптыра бер

егерме-утыз километр җир киткәч, атларыбыз да арыды, үзебез дә ачыктык. Шул сәбәпле, бер авылга тукталырга булдык. Квартирага урнаштык та капчыкларда булган ат итен алып, казанга пешерергә салдык. Азык һәрвакыт капчыгы белән үз янnetwork-да йөри иде, бу эшләр белән Гази Салтыковский идарә итте, шуның өстенә, ул гаскәри булганлыктан, коллективта военрук кебек бер кеше, мылтык һәм гранаталар белән ничек эш итәргә дә ул өйрәтә иде. Бу эшләр белән кызлар да кызыксына иде. Аш пешерүчеләребездән Насибулла Чикин белән Мәрьям Ибәтуллина казан тирәсендә, калганнарыбыз өстәл тирәсендә тезелеп утырып, аш пешкәнен көтә генә башлаган идек, ни күз белән күрик, яңадан атышлар башланды. Багажларны тиз генә яңадан атларга төяп, өстәлдәге туралган икмәкләрне эләктереп, чәйни-чәйни чыгып чаптык. Безгә насыйп булмаган аш кайный-кайный казанда калды. Тагын 20—30 чакрым китеп, бер авылга тукталдык. Тиз генә килеп җитә алмаслар әле дип, ат итен яңадан казанга салдык. Кызларны капка төбенә сакчы итеп куйдык. Ирләр атларны ашатырга, эчертергә тотындылар. Чөнки олаучыларыбыз да арттагы авылда качып калганнар иде. Бер-ике сәгать чамасы үткәч, өйгә кереп: «Я, поварлар, ашыгыз буламы», дигәч, Насибулланың: «Сугышта чыныккан атның ите дә, каһәр, каты була икән, тагы бер егерме минут кайнасын, аннары ашарбыз диюенә, капка төбендәге кызларыбыз: «Яңадан чигенергә!» — дип килеп керделәр. Шуннан Насибулла казандагы итне кулларын пешерә-пешерә капчыкка алып салды. Барыбыз да төялеп тагын чаптык. Бу юлы да шактый җир китеп, Фоки-Богородский дигән заводка барып кердек. Бу заводта инде бездән алда киткән артиллерия, шулай ук пулеметлар да бар иде. Иптәш Азин үзе дә монда килеп чыкты. Бу хәлләрне күргәч, без куанып киттек. Кыр штабы да шушында тукталган иде. Иптәш Азин монда биш-алты көн ныгып торачагыбызны аңлатты. Квартирга урнашып, ял иттек. Икенче көнне урамда, ачык мәйданда, концерт бирдек, митинг үткәрдек, кино-картиналар күрсәтелде. Сугышлар моннан егерме чакрым җирдә бара иде. Заводтан сирәк-сирәк кенә артиллерия атып тора. Өченче көндә тагын митинг үткәрелде. Русча-татарча концерт бирдек. Ахырда тынлы оркестр музыкасы астында төрле биюләр башланды. Мәстүрә Абканиева ирләр киеменнән «Казачок»ны биеп җибәрде. Карап торган җирендә, чыдый алмыйча, җилкәсендәге буркасын салып ташлап, Азин үзе дә биюгә кушылды. Урам тулы халык һәм гаскәрләр кул чабып тордылар. Соңра гаскәрләр арасыннан да чыгып биючеләр булды. Күңел ачулар беткәч, Азин атына атланды да, гаскәрләргә мөрәҗәгать итеп:

— Иптәшләр! Безнең тыныч тормышыбызны бозмасыннар өчен, бу заводны дошманнан сакларга кирәк. Шуның өчен дә пехота — окопларыгызга, атлы гаскәрләр — минем арттан! — дип әйтүенә, тынлы оркестр гаскәри марш уйнап җибәрде, гаскәрләр, «Ура» кычкырып, Азин артыннан чаптырып киттеләр.

Иртәгесен без бу заводтан туры Гальянга барып чыктык. Анда да халык һәм гаскәрләр өчен митинг-концерт үткәреп, кино күрсәттек. Икенче көнне, тар юлдан гына йөри торган кечкенә вагоннарга урнашып, Ижевскига киттек. Барып җиткәч, бронялы поездның иң ахыргы ачык вагонына төялеп, Әгерҗегә юнәлдек. Әгерҗедә ике-өч көн тордык. Шушы көннәрдә базар урамында, бер агач кибет алдында, сәхнә ясап, митинг-концерт үткәрдек. Инде яз башланган, юллар бик пычрак иде. Фронт Әгерҗедән ун километр җирдә. Вокзалдагы барлык составларны җибәреп бетергәч, бронялы поезд составы белән безгә дә китәргә әмер булды. Колчак Ижевск ягыннан да, Сарапул ягыннан да кысрыклый иде.

Фронтта берничә урында концерт куйганнан соң, Вятская Полянага килеп тукталдык. Суның теге ягында аклар, бу ягында кызыллар иде. Яр буйларында окоплар казылды. Шушы рәвешчә, Азин дивизиясе, чигенүдән туктап, Вятка суы буенча фронтны ныгытты.

Шушы көннәрдә Казаннан Камил Якуб иптәш килде. Татарча газеталар, китаплар, революцион җырлар алып килгән иде. Гаскәрләр арасында таратыр өчен безгә дә бирделәр. Беренче мәртәбә Камил Якуб иптәшне шунда күрдек. Безнең эшләребез хакында сорашты һәм шулай фронтның алгы сызыгында гаскәрләрнең рухын күтәреп йөрүебезне бик хуплады. Ярдәм кирәк була-нитә калса, үзенә мөрәҗәгать итәргә кушты. Тора торган квартирабызга да ике-өч мәртәбә килеп, репетицияләребезне карап утырды. Кызыл гаскәр киемендәге кызларыбызны күреп, аларны аеруча мак-

тады. «Каһарман татар кызлары икәнсез, мин бу труппа хакында ишеткән идем, ләкин нинди артистлар, кемнәр икәнен генә ачык белми идем», — диде.

Көннәрнең берендә кич белән килеп керде дә, бераз сөйләшеп утыргач, мина үзе белән окопларга гаскәрләр янына әңгәмәләр үткәрергә барырга тәкъдим ясады. Листовкалар, газеталар күтәреп, икәүләшеп чыгып киттек. Яр буена житкәч, караңгыда җиргә ятып, түш белән шуа-шуа гына окопларга барып кердек. Гаскәри иптәшләр әиз бик күп сораулар бирделәр, аның килүен бик яраттылар. Газеталар, китапларны таратып, дөнья яңалыкларын сөйләп, кайтып киттек.

Азин дивизиясенең кыр штабы Вятская Полянада урнашты. Икенче армиянең штабы бу вакытта Казанда иде. Көннәрнең берендә армия штабына хуҗалык бүлегеннән азык-төлек алырга барырга булдылар һәм шул поезд белән безне дә Казанга берәр атнага дип җибәрделәр. Чөнки бу көннәрдә гаскәрләр арасында переформирование бара иде.

Без Казанга килгәндә, Галиәсгар Камал белән Габдрахман Камал запастагы II нче батальон клубында эшлиләр иде. Сафа Габитов дигән артист «Аң» труппасы исемендә кечерәк кенә состав белән клубларда эшләп ята иде. Кәрим Тинчурин, Хәмит Колмәмәт, Ситдыйк Айдаров, Гөлсем Болгарская, Гөлсем Камская, тагы берничә кеше Мөселман хәрби коллегиянең Сәяси бүлегендә учетта торалар иде. Казанда даими рәвештә эшли торган татар дәүләт труппасы ул чакта оештырылмаган иде әле. Шушы артистлар сирәк-сирәк кенә, кечкенә күләмдә генә спектакльләр, концертлар куйгалыйлар иде.

Шушы көннәрдә Аркадий бакчасында Сабан туе бәйрәме үткәрелде. Елга бер килә торган бәйрәм концертында без дә катнаштык. Беренче бүлектә бер пәрдәлек «Ач гашыйк» әсәре куелды. Анда Тинчурин белән Әхмерова уйнады. Икенче бүлектә «Шәкерт имтиханга әзерләнә» дигән әсәрдә мин һәм Мәрьям Ибәтуллина уйнады. Концертта алар да, без дә катнаштык.

Габдрахман Мангушев белән Габдрахман Камал Самар ягындагы фронтка бару өчен, татар труппасы оештырганнар иде. Ләкин артисткалары житешми икән. Безнең труппада, киресенчә, ирләр җитешми иде. Шуңа күрә, мин алардан берәр артист табып бирүләрен сорадым. Алар Мөхәммәт Вәлишин белән Гыйлаҗ Сабитовны тәкъдим иттеләр. Вәлишин квартирасына барып сөйләшеп, аның ризалыгын алгач, Гыйлаҗ Сабитовны күндерергә киттек. Сабитов та шулай ук китәргә риза булды.

Гыйлаҗ Сабитовны, Мөхәммәт Вәлишинны һәм Гази Салтыковскийның хатыны Нәсимә Зәйнуллинаны алып, агитаторлыкка Шакирҗан Хәмидине кушып, Мөкәррәмә Әсфәндиярова белән Камилә Мәҗитованы татар бригадасына күчереп, 3 май көнне Вятская Полянага, кыр штабына, киттек.

Вятская Полянада безгә, Мамадышка кадәр булган авылларда гаскәриләр һәм авыл халкы өчен митинглар, спектакль, концертлар үткәрергә кушып, маршрут бирделәр. Кукмарада ике-өч спектакль куйдык та Өлге дигән авылга киттек. Анда тагын, ике көнгә өч спектакль үткәреп, Мамадыш ягына борылдык. Шул яктагы авыллар буенча киттек. Дусай дигән авылга килеп, митинг һәм спектакль үткәрдек. Ләкин бу спектакльне карарга ирләр генә килгән, хатын-кызлардан берәү дә юк иде. Бу хәл безгә гаҗәбрәк тоелды. Чөнки башка авылларда хатын-кызлар азмы-күпме булса да күренгәлиләр иде. Шуннан Шакирҗан Хәмиди белән квартирга кайтып, йорттагы хатын-кызлар белән сөйләштек. «Әй, абыйлар, безгә бит ирләр җыелган җирдә күренергә ярамый. Шуңа күрә без өйдә генә кызыгып утырабыз», диде хуҗа кызы. Без: «Әгәр дә иртәгә мәктәптә ирләр затын кертмичә, махсус хатын-кызлар өчен генә спектакль үткәрсәк, барырлармы?» — дип сорадык. Хатын-кызлар куаныштылар.

Икенче көнне көндезен мәктәптә хатын-кызлар өчен генә махсус бер спектакль — «Әдәпсезләр арасында хиҗапсыз кыз» һәм концерт бүлеге булды. Шакирҗан абый хатын-кызларның да ирләр белән бертигез хокуклы булулары, кызылларның шул хокукны яулап алып бирү өчен сугышканлыклары турында доклад ясады. Мондый әшебезне хатын-кызлар бик ошатты. «Күзебезне ачтыгыз бит», дип, уен беткәч тә озак кына сөйләшеп утырдылар.

Маршрутыбызны икенче июньдә тәмам итеп, яңа заданиеләр алырга штабка кайттык. Бер генә айга чыккан Сабитов белән Вәлишин да: «Булмаса тагын бераз

йөрик әле», дип, труппада калырга риза булдылар. Вятский Полянда да гаскәрләр өчен бер спектакль, концерт оештырдык. Мәйданда бик зур митинг үткәрелде. Шул көннән башлап Колчакка каршы ныклы һөҗүмнәр башланды. Казаннан яңа көчләр килде. Бронялы поезд, тимер юл күперennән су аркылы чыгып, дошманны кысрыклый башлады. Азин дивизиясе Алабуга шәһәрен азат иткән иде инде. Без хуҗалык часте гаскәрләре белән Алабугага кергәндә, шәһәр бөтенләй диярлек буш калган иде. Бара-бара, Камаево авылына туктап, ике көндә ике спектакль үткәрдек. Монда гаскәр дә, шулай ук авыл халкы да күп иде. Тирсә янында бик каты сугышлар булган. Азин иптәш үзе атлы гаскәре белән Тирсәне әйләндереп, чолганышта калдырып, авылда булган өч йөздән артык Колчак гаскәрен пленга алган иде. Без шул авылга килеп җитеп урнаштык та митинг, спектакль үткәрдек. Икенче көнне иптәш Азин әсирләрне күрсәтеп: «Менә, иптәш артистлар, бу әсирләр өчен дә бер махсус концерт бирегез, күрсеннәр безнең ни өчен сугышканны», дигәч, шул әсирләр тора торган йорттагы лапаста бер пәрдәлек «Денщик Гали» комедиясен күрсәттек һәм концерт бирдек. Алар арасында татарча белүчеләр дә күп иде.

Колчак гаскәре тәртипсез рәвештә чигенә, төркеме-төркеме белән пленга төшә иде. Без исә алар артыннан һаман алга атладык.

Сугышчылар һәм халык күп булган урыннарда спектакльләр куя-куя, фронт белән Ижевскига барып җиттек.

Монда спектакльләр куярга туры килмәде, чөнки Воткинский заводы өчен бик каты сугышлар бара иде әле.

Шул заводка барып кергәндә, зират янында көтелмәгән атышлар килеп чыга, иптәш Азинның аты яралана, үзенең дә аягына пуля тия. Яралы булуына карамастан, ул, икенче атка атланып, сугышка омтыла. Завод алына.

Колчак бу вакытта Пермь шәһәрендә иде. Икенче көнне Пермь шәһәре дә кызыллар тарафыннан алынды. Колчак Екатеринбургта дигән хәбәр килде. Ике көннән Екатеринбург шәһәре дә алынгач, «Колчак Омскига качты», дигән хәбәр таралды. Шуннан соң Азин дивизиясенә кире Сарапулга кайтырга приказ булды. Шулай итеп, Колчак Казанның капкасы булган Вятский Поляннан куылгач, Азин дивизиясе кире Сарапулга кайтты. Без дә кайттык. Анда бер көн торгач, мине Икенче армия штабына чакырттылар.

— Менә, иптәш Антов, Азин дивизиясен Көнчыгыш фронтына җибәрергә дигән приказ бар. Сезне дә шунда, дивизия белән бергә, «Көнчыгыш фронтының аерым группасы» карамагына җибәрәбез, — диделәр. Квартирага кайтып, бу хәбәрне иптәшләргә сөйләдем. Безнең белән бер айга гына чыккан Вәлишин белән Сабитов: «Без ике ай йөрдек, безне Казанга җибәрегез инде, өйдә семьялар да бар. Ә сезгә икенче артистлар җибәрерләр. Камил Якуб иптәш тә шулай дип әйтте бит», — дигәч, каршы килеп булмады. Чөнки бу иптәшләр чыннан да күп хезмәт күрсәттеләр. Мөхәммәт Вәлишин баш рольләрдә уйнавы өстенә, концерт бүлекләрендә татарча һәм русча көлке декламацияләр сөйләве, матур биюләре белән тамашачыларның мәхәббәтен казанды. Зур рәхмәтләр әйтеп, бу иптәшләрне озатып җибәрдек. Труппабызда артистлар кимегәч, яңа артистлар алып килү өчен, минем үземне дә өч көнгә Казанга җибәрделәр. Ләкин Казанда ике-өч көн эчендә генә берни дә чыгарып булмады. Вәгъдә генә бирделәр. Мин бик ашыга идем, үз частемнан аерылып калуым бик ихтимал иде. Тиз генә Сарапулга әйләнеп кайтырга мәҗбүр булдым. Сарапулга кайтып кердем дә вокзалдан туп-туры штабка чаптым. Анда комиссарны очратып, мәсьәләнең ничек торуын аңлатып бирдем. Казанга, хәрби коллегиягә: «Биш кешене Вольск шәһәренә җибәрегез», дип телеграмма суктылар. Труппада калган алты кеше, шул кичтә үк, Вольск шәһәренә китәргә тиеш иде. Пристаньга төштек тә каюталарга урнаштык. Пароходның кырыена зур баржа тагылган иде. Шул баржага сугыш коралларын, атларны, азыкларны төяп бетергәч, иптәш Азинның үзе белән бергәләп, төнге сәгать икедә кузгалып киттек.

# Н. К. Крупская белән очрашу

Пароход Чистайга килеп туктады. Ни күзем белән күрим: дебаркадерда Нәби Вахитов басып тора. Ул мине күрү белән: «Локман, бу синме?» дип, басмалар куйганны да көтмичә, туры безнең пароходка сикереп төште. Мине кочаклап алды. Өч-дүрт ел очрашканыбыз юк иде. Ул минем туганнарым һәм эшләребез хакында сорашты. Иптәшләрем белән таныштырдым. Безнең фронтта эшләп йөрүебезне бик ятратты. Мулланур Вахитов хакында да сөйләшеп, кайгырышып алдык...

Тагы юлга чыгып, беркая тукталмыйча, Самарага барып җиттек. Мин каютада язып утыра идем, Гази Салтыковский йөгереп керде дә: «Иптәш Аитов, әйдә әле, күрше пароходта Надежда Константиновна Крупская бара», — диде. Палубага чыктык. Янәшәбездә генә «Красная Звезда» исемле агитпароход туктаган иде. Аның палубасында Надежда Константиновна Крупская иптәшләре белән басып тора иде. Иптәш Крупскаяның өстендә буйлы-буйлы җәйге ак костюм, куе коңгырт чәчләрен артка таба тарап өеп куйган. Гадәттән тыш гади һәм мөлаем карашлы икән. Менә ул өсләренә гимнастерка, башларына кызыл яулык бәйләгән ике кызыбызны күреп алды да: «Кызлар, сез санитаркалармы?» — дип сорады. Мәрьям Ибәтуллина: «Юк, без артисткалар», — дип җавап кайтарды. Мин дә: «Болар безнең татар артисткалары», — дип өстәдем. Надежда Константиновна, безнең белән кызыксынып, төрле сораулар бирә башлады. Без, зур куаныч кичереп, үзебез турында сөйләп бирдек. Ул безнең исемгә мактау сүзләре яудырды, сәламләде. Бу очрашу бездә мәңге онытылмаслык тәэсир калдырды...

Пароход Самарадан кузгалып, яңадан беркая да тукталмыйча, Вольск шәһәренә барып җитте.

Бу вакытта сугышлар Деникин гаскәрләренә каршы, Саратов шәһәре тирәсендә бара, икенче яктан, Царицын тирәләрендә, Ворошилов җитәкчелегендәге гаскәрләр дошманны кысрыклый иде. Иптәш Азин да, икенче көнне үк, үзенең атлы гаскәре белән кискен һөҗүмгә кушылды.

Бу сугышлардан иптәш Азин аягы җәрәхәтләнеп кайтты да госпитальгә керде. Анда биш-алты көн яткач, ярасы төзәлеп бетмәүгә дә карамастан, яңадан фронтка китте. Соңгы вакытларда иптәш Азин җәяү йөргәндә култык таягы урынына кылычына таянып йөри башлады.

Шушы ике атна эчендә без ике мәртәбә бер пәрдәле «Кыз сорау», «Деңщик Гали» кебек әсәрләрне сәхнәгә куеп, митинглар үткәрдек. Зуррак әсәрләр яки концертлар куярга көчебез җитми иде. Уйнаучылардан Ибәтуллина, Салтыковский, Хөсәенов һәм мин — 4 кеше генә калган идек, бүтәнебезнең кайсы берсе костюмерша, кайсы сәхнә төзүче һәм суфлер иде. Казаннан артистлар килгәч, программаны көчәйтербез дип уйлап, телеграммалар җибәреп карасак та, беркинди җавап булмады.

Көннәрнең берендә иптәш Азин, фронттан кайтып, гаскәрен ялга куйды. Икенче көнне митинг үткәрелде, «Деңщик Гали»не күрсәттек. Митингтан соң Азин бөтен атлы гаскәренә тезелергә кушты. Үзе, кылычына таянган килеш, аксавын сиздермәскә тырышып, аты янына килде һәм, сикереп атланды да, кылычын селтәп: «Иптәшләр, минем арттан, Урра!» дип кычкырып җибәрде. Гаскәрләр, «Ура!» кычкырып, һөҗүмгә киттеләр.

Кызганычка каршы, бу — легендар командирны соңгы озатуыбыз булган икән. Берникадәр вакыттан соң, без аның, яралы хәлдә, аклар кулына эләгүе хакында аяныч хәбәр ишеттек. Аның һәркайчан үзе янында йөри торган ышанычлы адъютанты — Әгерҗе егете Якуб Әбдрәшитов та шундый ук бәлагә юлыккан икән. Легендар батырның бу фаҗигасен түбәндәгечә сөйлиләр: Азин үзенең атлы гаскәрләре белән уртадан һөҗүм иткәндә, аның уң һәм сул канатындагы гаскәрләре арткарак калганнар. Батыр командир атлыгып Деникин гаскәрләренең эченә барып керә дә дошманны кыра башлый... Бәхетсезлеккә каршы, нәкъ шул вакытта,ияр каешы өзелеп китә һәм Владимир Мартинович Азин, атның баш очыннан атылып, җиргә барып төшә. Дошманнар аны шунда ук камап алалар...

Бу хәл безнең барыбызга да бик авыр тәэсир итте. Аеруча минем үземә нык тәэсир итте. Аны югалту туганымны югалтудан бер дә ким түгел иде. Мин аның белән беренче мәртәбә Әгерҗедә, 1918 елның сентябрь аенда очраштым. Шуннан башлап, 1919 елның сентябренә кадәр үткән бер ел эчендә, фронт шартларында бергә эшләү, бергә яшәү мәңге истән чыкмаслык булып калды.

Иптәш Азин озынрак кына буйлы, чыныккан таза гәүдәле, конгырт чәчле, яна гына чыгып килә торган сирәк сакалын һәркайчан кырып йөрүче, янып торган зур зәңгәр күзле кеше иде. Өстендә — френч, кызыл лампаслы зәңгәр диоганаль галифе, аягында — озын кунычлы, ялт итеп торган хром итек; башына каракүл папаханы, чәчен чыгарып, артка этебрәк кия һәм озын кара буркасын җилкәсенә элеп җибәрә иде.

Без Вольскида яңадан атна-ун көн торсак та, бер спектакль дә куя алмадык. Чөнки Казаннан артистлар да килмәде, икенчедән, татар гаскәрләрен дә төрле частьларга җибәрделәр. Бу хәлдә ятуның файдасы булмагач, безнең труппаны таратырга карар чыгардылар. Габитов белән Хәбибрахмановны үз частьларына озаттылар. Гази Салтыковскийны, партия члены булганлыктан, Казанга, агитаторлар курсына, Мәрьям Ибәтуллинаны Сарапулга, шәһәр мәгариф бүлеге карамагына, мине Казанга, Мөселман хәрби коллегиясе карамагына җибәрделәр. Шулай итеп, «Беренче Мөселман фронт труппасы» үзенең эшен бетереп таралды...

**СЕЗ ҮЗ ИСЕМЕГЕЗНЕҢ МӘГЪНӘСЕН БЕЛӘСЕЗМЕ?**

Вәсим — гүзәл, матур йөзле.
Габид — гыйбадәт кылучы, табынучы.
Гадил — турылыклы.
Гази — сугышта җиңеп чыгучы.
Газыйм — бөек, зур.
Газыймә — гадәттән тыш зур эш, мәсьәлә.
Гали — бөек, олы.
Галләм — бик күп белүче.
Гамил — эшләүче, хезмәт итүче.
Гамир — төзек, бөтен, әйбәт.
Гани — бай, күп маллы кеше.
Гарифә — билгеле, атаклы.
Гасыйм — начар эшләрдән сакланучы.
Гата — бирү, тапшыру, бүләк итеп бирү.
Гафият — исәнлек, саулык.
Гафур — кичерүче, ярлыкаучы.
Гаян — ачык, билгеле.
Гаҗибә — ис китәрлек әйбер.
Гыйрфан — аң, белем.
Гыйсмәт — начар эшләрдән тыелу.
Дилбәр — сөекле, сөйдерүче.
Диләфрүз — сөендерүче, шатландыручы.
Дәүләт — мал, байлык.
Закир — телгә, искә алучы.
Зариф — ягымлы, нәзакәтле.
Заһид — дөнья эшләреннән ваз кичеп, гыйбадәт белән генә шөгыльләнүче ир кеше, монах.
Заһир — ярдәмче, булышчы.
Зиннәт — бизәк, бизәү әйбере.
Зыя — яктылык, нур.
Зәйтүнә — зәйтүн агачы.
Зәки — зирәк, сизгер.
Зәригъ — үренте, шытым.
Илһам — күңелгә салынган нәрсә.
Инсаф — гаделлек, турылык белән эш итү.
Иршад — юлга салу, юл күрсәтү.
Исрафил — мөселман дине буенча, кыямәт көнендә быргы сызгыртырга тиешле фәрештә исеме.
Йосыф — матурлык, күркәмлек иясе.
Кави — көчле, куәтле.
Кадир — булдыра алучы.

# Әдәби мирас

## Киләчәккә өмет белән



Г. Биги — Абдулла Хәсән улы Мостакаев 1890 елның 15 сентябрендә Саратов губернасы Хвалын өязе Татар Шмалагы[1] авылында урта хәлле крестьян семьясында туа.

1891 елда Мостакаевлар семьясы Саратов губернасы Кузнецк өязендәге Биги авылына күчеп китә. 1907 елга кадәр Абдулла шул авылда үсә. Башта шундагы кадим мәктәбендә, аннан 1904 елда шул ук авылда ачылган ысул җәдит мәктәбендә укый. Бу мәктәптә 6 сыйныфны тәмамлап, 1907 елда Оренбургка китә.

Оренбургта «Хөсәения» мәдрәсәсенә керә һәм анда ике ел укый. «Хөсәения»нең эчке тәртибе, андагы консерватив карашлар, дини хорафатлар белән шәкертләр килешә алмыйлар. Иске тәртипләргә каршы хәрәкәт итүчеләрнең берсе булган Абдулла Мостакаев та мәдрәсәдән чыгарыла.

«Хөсәения»дән чыгарылган шәкертләрнең күбесе прогрессив юнәлештәге «Буби» мәдрәсәсенә кабул ителә.

Ләкин «Буби» мәдрәсәсе гөрләп яшәгәндә, реакцион руханилар да тик ятмый. Алар мәдрәсә өстеннән донос ясыйлар. Нәтиҗәдә, мәдрәсәнең директоры белән күп кенә укытучылары кулга алына. Шулай итеп татарлар арасында заманы өчен иң алдынгы, иң прогрессив белем йорты, кояшлы көннәр туганга кадәр, үзенең эшчәнлеген туктатырга мәҗбүр була.

«Буби» ябылгач, Абдулла бала чакта үзе укыган Биги авылы мәктәбендә укыта башлый.

Ә 1913 елда, Яңа Үргәнечтән ерак түгел бер кышлакта мөгаллим булып эшкә урнаша. Бер кыш укыткач, ул Ташкенттагы татар мәктәбенә чакыртыла.

1915 елда Абдулла армиягә алына. 1917 елда авыру сәбәпле ялга чыгып, өенә кайта һәм инде аңа исәе армиягә яңадан барырга туры килми.

Бөек Октябрь революциясен Абдулла контрреволюцион көчләргә каршы көрәштә каршылый.

Ул вакытларда Коканд шәһәре Совет властенең дошманнары булган автономистларның үзәгенә әверелә. Иргаш курбашилар бандасы белән берләшкән автономистларга каршы Советларның кораллы көчләре хәрәкәт итә. Контрреволюция җиңелә, Кокандта власть Советлар кулына күчә.

Кораллы бәрелешләр бетүгә, Абдулла Үзбәк учительская семинариясен советчыл педагогик уку йорты тибында торгызуга булыша.

1918 елда Абдулла Мостакаев большевиклар партиясе сафына алына.

Партиягә кабул ителү белән, аңа тагын да күп төрле курслар һәм халык университеты оештыру, аларга җитәкчелек итү, агитатор булу кебек җаваплы эшләр йөкләнә. Бөтен Төркстан Советларының VIII съездына делегат булып сайлана.

1920 елның башыннан Абдулла ага Мостакаев Ташкент төрек-татар мәгариф институты директоры булып эшли башлый.

1923 елда ул Мәскәүнең Я. М. Свердлов исемендәге Коммунистлар университетына укырга керен, аны 1926 елда тәмамлый.

---

[1] Хәзерге Ульяновск өлкәсе.

*Соңгы елларда ул Үз. ССР Фәннәр академиясенең Философия һәм хокук институтында өлкән гыйльми сотрудник булып эшли. 1964 елдан персональ пенсионер.*

*Г. Биги әдәбият мәйданында 1911 елдан күренә башлый. Ул үзенең шигырьләрендә иске тормышка каршы көрәшкә, якты киләчәккә өмет белән яшәргә, туктаусыз алга омтылырга өнди.*

*Татар әдәбияты тарихында игътибарга лаек булган, ләкин әлегә читтә калып, онытыла барган әдәби мирасыбыз Г. Биги иҗаты белән генә чикләнми, әлбәттә. Аларны җыярга, тупларга һәм киң катлау укучыларыбызга җиткерергә кирәк.*

*ЛОТФИ ҖӘФӘРОВ.*

*Г. Биги*

## Ил уянды

Ил уянды, ил терелде, илдә якты таң туды;
Ил яңарды, ил агарды — илдә көчле аң туды.
Кайный илләр, шаулый җилләр, изге ут ялкынлана;
Ут эчендә, йорт эчендә мәңге үлмәс җан туды.
Тибрәнә ил, тибрәнә җил, яшь йөрәкләр кузгала;
Йоклаган, сулган йөрәктә саф, гали вөҗдан туды.
Изри ташлар, айный башлар — тынчыган уйлар бетә;
Ил күгендә очты нурлар, илдә көч, илһам туды.
Ил йөзендә нур чәчелгән, нурда яшь гөлләр йөзә,
Ил күгендә мәңге сүнмәс ай, кояш, чулпан туды.
Ил ирекле, ил күрекле — алда якты изге юл;
Ил, ирек саклар өчен бик күп арысланнар туды.

Ил уянды, ил терелде — көнчыгышта таң туды;
Ил агарды, ил яңарды — яшь буында аң туды.

«Таң», № 1, 1920.

## Җиңелмим

Авыр-ямьсез бу тормыш мәйданында,
Явыз, алдакчы, комсызлар янында,
Томан астындагы кыска гомернең
Йөрәк яргыч, тонык, нурсыз таңында,
Уза төрле читен хәлләр башымнан,
Зәһәр агу чыга татлы ашымнан.
Күрәм кайчакта хурлыклар, газаплар
Үземнең иң якын, шәп юлдашымнан.

Шулай да һич берәүгә бер ялынмыйм,
Сузып куллар, ялынганга салынмыйм,
Өметнең актыгын эчтән югалтып,
Йөрәксезләр кеби бетмим, чалынмыйм.
Качан, кайда үләрне бер дә белмим
(Әҗәлгә каршы кем дә тапмаган им),
Вә ләкин шул оятсыз бәндәләргә
Җаным бар чакта баш бирмим, җиңелмим.

«Шура», № 11, 1913.

## Бер мескенгә!

И мескен! Кайт уеңнан — кермә утка,
Күмер булма, каралма, янма юкка,
Болай да бер кара гүргә керерсен,
Череп туфрак булырга өлгерерсен.
Егылма, ач күзенне, алгарак бар,
Бу салкын җил-давыллар, бәлки, туктар,
Кара көннәр, бу тартышлар-көрәшләр,
Ике күздән түгелгән канлы яшьләр,
Сабыр кыл, кем белә, бер көн бетәрләр,
Гөмер дулкыннары берлән үтәрләр.
Исәр җилләр, бетәр хәсрәтле эзләр,
Өреп, комнар ташып, барысын тигезләр,
Кара ямьсез болытлар һәм качарлар,
Җылы, якты кояшка юл ачарлар;
Ярып яфрак, үсәр кипкән агачлар,
Вә сайрар шунда былбыл-сандугачлар,
Менә шул чакта син дә шатланырсың,
Ачып киң күкрәгенне тын алырсың!
Тырыш барлык көчең берлән чыдарга,
Ярып дошман сафын алга чыгарга,
Явыз тормыш, усал дошманнарыңнан
Үзеңне сакла, бак, бирмә егарга!

«Шура», № 6, 1914.

## Бәхет!

I

«Бәхет кайсы берәүләргә
Ява күктән», — диләр бездә,
Кысып тешне тырышмактан
Бәхетне көтмиләр бездә.
Кая соң, кемгә күкләрдән
Бәхет яңгыр булып яуган,
Яхут алтын, көмеш таулар
Килеп кем өстенә ауган?

II

Әгәр чыксаң берәр якка,
Бәхет ялкыннарын күзләп,
Фәләкне, күз камаштырган
Көмеш-алтыннарын эзләп:
Тырыш тик алга атларга,
Мәшәкатьләргә тез чүкмә,
Фәләктән каршылык күрсәң,
Өметсезләнмә, яшь түкмә.

«Шура», № 7, 1911.

# *Фикер алышу, бәхәсләр*

*Р. Нәфигов,*
тарих фәннәре докторы.

## ГАБДУЛЛА ТУКАЙ БИОГРАФИЯСЕН ӨЙРӘНҮНЕҢ КАЙБЕР МӘСЬӘЛӘЛӘРЕ

> **Мин синең шикелле саф, коеп куйган шагыйрь генә түгел, мин дипломат, политик, общественный деятель дә бит. Минем күз күпне күрә, колак күпне ишетә...**
>
> ***Г. Тукай.***

Г. Тукайның иҗат биографиясен өйрәнү буенча Бөек Октябрь социалистик революциясеннән соң күп эш эшләнде. Әдәбият белемендә Тукай мирасын өйрәнүгә багышланган махсус бер тармагы барлыкка килде.

Тукайның иҗат мирасын өйрәнү КПСС-ның XX съездыннан соң сизелерлек дәрәҗәдә алга китте: күп кенә тикшеренүчеләр — әдәбият белгечләре, тарихчылар, философлар, экономистлар — Г. Тукайның биографиясен һәм бөтен иҗатын өйрәнүгә байтак яңалыклар керттеләр.

Шунысы куанычлы, бу чорда күп кенә әдәбият белгечләре шагыйрь иҗатына караган яңа проблемалар күтәрделәр, тикшеренү тематикаларын киңәйттеләр һәм тирәнәйттеләр. Шул темаларның кайберләрен санап үтик: Г. Тукай һәм «Мулла Насретдин», Г. Тукай һәм Ш. Мөхәммәдовның экономик карашлары; XX гасыр революцион демократиясенең роле һәм урыны турында; татар әдипләренең рус, казакъ, үзбәк әдипләре белән элемтәсе; революцион социал-демократиянең татар язучыларына йогынтысы; царизмның татарлар арасында милли-азатлык хәрәкәтенә карата политикасы; Г. Тукайның Уральскидагы тормышы һ. б.

Шулай булса да, өйрәнелергә тиешле темалар һәм юнәлешләр бүген дә күп әле. Һәм бу — табигый дә: Тукай иҗаты күпкырлы, катлаулы ул.

Безнең уебызча, тикшеренүчеләр алдына архив фондларын җентекләп һәм тулысынча өйрәнү мәсьәләләрен куярга вакыт җитте инде.

Царизм азчылык милләтләрне буып торды, аларның культураларына үсү мөмкинлеге бирмәде. Шунлыктан хәзер ул халыкларның тарихын, матбугатта чыккан фәнни хезмәтләр буенча өйрәнүдән бигрәк, патша чиновниклары язмалары, миссионерлар хәбәрләре, газета һәм журналларның цензор караган экземплярлары буенча өйрәнергә туры килә. Ә алардан нинди мәгълүматлар алырга була соң? Казан университетының фәнни китапханәсендә «Волжский листок» газетасының 1905 елгы цензор экземпляры саклангац. Менә шул газетада татарлар турында, аларның шәһәр һәм губерна күләмендәге революцион хәрәкәттә катнашулары турындагы мәгълүматларның барысын да патша ялчылары, бик тырышып, кызыл кара белән сызып чыкканнар. Бу очраклы хәл генә түгел, бу — патша ялчыларының эш кагыйдәсе. Шулай булгач, матбугатка цензор аша чыккан мәгълүматлар буенча гына эш итүче галимнәрнең хезмәте ни дәрәҗәдә кыйммәт һәм тирән булырга тиеш соң инде?

Урыннардагы архивларны, әйтик, дәүләт һәм партия үзәк архивларын, музей фондларын, теге яки бу кешеләрнең шәхси архивларын җентекләп өйрәнгәндә күп кенә кызыклы фактларны һәм моңарчы билгеле булмаган нәрсәләрне табарга, беркайда да басылып чыкмаган кулъязмаларны очратыр-

га була. Аларның кайберләре мөһим эчтәлекләре белән генә түгел, бәлки алардагы фактларның тирән һәм дөрес гомумиләштерүләр ясарга, Россия халыкларының иҗтимагый фикере үсеш тарихы буенча нәтиҗәләр чыгаруга мөмкинлек бирүләре белән дә кызыклы.

Яшүсмер Тукай һәм кайбер прогрессив фикерле яшьләр ерак Уральскида 1903 елда «Әль-мәгариф» исемле кульязма газета чыгаралар, ә 1904 елдан «Әлгасрел-җәдит» исемле кульязма журнал да чыгара башлыйлар.

«Әлгасрел-җәдит» саннарының берсендә журналны чыгаруны дәвам итү, аны басма органга әверелдерү өчен мәдрәсә шәкертләренең һәртөрле чаралар белән ярдәм итәргә теләүләре турында хәбәр урнаштырылган. Анда шулай ук шәкертләрнең берсе — Г. Тукайның, киләчәктә басма журнал чыгаруны күздә тотып, Оренбургка барып хәреф җыю эшенә өйрәнергә һәм, Уральскига кайткач, «Әлгасрел-җәдит»[1] журналында наборщик булып эшләргә җыенуы турында да әйтелә. Якты га, мәгърифәткә һәм белемгә омтылу өлгергән, һич тә кире кагып булмый торган объектив күренеш иде. XX гасыр алып килгән яңалыклар, үзгәрешләр татар халкына да тәэсир итте. Беренче рус революциясе күп проблемаларны һәм кыенлыкларны хәл итте, Россия халыкларында, шул исәптән татарларда да, вакытлы матбугат булдыру өчен шартлар тудырды. Г. Тукайга да Оренбургка барып йөрүнең кирәге калмый, хәреф җыярга ул Уральск типографиясендә генә өйрәнде.

Архивларда губернаторлар, жандарм идарәләре начальниклары һәм полицейскийлар тарафыннан бирелгән донесениеләр тупланган. Шунда ук гаепләнүчеләрне тикшерү турындагы эшләр, прокуратура һәм судның «фактик» дәлилләре, басма һәм кульязма яшерен политик әдәбият, адресатларына барып җитә алмаган хатлар.

Архив кәгазьләрен башка материаллар һәм документлар белән чагыштырып, тәнкыйть күзлеге аша тикшерергә кирәк. Официаль кешеләр — дәүләт чиновниклары, полицейскийлар, жандармнар (муллалар, руханилар һәм провокаторларга караганнары турында әйтеп тә торасы юк) — куллы аша үткән материаллар үзләрендәге фактларның дөреслеген аеруча җентекләп тикшерүне таләп итәләр.

Кызганычка каршы, архивларда саклана торган документларның җисеменә исеме һич тә туры килми торганнары да бар. Жандарм идарәсе яисә губернатор канцеляриесе тарафыннан бирелгән беренче төгәл булмаган исем астында гына йөртелүче документлар һаман да очрый әле.

Чикләнмәгән властька ия булган патша ялчылары эшнең асылын юри бозып, изелгән халык арасыннан чыккан революционерларын гаепләп килгәннәр. ТАССР дәүләт архивы материаллары буенча, мәсәлән, шул нәрсәне күздән кичерергә мөмкин: урыннардагы власть ияләре хәтта татар большевикларын, Г. Коләхметовны һәм бөтен татар революцион демократларын, прогрессив язучыларны да панисламистлар рәтенә кертеп, аларга «милләтчеләр» дигән ярлык ябыштырганнар[2].

Һәм бу берәр чиновникның мәсьәләне аңлап житкермәве яисә политик наданлыгы аркасында булган очраклы хәл генә түгел.

Бер милләтне икенче милләткә каршы котырту политикасы, «бүлгәлә һәм хакимлек ит» дигән мәгълүм лозунг — самодержавиенең эш методлары нигезендә менә шул нәрсә ята иде. Халыкның бер өлешенең караңгылыгыннан һәм наданлыгыннан файдалану өчен, революцион хәрәкәткә каршы көрәштә патша ялчыларына шулай эшләү җиңелрәк иде.

1909 елның 18 декабрендә, полиция Департаментына яшерен рәвештә җибәргән донесениесендә, Уфа жандарм идарәсе начальнигы Россиядәге «панисламистлар»ның ике төрле категориясе булуын хәбәр итә. Беренче категориягә ул татар яшьләрен — укытучыларны, контора хезмәткәрләрен һәм приказчикларны кертә. Рус «революционерлары тактикасын кабул итәләр»,— дип ачыклый жандарм һәм аларның матбугат органнарын конкрет күрсәтеп һәм кайбер кешеләр-

[1] «Әлгасрел-җәдит» журналы, № 20, 1904 ел. «Әлгасрел-җәдит» журналының 1904—1905 елгы саннары (барысы 20 данә) К. Мотыйгиның улы Х. К. Төхфәтуллинда саклана. Очрактан файдаланып, шул архив материаллары белән танышырга мөмкинлек биргәне өчен, аңа рәхмәт белдереп үтәсем килә. Ул материалларны дәүләт учреждениеләренә сатып алырга бик кирәк, анда чиксез зур, кыйммәтле документлар — халык шагыйре Г. Тукайның беркайда да басылмаган әсәрләре бар.

[2] Бу фактны Россиядә милли азатлык хәрәкәтен беренче тикшерүчеләр үк билгеләп үткән: А. Аршаруни һәм Х. Габидуллин. Россиядә панисламизм һәм пантюркизм турында очерклар. «Безбожник» нәшрияты, 1931 ел, 3 бит.

нең исемнәрен атап үтә: «Азат», «Азат халык» газеталары; Г. Камалның «Яшен» журналы; В. Бәхтияровның «Әлислах»ы; Уральскида чыга торган «Әлгасрел-җәдит» һәм «Уклар» журналлары һәм «Яңа тормыш» газетасы.

Панисламистларның икенче категориясенә Уфа жандармы муллалар, адвокатлар, сәүдәгәрләр оешмаларын һәм «эчтәлеге кадетларныкы кебек дип әйтерлек» программасы булган «Иттифак» союзын кертә[1]. Уфа жандармерия донесениесе буенча, барлык татар яшьләре, барлык демократик җәмәгать эшлеклеләре, шул исәптән Г. Камал, «Азат» һәм «Азат халык» газеталарында басылган күп санлы мәкаләләрнең авторы Г. Коләхметов, Уральскида чыккан «Уклар» журналының нәшире һәм фактик редакторы Г. Тукай «Әлислах»ның актив сотрудниклары Ф. Әмирхан, И. Ибраһимовлар да панисламистлар рәтендә булып чыгалар.

Вакытлы матбугатны, төрле милләт халыклары телендә чыгып килгән махсус басмаларны (бигрәк тә февраль революциясеннән соңгы чордагысын), үзәктә һәм урыннарда чыккан большевистик матбугатны өйрәнүнең әһәмияте аеруча зур[2].

Ленин җитәкчелек иткән «Новая жизнь» газетасы Россиядәге изелүче милләтләрнең политик аңы уяна башлау фактлары турында системалы рәвештә язып, урыннардагы партия оешмаларына милли азатлык хәрәкәте белән җитәкчелек итәргә юнәлеш биреп тора. Бу газета патша власте белән килешү юлларын эзләүче, милләтләрне үзара ызгыштырырга омтылучы милли-буржуаз оешмаларның чын йөзен бик үткен һәм уңышлы фаш итеп килә.

Бездә татар халкының алдынгы өлеше, аның демократик вәкилләре «Новая жизнь» газетасы белән яхшы таныш булуы турында сөйләүче фактлар бар. Уральскида, мәсәлән, татар газеталарының нәширләре һәм сотрудниклары, һәм шул исәптән Г. Тукай да, 1905 елда «Новая жизнь»ны үзләре алганнар. Алай гына да түгел, алар хәтта ул газетадагы материалларның кайберләрен русча чыга торган үз газеталарына да күчереп басканнар.

Ленин идеяләренең һәм большевистик пропаганданың киң халык массаларына тәэсир көче, нәтиҗәләлелеге бу очракта да бик ачык күренеп тора.

Илебездәге төрле милләт хезмәт ияләре арасында сыйнфый бердәмлек булдыру, аларны халыклар дуслыгы рухында тәрбияләү буенча Коммунистлар партиясе туктаусыз рәвештә титаник эш алып барды. Бу җәһәттән «Правда» газетасының бик зур эш башкаруы мәгълүм. Ул массаларга партиянең милли мәсьәлә буенча программасын аңлатып килә, контрреволюционерларның «милли-культура автономиясе» дигән лозунгларының асылын фаш итә. В. И. Ленин инициативасы һәм Үзәк Комитет күрсәтмәсе буенча, газета изелгән милләтләр, шул исәптән татарлар тормышы турында да «Өлкә кушымталары» исемле махсус битләр чыгарып килә. «Правда»да Казан большевикларыннан В. Журавлев, Г. Сәйфетдинов һ. б. мәкаләләрен бастыралар.

Төрле шәһәр архивларына таралган документларның начар сакланган булуы, «Әлислах», «Уралец», «Уральский дневник» газеталарының һәм «Яшен», «Ялт-Йолт» һ. б. журналларның тулы комплекты юклыгы, цензор экземплярларының да тулысынча сакланмавы тикшеренүне кыенлаштыра. Тукай үзе җитәкчелек иткән яки ул актив язышкан матбугат органнарының архивлары да табылмаган әле. Шагыйрьнең матбугатка чыкмаган кульязмаларын эзләргә кирәк. Тукайның чит илләге «Мөселман» редакциясенә җибәргән әсәрләрен эзләү дә тикшеренүчеләр бурычы булып тора. Шагыйрьнең шушы көнгә кадәр кайбер псевдонимнары бөтенләй ачыкланмаган, ачыкланганнарының да кайберләре бәхәсле. Ихтимал, кайбер нәрсәләр мәңгелеккә югалганлыр инде. Ләкин, шулай да, барысы да югалып бетмәгәннәр әле.

Чыганаклар турында без шуңа болай күп сөйләдек, чөнки Тукай иҗатын һәрьяклап һәм тулысынча өйрәнү, аның әсәрләрен анализлау архив материалларына да нигезләнеп эшләгәндә генә мөмкин дигән фикерне ассызыклап әйтәсебез килде. Тукай эпохасын, аның иҗатын бары тик шул чакта гына тирәнрәк аңларга була.

---

[1] Фактларны И. Д. Кузнецов тарафыннан әзерләнеп бастырылган «Беренче рус революциясе чорында милли хәрәкәт (Полиция Департаменты архивыннан алынган документлар җыентыгы)» исемле китаптан алдым. Чувашия дәүләт нәшрияты, Чабаксар, 1935 ел, 239, 259—260 битләр, рус телендә.

[2] С. Кәримованың «Рабочий» газетасы массалар өчен көрәштә» (Казан, 1957, рус телендә) исемле зур булмаган махсус тикшеренүе бу өлкәдә әлегә бердәнбер хезмәт, ә бит массаларның политик аңын үстерүдә революциягә кадәр урыннарда чыккан вакытлы матбугатның ролен тикшерү белән җитди шөгыльләнә башларга бик вакыт инде.

Әдәбият белгечләренең әлеге шул тикшеренү чыганаклары тар булу аркасында килеп чыккан ялгыш һәм төгәл булмаган раслауларын бүген очратырга мөмкин әле.

* * *

Габдулла Тукай 1905 елны ирек кояшы чыгу дип кабул итә һәм аннан соңгы елларда да шул фикереннән кайтмый. Беренче рус революциясе аның өчен гасырларга тиң[1] вакыйга була.

Язучы, җәмәгать эшлеклесе буларак, Тукай халыкның күңеленнән көч ала. 1907 елдан соң «Халык зур ул, көчле ул, дәртле ул, моңлы ул, әдип ул, шагыйрь ул» дип, бары тик бөек оптимист кына әйтергә мөмкин.

Тукай дин әһелләренең барлык кешеләрнең дә язмышы алдан хәл ителеп куелган дип өйрәтүенә, фатализмга кискен рәвештә каршы чыга һәм үз фикерләрен башкаларга да ирештерергә тырыша. Халык җырларында шактый еш очрый торган «язмыш», «алла», «ислам» кебек сүзләрнең чын халык сүзләре булмавын (алар бик борынгы заман халык җырларында очрамый), бәлки ислам дине белән килеп керүләрен ачык, аңларлык итеп әйтеп бирә. Шагыйрь чын халык рухын туп та җимерә алмый, ук та тишә алмый торган халык җырларында күрә. («Халык әдәбияты» исемле мәкалә.)

«Халык әдәбияты» дигән мәкалә безгә Г. Тукай иҗатын туендырып торган ике чыганакны ачып бирә: аның берсе татар халкы, аның тормышы, рухы, сәнгате булса, икенчесе — шагыйрь яшәгән чынбарлык, бигрәк тә, 1905 елгы революция тәэсире.

Шагыйрь, интернационализм идеяләрен яклап, великодержавный шовинизмга, татар милләтчеләренә кыю рәвештә каршы чыга. Җыен юк-бар нәрсәләр бастырып ятучы милләтчеләрне тиләләр йортына озатырга тәкъдим итә ул. («Узган ел хисабы».) Революцион демократ Г. Тукай XX гасырда ирек кояшы чыгачагына ышанган зур оптимист була.

Меңнәрчә талантларны буып торган Россия атмосферасында да Тукай үзе теләгән заманны якынайту өчен тырышты. Бәрәңге һәм икмәккә дә туймаган, ә кайчакта хәтта бер сынык икмәк өчен дә тилмереп йөргән йөз меңнәр һәм миллионнар исеменнән сөйләп, шагыйрь царизмның һәм капитализмның кешеләрне гарипләндереп, йотып торуын иҗатында бик ачык чагылдырды.

Россиядәге шул социаль гариплекләрне һәм яман шешләрне үз каләме белән бик оста итеп сурәтләве арта бару белән бер үк вакытта, Тукайның яшәп килгән стройга каршы революцион хәрәкәткә чакыруы да көчәя бара.

«Кибән чалма, кибәк баш»лы ишаннар, шымчы һәм доносчы ахуннар, ислам динен жандарм кылычы белән таратучы икейөзле, кәбестә башлы, гел артка гына караучы муллалар; милләт бетә дип аһ оручы милләтчеләр; карак, жулик, комсыз татар байлары; меньшевик-карагруһчы бүреләр; уңнар арасында да иң уңы булган Гучковлар; карбыз башлы Пуришкевич һәм К° — гади эшче халык муенына атланган, кешегә охшаш бу хайваннарның бөтен династиясе себерелеп түгелергә тиеш. Шагыйрь менә шуңа чакырды.

Ил эчендәге гаделсезлекләргә каршы барган көрәш Тукайны халыкара империалистларга каршы да юнәлтмичә кала алмады.

Герман империализмының якын Көнчыгыштагы мәкерле эшләрен дә Тукай күп мәртәбәләр фаш итте. 1911 елны, төрек-итальян сугышы уңае белән, Вильгельм үзен мөселман Көнчыгышы мәнфәгатьләрен яклаучы дип белдергән иде. Вильгельм «хәлфә»гә ышаныч белдереп, төрекләр алдандылар, ул ялганчы булып чыкты диде Тукай һәм ерткыч империалистларның икейөзлелегеннән көлде. («Ялт-Йолт» редакциясенә сораулар.)

Мароккода ике империалистик группа интереслары бәрелешүдән туган куркыныч хәлләргә бәя биреп, шагыйрь «Франс» һәм «Герман» исемле ике этнең бу юлы сөякне сугышсыз гына бүлешә алуларын әйтә. («Узган ел отчеты»[2].)

«Ялт-Йолт» журналының бер санында шундый рәсем бар: чит илләрдәге кырылыш-талаш турында кычкырынырга яратучы Сэм агайның үз борыны төбендә бер негрны кыйнап яталар[3]. Бу рәсем шундый дөрес һәм бүгенге көн белән шундый аваздаш, әйтерсең, ул әле яңа гына ясалган.

Балкан сугышлары вакытында төрекләрнең сугыш башында ук Черногория чигендәге ныгытмаларын ташлап качуын ша-

---

[1] Г. Тукай. Сайланма әсәрләр, II том. Казан, 1961 ел, 84 бит, рус телендә.

[2] Тукайның бу чагыштыруы империалистларны төрле җанварлар рәвешендә сурәтләгән «Мулла Насретдин» исемле әзербәйҗан журналы рәсемнәре белән аваздаш.

[3] «Ялт-Йолт», № 8, 1910, 4 бит.

гыйрь: «Төрекләр белми эшләмәс; төрекләр — искедән сугышчан халык», дип, төрекләрнең кабат һөҗүмгә күчүләрен көтеп, хыялланып яткан пантюркистларны һәм панисламистларны да бик ачы көлеп фаш итә («Тегеннән-шуннан»). Хезмәт ияләре исәбенә һәм аларга каршы алып барылган талау сугышларына Тукай җаны-тәне белән каршы була.

Тукайның һәм башка т-гар революцион демократларының панисламистларга һәм пантюркистларга каршы көрәше интернациональ әһәмияткә ия һәм ул көрәш халыкара реакцион көчләргә каршы юнәлтелгән иде. Аларның миллилеге империализмга һәм нәсел-нәсәпсез космополитизмга капма-каршы булган патриотик миллилек иде. Халыклар дуслыгы, үз Ватаны — Россиягә һәм бөтен дөнья халыкларына мәхәббәт идеяләре халык шагыйре Тукай һәм аның каләмдәшләре иҗатында бик ачык үткәрелә.

Дингә каршы көрәш—шулай ук Октябрьгә кадәр татар демократик әдәбиятының кыйммәтле сыйфатларыннан берсе булып тора.

Бу идеяләр, бу юнәлешләр гомум әдәбият агымында югалып калмады. Октябрьгә кадәрге татар әдәбиятында, сан ягыннан революцион-демократик әдәбияттан артыграк булса да, буржуаз әдәбият өстенлек алып тормады. Өстенлек милләтнең үз «аталарына», ягъни милләтчелек идеологларына, хакимлек итүче Пуришкевичлар-Гучковлар-Струвелар культурасына каршы көрәштә революцион-демократик юнәлештә торган әдәбият ягында иде.

* * *

Татар иҗтимагый фикере үсеше тарихында үзенә аерым урын тоткан «Яшен» һәм «Ялт-Йолт» кебек прогрессив журналлар редакциясендә Г. Тукайның, политик, дипломат, җәмәгать эшлеклесе буларак, эшчәнлеге бик төрле. Бу журналлар Г. Тукай һәм Г. Камалларның турыдан-туры катнашы белән оештырыла. 1910 елда «Ялт-Йолт» редакциясе каршында татар язучыларының һәм шагыйрьләренең иң алдынгыларын берләштергән әдәби иҗат группасы барлыкка килә. Әйтик, журналда, Г. Тукайдан һәм Г. Камалдан тыш, Фатих Әмирхан, Галимҗан Ибраһимов, Ф. Сәйфи, Кәбир Бәкер, Т. Мирвәлиев һ. б. актив эшли. Әлеге журналлар берничә еллар буена (әгәр «Яшен»нең 1908 елда чыгарыла башлавын искә алсак, бик авыр еллар буена) өзлексез рәвештә мөселман руханиларына, татар милләтчеләренә, панисламизмга һәм шовинизмга каршы көрәш алып баралар, царизмның, АКШның, Англиянең, Германиянең, Франциянең империалистик политикасын фаш итеп торалар.

XX гасыр башында татар революцион демократларының тәҗрибәсе, алар көрәшенең төрле форма һәм алымнары җирдә колониализм калдыкларын бетерү өчен көрәшүчеләргә билгеле бер дәрәҗәдә бүген дә кызыклы әле, безнеңчә. Империалистларны фаш итү исә безнең көннәрдә дә актуальлеген югалтмаган.

Төрек агентларының һәм Төркиягә качкан А. Р. Ибраһимов һәм Й. Акчураларны Россиягә панисламизм һәм пантюркизм идеяләрен алып керергә тырышуына каршы «Ялт-Йолт» журналы системалы чыгыш ясап килә. Шул ук вакытта редакция патша дәүләтенең Россия халыклары арасында дошманлык кабызуына каршы да көрәшә.

Патша адвокатларын журнал күп мәртәбәләр принципиаль тәнкыйтькә дучар итә. Ләкин патша цензурасы үзенең ярдәмчеләрен йолып кала. «Ялт-Йолт» журналының 1911 елгы егерме тугызынчы санында, мәсәлән, уникенче бит тулысынча кызыл карандаш белән сызылган, ундүртенче битнең яртысы нокталар белән тутырылган, ә унбишенче бит бөтенләй буш. «Ялт-Йолт»ның бу һәм моннан соңгы утызынчы санында редакция «Канатлы сүзләр» һәм «Хәбәрләрнең кызыгы» исемле мәкаләләрендә Столыпинга, реакцион дума депутатларына һәм Ходжетлаше провокаторның уң кулы булган Датиевка каршы чыккан булган[1].

Татар демократларын куралмавы турында Датиев «Мөселман интеллигенциясендә ике агым», «Социалист хөкеме алдында шәрык вә мөселманлык» исемле мәкаләләрендә язып чыга. Демократик рухтагы төрле милләт интеллигенциясенең үзара берләшә баруын күреп, революциядән куркуыннан һәм ачуыннан калтырап, ул кабахәт субъект: «Барыгыз, ләкин Маркс «Капиталы» белән түгел, ә, барыннан да элек, Коръән һәм шәригать белән; партия лозунг-

---

[1] «Ялт-Йолт», 1911 ел, 13 декабрь, 3 бит. «Редакциягә бәйле булмаган хәлләр аркасында» журналның 1910 елгы беренче дүрт саны соңгарып чыга. «Ялт-Йолт», № 33, 1912 ел, 15 февраль, 4—5 битләр.

лары белән түгел, ә гомум-кешелек идеяләре белән», — дип язды [1].

«Ялт-Йолт»та эшләгән язучылар марксист булмыйлар, ләкин алар марксизмга уңай карашта торалар, хезмәт ияләре белән тыгыз бәйләнеш тоталар һәм үз идеалларын, бурычларын шунда күрәләр.

Провокатор Датиев үз язмаларында, бер үк вакытта акыл да өйрәтеп, ачуланып та, А. М. Горький белән полемикага керергә омтыла. Димәк, «Ялт-Йолт» редакциясе әнә шундый провокаторчылык һәм карагруһчылык пычрагыннан саклануы белән, бөек пролетар язучысы белән дә һәм бөтен Россиядәге чын революцион агым белән дә теләктәш булуын белдергән.

Татар революцион демократлары системалы рәвештә буржуаз милләтчелеккә каршы көрәш алып баралар. Казанда яки Оренбургтамы, Астраханьда яки Томскидамы, Чиләбедә яки Кустанайдамы, Бакуда яки Троицкидамы, кыскасы — татар буржуазиясе идеологлары кайда гына чыгыш ясасалар да, «Ялт-Йолт» аларның берсен дә игътибарсыз калдырмады. Һәм менә бу хәл Казан журналы эшчәнлегенең, Тукай эшчәнлегенең тагын бер мөһим моменты. Бөтен Россиягә таралуын (ә ул, подпискадан тыш, түләүсез рәвештә барлык «мөселман» җәмәгать китапханә-уку залларына җибәрелеп торган) искә алсак, Россия халыклары арасында дуслык идеяләрен пропагандалауда аның роле шактый булды дип әйтергә мөмкин. Журнал самодержавиегә, урта гасыр калдыкларына каршы гына түгел, капиталистик мөнәсәбәтләргә каршы да көрәшә. «Ялт-Йолт»ның 1912 елгы 32 санында (4 бит) редакция исеменнән татар эшчеләренең «үз» татар фабрикантлары Дибердиевларны да дөмбәсли башлавы әйтелгән.

* * *

Беренче рус революциясе чорында барлыкка килгән татар революцион демократиясе 1905 елгы революция байрагын реакция елларында да төшермәде. Ул һәртөрле милли чикләнгәнлеккә һәм бикләнгәнлеккә каршы иде. Татар революцион демократиясе, Россиянең бөтен халыклары революцион демократиясе кебек үк, иркле халыкларның бердәм Россиясе, ул халыкларның үзара дуслыгы өчен тырышты. Патриотизм рухы, империализмга нәфрәт — татар революцион демократиясенең иң әйбәт сыйфатларыннан берсе булды. Һәм ул барлык демократик көчләрне берләштерүнең кайбер конкрет формаларын да эшләп чыгара алды (дәүләт башкаласында рус телендә басылган «Мөселман газетасы»нда сотрудниклык итү, күп милләтле бердәм театр коллективлары оештыру). Татар демократиясенең иң яхшы вәкилләре рус революцион демократлары байрагын күтәрделәр һәм алар көрәшен яңа тарихи шартларда дәвам иттеләр. Демократик культура вәкилләре бу көрәштә социалистик культура вәкилләре белән тыгыз элемтәдә торып эш алып бардылар.

Татар революцион демократлары хезмәт ияләрен социалистик җәмгыять урнаштыру өчен революцион көрәшкә чакырды, һәртөрле юллар белән социал-демократиягә ярдәм итәргә тырышты: брошюралар, листовкалар, прокламацияләрне тәрҗемә итте, үз матбугаты битләрендә большевиклар чыгышына зур урын биреп килде.

Большевиклар революцион демократиянең ролен һәм әһәмиятен тиешенчә бәяләделәр. Революцион социал-демократия революцион демократларны эзлекле булмаулары, вак буржуаз-народниклык иллюзияләренә бирелеп китүләре өчен тәнкыйтьләп һәм шул ук вакытта аларга самодержавиегә һәм буржуаз милләтчелеккә каршы көрәштә һәртөрле юллар белән булышлык та күрсәтеп торды, рухи яктан үсәргә ярдәм итте. Зур каршылыклар белән булса да, фәнни социализмны аңлауга таба хәрәкәт итүче татар революцион демократларының царизмга, татар буржуазиясе идеологларына каршы көрәштә дә шактый өлеш керткәнлеген билгеләп үтәргә кирәк.

Октябрь революциясенә кадәрге рус культурасына башка халыклар культурасы да кушылып, үзләреннән өлеш кертә килделәр. Революцион демократлар рус булмаган халыклар арасында да бар иде. (М. Налбандян, М. Ф. Ахундов, Г. Тукай һ. б.) 1905 елдан соң, илнең барлык халыкларының демократик һәм социалистик культура элементлары сыйфатында, гомуми культура хәзинәсенә «чит халыклар» керткән өлеш аеруча нык сизелә башлады.

Россия халыклары үсешенә беренче рус революциясенең тәэсире күпьяклы булды һәм ул тәэсир милләтләр һәм халыкларның үз эчендә сыйнфый каршылыкларның өлгерүен тизләтте, төрле милләт эшчеләрен берләштерү җирлегендә, алар арасында революцион идеологиянең үсүенә ярдәм итте.

---

[1] «Мөселманнар дөньясында». № 30 11(24) ноябрь, 1911 ел; № 32, 25 ноябрь (8 декабрь) 1911 ел.

Мәкаләдә куелган тема рамкаларыннан бераз читләшсәк тә, безнеңчә, бу аклана: татар вакытлы матбугатын белмичә торып, Тукай турында язарга мөмкин түгел, чөнки Габдулла Тукай һәм татар әдәбияты — аерылгысыз.

* * *

Инде, сүзгә йомгак ясап, И. Нуруллинның «Казан утлары» журналының өченче санында (120—127 битләр) фикер алышу тәртибендә басылып чыккан «Шагыйрьне өйрәнү юлында» исемле мәкаләсенә тукталып үтәсе килә.

И. Нуруллин кулланган полемика алымнары турында берничә сүз: фәнни тәнкыйтьтә үз фикерләренне генә түгел, бәлки аппонент фикерләрен дә төгәл күрсәтергә кирәклеге һәркемгә билгеле нәрсә. Менә шул шарт үтәлмәгән И. Нуруллин мәкаләсендә. Әйтик, минем китаптагы Тукай Уральскида чакта русча житәрлек, иркен белгән дигән урыннан цитата китерә ул. И. Нуруллин Тукайның Г. Шәрәф истәлегендәге «минем русчам Уральскидан килгәндә зәгыйфь иде», дигән сүзләренә мөрәҗәгать итә дә сорый: «Кайсына ышанырга? Минемчә, соңгысына. Чөнки, — дип дәвам итә ул, — беренчедән, бу сүзләрне эченә алган истәлек Тукай үлеп бер ел үткәч дөньяга чыккан — ялгышырга әле мөмкин түгел; икенчедән, авторы теләсә дә, фактны бозып күрсәтә алмас иде — шаһитләр күп».

Аннары, минем хезмәткә мөрәҗәгать итеп, И. Нуруллин мине тиешле дәлилләр китермәгән дип гаепли.

И. Нуруллинның минем хезмәт турындагы фикерләренә пунктлары буенча җавап бирәм. Беренчедән, мин Г. Тукайның рус телен ни дәрәҗәдә тирән белүен күрсәтүне максат итеп куймадым. Чөнки, сүз уңаенда гына әйткәндә, бу тема инде күптән башка галимнәр тарафыннан өйрәнелгән һәм Г. Тукайның Уральскида яшәгән чорда рус телен житәрлек яхшы белгәнлеген дәлилләүче квалификацияле фикерләр дә бар [1].

И. Нуруллинга Г. Шәрәф истәлеген дә игътибар беләнрәк укырга кирәк булган. Ул цитаталар алган «Тукай турында замандашлары» (Казан, 1961) исемле китапның 99 битендә Г. Тукайның Г. Шәрәф белән Пушкин, Лермонтов шигырьләре, Белинский тәнкыйте турында сәгатькә якын әңгәмә алып барганлыгы әйтелгән. Әгәр бөек рус шагыйрьләре иҗатын һәм «ярсу Виссарион» мәкаләләрен белмәгән булса, Тукай әлеге шактый катлаулы тема буенча ничек әңгәмә ясый алган булыр иде икән, дип сорыйсы килә. Ул чакта әлеге язучыларның әсәрләре татарчага тәрҗемә ителмәгән бит, Тукай аларны бары тик русча укып кына белә алган. Рус әдәбияты классикларын уку, аларны татарчага тәрҗемә итү һәм алар турында квалификацияле сөйләшү алып бару өчен, рус телен шактый яхшы белергә кирәк.

Г. Шәрәфнең бу мәсьәләдә фикере каршылыклы икәнлеге күренеп тора. Димәк, халык шагыйре тормышының бик мөһим ягы турында, И. Нуруллин мәкаләсендәгечә, Г. Шәрәф әйткән сүзләр генә берләнбер шаһит була алмый. Икенчедән, әгәр И. Нуруллин чыннан да тикшеренүдә фәнни методлар өчен тырыша икән, ул Г. Шәрәфнеке белән бер үк вакытта чыккан икенче истәлекнең дә булуын һәм анда Г. Тукайның рус телен шул тикле яхшы белүе, хәтта мәдрәсәнең өлкән классларында укучы шәкертләрне дә русчага өйрәтүе турында сүз баруын, әлбәттә, әйтергә тиеш иде. Бу турыда шагыйрьнең иң якын дусларыннан берсе, аның белән бергә Уральскида яшәгән кеше — Габдулла Кариев язган.

Тукай замандашы язган бу дөрес факт әдәбият белгеченә, һич югында, башка авторлар (әйтик, М. Гали) аша булса да билгеле булырга тиеш иде.

Өченчедән, типографиядә бергә эшләгән кеше сөйләве буенча, Тукайның «Уралец» газетасында русча бер-ике шигырь (бары тик!) бастырып чыгарган булуы турында әйтсәм дә, минем китабымның 273 битендә мондый искәрмә бирелгән: «Уралец» һәм «Урал көндәлеге» газеталарының барлык саннары илнең бер генә китапханәсендә дә юк, шунлыктан без бу фактның дөреслеген әле раслый алмадык». Димәк, мәсьәлә минем тарафтан ачык калдырылып, аны киләчәктә тикшерү бурычы гына куелган. Фән куәлегеннән карaганда, яңа тема һәм проблемаларны алга кую дөрес түгелмени?

Белмим, И. Нуруллин моны ничек кире кага алыр икән. Лакин нигә сон ана ми-

---

[1] Карагыз: Габдулла Тукай. Шагыйрьнең туууына алтмыш ел тулуга багышланган фәнни сессия материаллары. Таттосиздат, Казан, 1948. Х. Хисмәтуллинның «Тукайның рус әдәбиятыннан тәрҗемәләре» исемле мәкаләсе (113—114 битләр), М. Галинең «Тукайның Уральскидагы тормышы» исемле мәкаләсе (179—180 битләр). Р. Башкуров. Тукай һәм рус әдәбияты. ТКИ. Казан, 1958. 8—9, 35 битләр.

нем китаптагы искәрмә турында дәшми үтү кирәк булган? «Тәнкыйть» ыграк булсын өченме? Ул моңа ирешкән: тәнкыйть бик кискен чыккан.

Ә аның «истәлек Тукай үлеп бер ел үткәч дөньяга чыккан — ялгышырга әле мөмкин түгел» дип раславына килгәндә исә, бу ышанычны И. Нуруллинның үзенә калдырыйк. Теләгән кеше фактларны шаһитләр алдында боза ала. Тарихта андый хәлләр житәрлек.

И. Нуруллин кулланган «дәлилләү» алымнарының тагын берсенә тукталып үтик.

Ул, «шагыйрьнең ул еллардагы дөньяга карашын башлыча аның оригиналь әсәрләреннән чыгып» билгеләргә кирәк дигән фикердән чыгып, нигәдер «Сугыш һәм Государственная дума» исемле тәржемәсе буенча Тукайның карашларына мин биргән бәяне кире кага. Шунысы аңлашылмый: шагыйрьнең карашлары үсүе һәм киңәюе турында И. Нуруллинның тәржемәләрдән чыгып (ул «Мужик йокысы»на — Кольцев шигыренең тәржемәсенә мөрәжәгать итә) хөкем йөртергә хакы бар, ә икенче авторның хакы юк икән. Кая соң монда логика?

Бәлки, И. Нуруллин моңа каршы: «Тукай Кольцев шигыренә үзеннән юллар өстәп язган», дияр. Әйе, ләкин үз китабымда миндә, конкрет фактлар белән, «Сугыш һәм Государственная дума» брошюрасын тәржемә иткәндә Г. Тукай үзеннән күп кенә өстәмәләр, төзәтүләр керткән, алай гына да түгел, хәтта «Сугышның бер елы» исемле большевистик брошюра текстын да файдаланган (минем китапның 307 бите) дип исбатлыйм лабаса!

И. Нуруллин үзенең Тукайга мәхәббәте зур булуын әйтә һәм шул вакытта дөреслек барыннан да югары булырга тиеш дип белдерә. Тукайга мәхәббәт белән дөреслеккә мәхәббәтне шулай каршы куеп карауның хажәте юк (алар икесе бергә булырга тиеш).

Ә мәкаләдә эш ничек тора соң? Анда фәнни бәхәстә кулланылмый торган «чебенне фил итү», «ә филне абайламый узу» кебек чагыштырулар тонында һәм стилендә язылган төрле гаепләр китерелә.

Әмма хикмәт И. Нуруллин бик мул кулланган фельетон сүзләрендә түгел. Алар артыннан тагын минем китаптан алынган цитаталар китә:

«Цензорлар тарафыннан тәкъдим ителгән статья һәм пунктлар буенча Тукайга күп еллар буе төрмәдә утырырга туры килер иде... Казан цензорларының аның исеме тирәсендә казынулары ана билгеле иде: ул күп мәртәбәләр Казаннан ерак авылларга һәм шәһәрләргә китеп, адресын белдермичә яшәде».

Үз фикерен минем китаптагы: «Патша палачларының казынулары эзсез калмады, алар шагыйрьнең сәламәтлегендә һәм иҗатында чагылдылар»[1], — дигән нәтиҗә белән тәмамлыйсы урында, И. Нуруллин һич көтмәгән нәтиҗә ясый:

«Әйе, цензорлар карыйлар, зарарлы фикерләр табалар һәм тәкъдимнәрен жандарм идарәсенә жибәрәләр. Тукайга карата нинди чара күрелә соң? Бернинди дә чара күрелми, мәсьәлә үзеннән-үзе сүнә», — ди ул. Һәм аннары: «Тукай хәтта полиция күзәтүе астында да тормаган», — дип өсти[2].

И. Нуруллин, асылда, нәрсәдән канәгать түгел соң? Г. Тукайны Казан цензорлары эзәрлекләү турындагы мин китергән архив материалларыннанмы? Ләкин бу факт бит.

Цензура комитеты Тукайның һәр шигырь җыентыгын, һәр мәкаләсен исәпкә алып бара һәм, үз чиратында, бик төгәл рәвештә шул турыда губерна жандарм идарәсенә хәбәр итеп тора. Тукайның Казанда яшәгән һәм иҗат иткән чорда чыккан китапларының, ихтимал, берсе дә арест салынмыйча, аларның авторы уголовный җаваплылыкка тартылмыйча калган очрак булмагандыр[3].

Шуңлыктан Тукайның үз әсәрләрен яшерен рәвештә яисә чит ил нәшриятларында бастырырга теләве бик законлы хәл: күп нәрсәсен ул гомумән бастыра да алмый бит. 1910 елның 4 декабрендә шагыйрь Сәгыйт Сүнчәләйгә язган хатында Тукай аңа кайбер кискенрәк, «монда басылмаслык» әйберләрен Парижда басыла торган «Мөселман» журналына жибәрергә ниятләве турында яза.

Һәм, жандарм идарәсе соравы буенча, цензура комитеты биргән доносны суд палатасы раслаган булса, шагыйрьгә уннарча ел төрмәдә утырырга туры килгән булыр иде. Әйтергә кирәк, И. Нуруллин хәтта провокатор «Перс» (Абдулла Галиев) турындагы документларның безнең тарафтан табылган булуын да күрсәтеп китмәгән.

---

[1] Минем китапның И. Нуруллин цитата алган 62 бите.

[2] «Казан утлары» журналы, № 3, 1966 ел, 126 бит.

[3] ТАССР, УДА. Ф. 420, д. 172, л. 15, л. 17, л. 25; д. 179, Л. 143—145; д. 180, Л. 57.

Өстәп әйтәм, бу Тукайга бердәнбер донос түгел. Тукайга төрле гаепләр белдереп, Казан губернаторы да югары инстанцияләргә язган [1], матбугат эшләре буенча Баш идарә дә Тукай хрестоматиясе турында үз начальникларына җиткергән [2]. Тукай актив язышкан «Ялт-Йолт» журналының оппозицион [3] юнәлештә булуы хәбәр ителә. Цензура комитетының Тукайны эзәрлекләве 1911 елның ноябреннан 1912 елның апреленә кадәр дәвам итә [4].

Казан губерна жандарм идарәсе начальнигы таләбе буенча, 1909 елның 13 ноябрендә, «Әлислах» газетасы редакторы буларак, Тукайның иптәше В. Бәхтияров полициянен яшерен күзәтүе астына алына һәм бу күзәтү 1914 елга кадәр дәвам иттерелә [5].

Тукайның дусты Ф. Әмирхан артыннан 1912 елдан күзәтү алып барыла. Губернатор да, жандарм идарәсе начальнигы да аны күзәтүнең барышы турында рухани эшләр Департаментына хәбәр итеп торалар, бу пычрак эштә аларга провокаторлар да ярдәм итә. Губернаторның белдерүенә караганда, 1912 елның 13 ноябрендә Фатих Әмирхан һәм Әхмәтгәрәй Хәсәнов квартираларында көтмәгәндә ясалган тентү нәтиҗәсендә агентураларның «Әмирханов һәм Хәсәнов турындагы күрсәтмәләре хак булуын раслаучы әйберләр» табылмаган, ләкин «бик җентекле яшерен күзәтү» куелган. Аларны, имеш, бик нык конспирацияләнгән булганлыктан фаш итеп булмый дип, нәфрәтләнеп яза губернатор [6].

Шушындый фактларны ачканнан соң Тукай артыннан да күзәтү булуына шикләнергә мөмкинме соң? Архив документларыннан күренгәнчә, власть органнары үзләре күзәтүе астына эләккән бөтен кешеләрнең дә танышларын һәм дусларын күзәтеп торганнар. Монда бернинди дә идеаллаштыру һәм арттыру юк.

Саратов өлкә дәүләт архивы (СӨДА) фондында Казан жандарм идарәсе начальнигының Казан революционерлары һәм андагы төрле түгәрәкләр турында, «бик яшерен» дигән тамга салып, 1912 елның 31 июлендә Саратов шәһәр жандарм идарәсе начальнигына җибәргән документлар бар. Шул документларның берсеннән өзек китерик:

«26 июльдә Евангелистлар урамында, Хәсәновлар йортында, татар әдәбият түгәрәге (719, 876 һәм 997 номерлы 1911 елгы күчермәне карагыз) җыелды. Җыелыш якын киләчәктә калын рус журналлары кыләмендә әдәби-политик журнал чыгара башларга карар кылды. Бу журнал яшь татарларны берләштерү чарасы да булырга тиеш... Җыелышта бу мәсьәлә буенча катнаштылар: бертуган Барый һәм Гәрәй Хәсәновлар..., Габдулла Тукаев, Фатих Әмирханов, укытучы Гафур Колахметов...» [7]

«Урында кулланылган чаралар» дигән графада Казан жандарм идарәсендә болай дип язылган: «Монда исемнәре аталган кешеләрнең кайберләре Идарәгә үзләренең элекке политик эшчәнлекләре буенча билгеле. Алар артыннан күзәтү дәвам итә» [8].

Димәк, Г. Тукай артыннан полиция генә түгел, бәлки жандармерия (Казан жандармериясе генә түгел) дә, ким дигәндә, 1911 елдан күзәткән дигән фактны раслаучы документ бар. Ә мондый документ табылмаган булса, Тукай яшерен күзәтү астында булган дип уйларга мөмкин булмас идемени? Мөмкин иде һәм тиеш иде! Моның өчен Тукай яшәгән эпоханы ачык итеп күз алдына китерергә генә кирәк. Шагыйрь буларак, «дипломат, политик, общественный деятель» буларак, аның артыннан күзәтми булдыра алмыйлар. Тукай үз исталегенә платоник мәхәббәткә мохтаҗ шәхес түгел. Әгәр инде аның турында язарга тотынасың икән, ул чакта аның ничек итеп патша тираниясе вакытында да цензура кулы астындагы матбугат битләре аша үз идеяләрен үткәрә, үз идеалларын яклый алуын күрсәтергә кирәк.

Безнең И. Нуруллин белән бәхәсебез бу очракта принципиаль. Эш, хөрмәтле тәнкыйтьче күрсәтергә теләгәнчә, минем Тукайны матурларга тырышуымда түгел. Хәер, милли-азатлык хәрәкәте эшлеклесен патша власте эзәрлекләве турында язганда нинди матурлау булырга мөмкин соң? Һәм теге яки бу тикшерүче теләкләренең һәм омтылышларының ни катнашы бар монда.

И. Нуруллин белән минем фикер аермасының асылы — тарихи процесста шәхес ро-

---

[1] Ленинград Үзәк дәүләт тарих архивы. Ф. 821, Оп. 133, д. 472, л. 125.
[2] Шунда ук, д. 451, л. 8, л. 35.
[3] Шунда ук, ф. 776, оп. 31, д. 91, л. 49.
[4] Шунда ук, ф. 776, оп. 21, д. 260, л. 2—3, 9.
[5] ТАССР ҮД архивы, ф. 1, д. 5809, лл. 41, 73, 76, 82, 84.
[6] ЛҮДТА, ф. 821, оп. 133, д. 587, л. 75.
[7] СӨДА, ф. 51, оп. 1, д. 44, 1912, л. 59 оп. (Бу документны Саратов өлкә дәүләт архивыннан аспирант Р. Гарәфетдинов тапты).
[8] СӨДА, л. 60.

лен төрлечә аңлавыбызда, тикшеренү методларыбызның төрле булуында.

Әлбәттә, халык шагыйренең иҗатын өйрәнгәндә без аның әсәрләренә таянабыз. Менә шул чакта, табигый рәвештә, Тукайның монархы билгеле булмаган яисә патша вакытында матбугатка тулысынча чыга алмаган, цензура тарафыннан кыскартылган хезмәтләренең тулы вариантын табарга тырышу уе туа. Бу хәл төрле архивлар фондларында озак еллар буена кыен эзләнүләр алып барырга мәҗбүр итә. Ә безгә исә: туктагыз, болай эшләүнең хаҗәте юк, безгә инде барысы да билгеле дип әйтмәкче булалар... И. Нуруллинның шушындый фикерләре белән һич тә килешә алмыйбыз.

И. Нуруллинга ныклап торып архив фондларын өйрәнергә керешү зыян итмәс иде һәм ул чакта Тукай биографиясен өйрәнү эше дә тизләшер, ялгышулар, буталышлар да азрак булыр иде.

Ләкин ансат кына: «Тукай хәтта полиция күзәтүе астында да тормаган» һ. б. дип әйтү бернигә дә ярый торган эш түгел, һәм монда, үзе никадәр генә тырышып әйтсә дә, И. Нуруллинның Тукайга мәхәббәте юк.

И. Нуруллинга без аның төп концепциясе буенча принципиаль каршы киләбез: тәнкыйтьче тарафыннан бозып сурәтләнгән Г. Тукай портреты белән һич тә килешәсебез килми. Аның сурәтләве буенча, күз алдына революцион демократ, царизмга һәм буржуаз милләтчеләргә каршы көрәшүче түгел, бәлки дини уйларга чумган елак бер кеше килеп баса. Сүз уңаенда әйткәндә, татар әдәбияты тарихы белән чынлап торып кызыксынган кеше Тукай турындагы бу фикерләрнең әле революциягә кадәр үк эсер Ф. Туктаров һәм шагыйрьне өнәмәүче башка кешеләр сөйләгәннәргә охшаш булуын күрми калмас.

Моңа, революциягә кадәрге чорда татарлар арасында җәмәгать фикере үсеш тарихын эшкәртүгә катнашы булган һәм шунлыктан И. Нуруллин эшләре белән таныш кешегә, Г. Тукайның дөньяга карашына бәя бирү мәсьәләсе буенча аның фикер эволюциясе гомумән аңлашылмый. 1953 елда яклаган кандидатлык диссертациясендә И. Нуруллин Тукай — революцион демократ дигән положениене исбатлаган иде. Аннан соңгы 50—60 еллардагы хезмәтләрендә дә, әлеге мәкаләсе чыкканга кадәр, шул әлекке фикерендә булып килгән иде.

Хәзер нәрсә үзгәрде соң? Тавышсызтынсыз гына һәм үз позициясен яңадан карап чыгарга, һәм үз фикерләрендә калган кешеләрне кычкырып гаепләргә И. Нуруллинны хәзер нинди фактлар мәҗбүр итте соң?

Андый фактлар юк һәм алар И. Нуруллинның әлеге мәкаләсендә дә күренми. Мәкаләдә бер генә яңа факт та юк. И. Нуруллинның XX гасырда революцион хәрәкәтнең роле турындагы теоретик яктан буталчык фикерләре аның абруен күтәрми.

Мәкаләнең башка «вак-төяк»ләренә тукталмыйм. Авторның безнең адреска ясаган замечаниеләре дә якынча шундый характерда. Анда И. Нуруллинның, архивны тиешенчә белмәвеннән бигрәк, үз фикерләренең бернинди дәлилсез, горур тонда булуы гаҗәпкә калдыра.

И. Нуруллинның Г. Тукай иҗатына бирелгән бәяләргә ревизия ясарга омтылуы, бигрәк тә, ул омтылышның әдәби журнал битләрендә һәм илнең милли горурлыгы булган шагыйрьнең юбилее көннәрендә булуы борчый һәм кызгану уята.

---

**СЕЗ ҮЗ ИСЕМЕГЕЗНЕҢ МӘГЪНӘСЕН БЕЛӘСЕЗМЕ?**

Мәрзия — яхшы дип табылган.
Мәсрүрә — шатлыклы, сөенечле.
Мәсхут — кабул ителмәгән.
Мәхдүмә — хөрмәткә лаек кеше.
Мәхмүт — макталган, мактаулы.
Мәхтүбә — ярәшелгән кыз.
Назыйм — тәртипкә салучы.
Мәһди — туры юлда булган кеше
Мөбарәк — кадерле, бәхетле.
Мөбин — дөреслек белән ялганны аеручы.
Надир — сирәк очрый торган.
Назыйр — мөдир, министр.
Наил — ирешә алучы.
Насыйр — ярдәм бирүче.
Насыйх — нәсихәт итүче, үгетләүче.
Насыйб — хезмәт урынына билгеләүче.
Нәфигъ — файда китерүче.
Наҗия — котылган, котылучы.
Низам — тәртип, кагыйдә.

# Сәнгать

## ХАЛКЫБЫЗНЫҢ ЧИГҮ СӘНГАТЕ

Чигү сәнгате татар хатын-кызларының бик борынгыдан килгән һәм киң таралган иҗат төре. Алар чиккән әйберләрнең матурлыгына, ул әйберләрдәге бизәкләрнең уңышлы сайланышына сокланмыйча мөмкин түгел. Чигүдә тормышның җанлы сулышы, бик күп төрле чәчәкләр һәм үсемлекләр белән капланган кырлар, болыннар матурлыгы тоелып тора.

Татар осталары чигү орнаментикасының нигезендә чәчәк-үсемлек мотивлары өстенлек итә. Әмма чигүнең кайбер төрләрендә (мәсәлән, алтын белән чигүдә) геометрик һәм зооморф (кошлар, бал кортлары һәм күбәләкләр рәсемнәре) мотивлары да очрый.

Тормыш-көнкүреш әйберләренең һәм йорт җиһазларының бик күп төре — өстәл җәймәләре, намазлыклар, битъяулык очлары (1 нче рәсем), тәрәзә кашагалары, савыт-саба япкычлары, урын-җир әйберләре, тастымаллар, кул һәм баш яулыклары, кияүгә дип әзерләнгән аяк чолгаулары, калфаклар, түбәтәйләр (3 нче рәсем) — чигү белән бизәлгән. Революциягә кадәр язылган хезмәтләргә караганда, XIX гасыр урталарына тикле хатын-кыз күлмәкләрен [1] һәм ирләр күлмәгенең кайтарма якаларын [2] да чикканнәр. Хатын-кыз күлмәкләренең гадәттә итәкләре, бәби итәкләре, ә кайчакта җиңнәре һәм изүләре дә чигелгән. Хатын-кыз алъяпкычларын һәм күлмәкләрен [3] матур итеп чигү дә гадәти хәл булган.

XIX гасырда фабрика-заводларда җитештерелгән бизәкле тукымалар (ситсы, сатин, кленкор, ефәк һ. б.) киң тарала һәм бу хәл чиккән күлмәк һәм алъяпкычларның кимүенә сәбәпче була, чөнки хәзер чигеп мәшәкатьләнүнең хаҗәте калмый.

Чиккән калфаклар, өрпәкләр, түбәтәйләр, читекләр, туфлиләр дә элек бик кадердә йөргән.


Чиккән әйберләрнең күбесе төрле йолалар белән бәйле булган. Әйтик, кәләшләр, булачак кияүләренең туганнарына бүләк итү өчен, кулъяулыклар һәм, үз кияүләренә бирер өчен, аяк чолгаулары чикканнәр. Сабан туена яшь киленнәрнең чиккән сөлге, житкән кызларның кульяулык бүләк итүләре дә — бик борыннан килә торган йола. Ул бүләкләрне ат чабышында, көрәштә, йөгерештә һәм башка төр ярышларда җинеп чыккан кешеләргә биргәннәр. Республикабызның күп кенә авылларында бу традиция

---

[1] Лепехин. Рус дәүләте провинцияләре буйлап сәяхәт турындагы көндәлекләр. Рус телендә. 4 кисәк. СПб., 1771—1895 еллар. И. Георги. Рус дәүләтендә яшәүче барлык халыклар турында язмалар. Рус телендә. СПб., 1799 ел, 12 бит.

[2] Н. И. Воробьев. Казан татарлары. Рус телендә. Казан, 1953 ел, 225 бит. Н. И. Воробьев мондый якаларның Минусия, Алтай төрекләрендә, башкортларда һәм казакъларда да киң таралган булуын әйтә (шунда ук). Якалары, изүләре, ә кайчакта җиңнәре дә чигелгән күлмәкләр башкортларда әле дә сакланган, Казан татарлары да, ихтимал, элек күлмәкләрен шулай чикканнәрдер (А. С. Авижанская, Н. В. Бикбулатов, Р. Г. Кучеев. Башкортларның бизәү сәнгате. Уфа, 1964, 81 бит.)

[3] Күлмәк, алъяпкыч, күкрәкчәләрне башкорт хатын-кызлары да чикканнәр. Ихтимал, алар моны XVII—XVIII гасырларда күчеп килгән татарлардан өйрәнгәннәрдер.



Хатын-кыз калфагы. XIX йөз уртасы.

әле дә дәвам итеп килә. Чиккән әйберләр (гадәттә, чиккән сөлге) мәет күмгәндә дә кулланылган: мәетне кабергә төшергән кешеләргә бирелгән алар. Бу йола да республикабызның кайбер районнарында хәзергә кадәр сакланып калган.

Татар чигү осталарына тамбурлап (күпертеп), тоташ итеп һәм келәм ысулы белән чигү алымнары хас[1]. Баш һәм аяк киемнәрен төрле төстәге пыяла сәйләнчекләр (бисер) белән бизәп чигү дә әлек шактый киң таралган күренеш. Бу чигү төрләренең барысы да материал тектоникасына (төзелешенә) бәйләнмәгән иркенле чигүгә кайтып кала. Бу төр чигүләрнең атлам аралары төрле озынлыкта һәм төрле юнәлештә була. Элекке заманда, алтын белән чигү (алтынны ябыштырып тегү) ысулы да шактый киң таралган булган.

Тамбурлап чигү ысулын куллана башлау бик борынгы заманнарга барып тоташа. Мондый чигү безнең эрага кадәрге беренче һәм бишенче гасырларда яшәгән Монголия һәм Алтай[2] халыкларында ук кулланылган.

Казан хатын-кызлары бизәкләрне төрле материалларга (киндер, сатин, ситсы, ефәк, бәрхет һ. б.) чиккәннәр.

Материал чигүченең экономик хәленә һәм әйбернең нинди максат белән чигелүенә карап сайланган. Чигү өчен гадәттә ефәк (катылган), мамык һәм кайбер очракларда йон һәм металл (алтын һәм көмеш) җепләр кулланылган. Металл җепләр белән күбесенчә баш һәм аяк киемнәрен, өстәл җаймаларен, битъяулык очларын чиккәннәр. Тамбурлап чигү (аны күпертеп һәм элмәләп чигү дип тә атыйлар) революциягә кадәр иң киң таралган чигү төре булган. Кыргызлар аны «илмә-дус», кара-калпаклылар һәм казакълар «илмәк», төркмәннәр «илмә» дип атыйлар[3].

Тамбурлап чигүнең күп төрле мөмкинлекләреннән файдаланып, чигү осталары чәчәк һәм үсемлек рәсемнәрен күз явын алырдай ачык һәм матур итеп чигә торган булганнар.

Тамбурлап чигүнең нигездә ике төрле варианты бар: юка элмә һәм күперткән элмә. Алар бер-береннән элмә арасы һәм җеп юанлыгы белән аерыла. Н. И. Воробьев билгеләве буенча, эрерәк элмә һәм нечкә җеп белән чигү юка тамбур дип атала. Юан җеп белән һәм элмә араларын еш итеп чигү — күперткән тамбур дип атала. Күперткән элмә белән чигәр өчен, гадәттә, катылган ефәк җеп кулланылган.

XIX гасырның 70 нче елларыннан башлап, кулдан чигү белән беррәттән, тамбурлап машина белән чигү дә шактый киң таралып китә. Бу эшнең алга китүенә Европаның сату-алу фирмалары аша Казанга чигү машиналары китерелә башлавы ярдәм итә[4]. Татар чигүчеләре, аеруча сату өчен эшләгәннәре, машина белән чигү эшен бик тиз үзләштереп алалар һәм художество

---

[1] Н. И. Воробьев мишәр хатын-кызларының тамбурлап чигүләрен һәм, Казан татарлары белән чагыштырганда, бу эш белән бик аз шөгыльләнүләрен билгеләп үтә. (Н. И. Воробьев. Казан татарларының тукымаларны орнаментлау ысулы турында. ТАССР Үзәк музее материаллары. 2 сан. Казан. 1930, 17 бит.)

[2] Н. В. Воронков, В. К. Клейн, В. Н. Хвальковский. П. К. Козлов казылмаларыннан табылган монгол ефәк тукымалары. Рус телендә. Дәүләт Академиясенең материаль культура тарихы хәбәрләре. IX т., 7—8 чыгарылыш. Ленинград, 1932 ел; С. И. Руденко. Таулы Алтай табылмалары һәм скифлар. М.-Л., 1952 ел.

[3] А. С. Авижанская. Башкортларның бизәү сәнгате. Уфа, 1964 ел, 85 бит. А. Морозова. Машина белән бизәк чигү. Ташкент, 1960 ел, 6 бит; А. Андреев. Тау таҗиклары һәм Памир кыргызлары орнаменты. Ташкент, 1928 ел.

[4] А. Морозова. Алда күрсәтелгән хезмәт 10, 19 битләр.



Чигелгән сөлге башы. XIX йөз.

кыйммәтләре ягыннан кулдан чигелгәннәрдән һич тә ким булмаган бик нәфис әйберләр чигеп чыгара башлыйлар. Машина кулланыла башлагач, чигелгән әйберләр эшләп чыгару да бик нык арта.

Тамбурлап чигүдә, кагыйдә буларак, гади энә белән эш иткәннәр, ә XIX гасырның икенче яртысыннан алып ара-тирә махсус энәләр дә куллана башлаганнар. Тамбурлап гадәттә орнаментның контуры чигелгән, ә бизәкләрнең эчке өслеген келәм элмәге яисә тоташ чигү белән эшләгәннәр. Бизәкләрне тукымага карандаш, акбур яисә күмер белән алдан сызып куйганнар, аннары шул сызыклар өстеннән чиккәннәр. Бизәкләрне тукымага төшерү юллары күп төрле булган: бу эш өчен сабын да, алюмин кашык та, күчергеч кәгазь дә кулланылган. Ә кайбер чигүчеләр бары тик рәсемгә карап кына чиккәннәр. Карап чигү алымы аеруча киң таралган булган. Тукымага сызып тормыйча, әнә шулай карап кына чигү аркасында, һәр кеше теге яки бу бизәкне үзенчә сайлаган, чәчәкләрне, агачларны үзе теләгәнчә урнаштырып чиккән.

Гасырлар буена камилләшеп килгән чигү сәнгатендә бер гомуми традицион стиль, аерым төр бизәкләр һәм аларны урнаштыру принциплары формалашкан. Казан хатын-кызларының чигүләренә рәсемнәренең күп төслелеге, сурәтлелеге, ачыклыгы, төсләренең уңышлы чиратлаштырылуы һәм гомуман бизәкләренең җиңел, тәэсирле булуы хас. Тамбур ысулы чигүчеләрнең иҗат ирекен чикләмәгән, киресенчә, аңа материалларның үзенчәлекләре белән санашып тормыйча, бизәкләрне үзе теләгәнчә урнаштырырга мөмкинлек биргән.

Тамбурлап чигүнең композициясе, гадәттә, эре чәчәкләрне вак чәчәкләр белән аралаштыру юлы белән төзелгән. Орнаментның, бизәкнең билгеле бер ритмда урнаштырылган төсләре чигелгән әйбернең шома, тыныч фонына ачык контраст рәвештә сайланган. Намазлыкларга, естәл җәймәләренә, баш яулыкларына, савыт-саба япмаларына төсләр фоны кертү бизәкләрнең аерым төсләр гаммасын йомшартып яисә көчәйтеп җибәргән, әйбернең фоны белән бизәк төсләре арасында үзара тигезлек, ярашу тудырган.


Ювелир әйберләре, каелган читекләр белән бергә, чиккән әйберләр дә Идел буе мишәрләренә «башкортларга, Урта Азия, Кавказ халыкларына» бик күпләп озатылып торган. Һәм менә шул хәл «әлеге халыкларның художество иҗатында татар орнаментының таралуга ярдәм иткән»[2]. Мәсәлән, Урта Азия халыклары иҗатын тикшерүче А. Морозова татар чигү орнаментларының һәм бизәкләренең үзбәк чигүчеләре иҗатына актив кереп киткәнлеген яза. «Озак еллар буенча, — ди ул, — аларны күчереп киләләр, аларга охшатырга тырышалар, һәм яңа бизәкләрнең күбесе шултикле үзләштерелеп китә, хәтта XIX гасыр ахыры — XX гасыр башларында атаклы Ташкент эклектик стиле дә шулар нигезендә дөньяга килә»[3]. Татар орнаментының тәэсире башкорт сәнгатендә дә шактый сизелә. Татар орнаментының башкортларга үтеп керүенә, татар һөнәрчеләренең һәм чигүчеләренең осталыгы белән бергә, әлеге ике тугандаш халыкның

---

[1] Монда без тамбурлап чигү алымы үзенчәлекләрен язып тормыйбыз. Бу мәсьәлә белән кызыксынган кешеләргә Н. И. Воробьевның «Казан татарларының тукымаларны бизәү техникасы буенча кайбер мәгълүматлар» исемле хезмәтен укырга киңәш итәбез. ТАССР Үзәк музее материаллары. 2 сан. 1930 ел.

[2] А. Морозова. Алда күрсәтелгән хезмәт, 19 бит.

[3] Шунда ук.



Болгар казылмаларыннан табылган чигү үрнәге. XIV йөз.

үзара ныклы элемтәдә булуы һәм XVI — XVIII гасырларда күчкән күп кенә Казан татарларының (типтәрләр) Башкортстан җирендә яшәве дә ярдәм иткән [1].

Тамбурлап чигүгә караганда азрак булса да, татар чигү сәнгатендә ефәк, йон һәм, бигрәк тә, алтын һәм көмеш җепләр (фольга) белән тоташ чигү ысулы да шактый зур урын алып тора. Казан татарларының алтын белән чигү эше зураеп, кәләпүш-читек промыселына әверелеп киткән. Ләкин ул йорт-кул эше булу характерын югалтмаган.

Чигелгән материалга алтын һәм ефәк җепләр белән чәчәк рельефлары, чәчәк бөреләре, үсемлек сабаклары һәм яфраклары ясалган. Чәчәкләрнең ботакчыклары, таҗлары, бөтеркәле урыннары ука белән чигелгән. Нәтиҗәдә чәчәк-үсемлек дөньясының гаҗәеп дәрәҗәдә матур һәм зиннәтле бизәкләре барлыкка килгән.

Алтын белән чигү күп очракта кулдан эшләнгән, ләкин шәһәр хатын-кызлары арасында киергә кулланучылар да булган. Материяне 70 × 100 сантиметр зурлыгындагы аяклы рамнарга беркетеп чигүчеләр дә очраган. Ул болай булган: чигүчеләр чигеләчәк тукыманы әлеге рам эченә махсус баулар белән тарттырып куйганнар да, үзләре шунын янына тезләнеп эшләгәннәр.

Казан татарларының алтын чигү сәнгате күп гасырлар буена үсеп, камилләшеп килгән. Аның традициясе безнең бабаларыбыз — Идел-Кама болгарлары сәнгатенә барып тоташа. Археология материалларына караганда, ефәк җепләр белән алтынлап һәм көмешләп тоташ чигү ысулы әле болгар халыклары арасында ук киң таралган булган (5 нче рәсем) [2].

Безнең уебызча, XVI гасырга караган алтын чигү художестволылыгы ягыннан да, эшләнү ысулы ягыннан да шактый зур кыйммәткә ия. Билгесез профессиональ оста тарафыннан эшләнгән бу чигү художество эшләнеше стиле ягыннан XVI—XVII гасырларга караган кабер ташлары орнаментикасы белән бик нык охшаш [3].

XVIII—XIX гасырларда төсле бәрхеткә алтын, көмеш, энҗе һәм башка күп төрле асыл ташлар белән чигелгән һәм үзләренең матурлыклары, зиннәтлелекләре белән аерылып торган хатын-кыз баш киемнәре — калфаклар, өрпәкләр (чукрый калфак) — безнең көннәргә кадәр сакланып калган.

Әлеге ысул белән букет, ишелгән җеп, төрле йолдызчыклар сурәтләре ясап чигелгән, болгар чорыннан ук килә торган ирләр түбәтәйләренең нәфислеге дә танга калдыра.

---

[1] Татар орнаментларының йогынтысы башкорт кустар чигүенә кагылмый. Аларның ул төр чигүе татарларныкыннан бик нык аерылып тора һәм үзендә борынгы башкорт орнаменты традициясен саклый. Казан татарларында кустар чигү булмаган.

[2] Е. С. Видонова. Болгар казылмаларында табылган XIV гасыр тукымалары һәм чигүе. Рус телендә. 1947 ел.

[3] Үзеннән соңгы чордагылардан аермалы буларак, бу чигүдә бизәкләрне сурәтләүдә бик нык канончылык сизелеп тора һәм аларда чәчәк-үсемлек мотивлары да сирәк. Борынгы, аерым алганда Болгар, заман әсәрләренә хас булган тыйнаклылык, кырыслык, архаиклык та күренеп тора аларда.

Әле безнең көннәрдә дә илебез халыклары арасында чигүле татар туфлиләре һәм башмаклары да күңелдә онытылмас тәэсир калдыра. Төсле бәрхеткә алтын һәм көмеш белән чигелгән сурәтләрне еш кына салават күпере шикелле төрле төсләр сибеп ялтырый торган кыйммәтле ташлар белән дә бизәгәннәр. Халык иҗатының бу төрендә алтын чигүнең нәзакәтлелеге, аны сәнгать югарылыгына күтәрә торган гармониясе сизелеп тора.

Алтын, көмеш белән чигелгән бизәкләр, гадәттә, башка бизәкләрдән кабарынкырак була. Бу кабарынкылык (рельефлылык) чигелә торган рәсем астына катыргы яисә башка бүтән каты әйбер кыстырып калдыру аркасында барлыкка килә. Букет, бер якка бик килешле бөгелеп торган ботак рәсеме ясалган композиция аеруча киң таралган.

Алтын һәм көмеш белән чигелгән бәрхет түбәтәй һәм туфлиләрне чыгару белән хәзер Казан, Арча һәм Дөбъяздагы художество әйберләре эшли торган фабрикалар шөгыльләнә.

## СЕЗ ҮЗ ИСЕМЕГЕЗНЕҢ МӘГЪНӘСЕН БЕЛӘСЕЗМЕ?

Ниса — хатын-кыз.
Нияз — үтенү, ялвару.
Ногман — лалә чәчәге.
Нурдидә — күз нуры.
Нәгыйм — нигъмәт, муллык.
Нәзаһәт — намуслылык, гыйффәтлелек.
Нәзыйрә — үрнәк, өлге.
Нәкый — пакь, катнашмасыз.
Нәфисә — матур, гүзәл.
Нәҗиб — тәрбияле, аксөяк нәсел кешесе.
Рамазан — ай елының тугызынчы ае исеме.
Рауза — гөл бакчасы.
Рәхилә — өстендә йөк йөртә торган хайван.
Рашид — батыр, кыю кеше.
Риза — карышмау, разый булу.
Ризван — разыйлык, күңел хушлыгы.
Рифгать — күтәрелеш, югарыга ашу.
Рәдиф — запаста торучы гаскәр.
Рәзилә — түбән, хурлыклы.
Рәис — җитәкче, башлык итүче.
Рәйхан — зәңгәр чәчәкле хуш исле гөл.
Рәкыйб — конкурент, берәр эштә башкалардан өстен булырга омтылучы.
Рәми — ату, ук ату.
Рәфикъ — иптәш, юлдаш.
Рәфика — иптәш хатын.
Рәхим — рәхимле.
Рәшад — туры юл тоту.
Сабир — түзем, чыдаучы кеше.
Сабит — үз уенда нык торучы.
Сагыйрь — рюмка, бокал.
Садыйк — эчкерсез кеше.
Сәлим — сәламәт, исән-сау.
Сәлисә — секундның 60 тан бер өлеше.
Салих — яхшы, изге.
Сәмига — тыңлаучы, ишетүче.
Сания — секунд.
Сафа — рәхәтлек, кәефлелек.
Сахиб — ия, хуҗа.
Саҗидә — сәҗдә кылучы.
Суфия — начар эшләрдән сакланучы хатын-кыз.
Сәгадәт — бәхет.
Сәкинә — күңел тынычлыгы.
Сәрвәр — халыкның дәрәҗәле кешесе.
Сахи — юмарт.
Таифә — төркем, җәмәгать.
Тәлгат — күркәмлек.
Таһир — таза, нык, гаепсез.

## ТӨРЛЕСЕННӘН

# ХАЛЫК ТАРИХЫ – ФОЛЬКЛОРДА

Бу — күптәннән билгеле хакыйкать. Фольклор әсәрләрендә халыкның гореф-гадәтләре, чынбарлык тормышка мөнәсәбәте, тарихи үткәне теркәлеп калган. Аерым төбәкләрдә алар теге яки бу халыкның тарихын ачыкларга ярдәм итүче бердәнбер чыганак булып торалар. Әмма, шулай булуга да карамастан, татар фольклористикасында бу гаять әһәмиятле эшкә тиешле игътибар җитеп бетмәде. Хәзер бу эш нык җанланып килә. Шулай да фольклор белгечләренең кулы тимәгән, бөтенләй өйрәнелмәгән төбәкләр байтак. Шундыйларның берсе — белорус татарлары фольклоры.

1959 елда үткәрелгән халык санын алу йомгакларына караганда, Белоруссия ССР территориясендә 8000 нән артык татар яши икән. Польша Халык Республикасында тагын берничә дистә мең татар бар. Хәзер инде җирле халык белән тәмам үзләшеп җиткән, хәтта үз ана телләрен дә онытып бетергән бу татарлар Белоруссия, Польша җирләренә каян килеп чыкканнар соң? Рус, белорус, поляк телләрендә аларның килеп чыгышлары турында язылган фәнни материаллар әллә никадәр. Бөек Октябрь революциясенә кадәр яшәгән күренекле этнографлардан А. Мухлинский хезмәтләрендә белорус татарларының этногенезлары хакында кызыклы мәгълүматлар табарга мөмкин. (А. Мухлинский. Исследование о происхождении и состоянии литовских татар. Петербург. Рус телендә. 1857 ел.) «Белорус һәм башка славян телләре буенча хезмәтләр» исемле китабында академик Е. Ф. Карский белорус татарларының этногенезына тукталып, болай ди:

«Белоруссиянең төрле почмакларында, мәсәлән, Вильнода, Минскида, башка шәһәр һәм торак пунктларында, төркем-төркем булып, мөселман татарлары яши. Бу якларга алар XIV йөзнең башларында ук килеп утырганнар...» Е. Ф. Карский белорус татарларының җирле халык сөйләменә күчүләрен дә, нигездә, дөрес аңлата: «Литва дәүләте җирләренә күчеп утыргач, алар тиз арада белоруслашканнар. Бу, өлешчә, аларның белорус кызларына өйләнүләре белән аңлатыла» (459 бит).

Шулай да белорус татарлары телендә милли татар сүзләре әле хәзер дә байтак очрый: азан, садака, кош, мәче, сабак, хәрам, хуҗа, сәлам, дошман, иблис, шәригать һ. б. һ. б. Халык авыз иҗаты әсәрләрендә исә борынгы бабаларының культура мирасы тагын да ныграк сакланган. Оригиналь эчтәлекле әкиятләр һәм легендалар, сөйләкләр белорус татарлары фольклорында аеруча киң таралган жанрлардан санала. Фольклор әсәрләрендә аны иҗат итүчеләрнең уй-хыяллары, якты омтылышлары һәм батырлыгы гәүдәләнгән. Коры сүз белән генә калмас өчен, Д. Александровичның «Литва татарлары» исемле хезмәтеннән бер сөйләк китерик:

«Шулай бер заман Литва җиренә тәре йөртүчеләр басып керә. Төрле сихерле тылсымнар белгәнгә, литвалыларның кораллары боларга һич кенә зыян китерә алмый икән. Аптырагач, литва князьләре ярдәмгә татарларны чакырып карарга булалар. Шундый бирәләр, шулкадәр котларын алалар татарлар — немецларга укчә ялтыратудан башка чара калмый. Татарны пуля да алмый, дигән мәкаль дә әнә шул заманда чыккан, ди».

Белорус татарларының фольклоры турында сөйләгәндә, шуны да искәртеп үтик: халык авыз иҗатының борынгы җәүһәрләре күбесенчә гарәп хәрефләре белән белорусча язылган һәм буыннан-буынга килгән иске кульязма китапларда очрый. Ул китапларның байтагы 16—17 гасырларда ук язылган. Кызганычка каршы, аерым кулларда саклана торган бу китаплар хәзергә кадәр ныклап өйрәнелмәгән, тикшерелмәгән. Ә өйрәнергә, тикшерергә бик кирәк. Аларда татар халык авыз иҗатын өйрәнүче галимнәр өчен кызыклы, бай материал сакланган булырга мөмкин.

**Р. МОЗАФФАРОВ,**
**Б. ГАФАРОВ,**
**филология фәннәре кандидатлары.**

# ИБРАҺИМ ХАН ЯРЛЫГЫН УКУГА КАРАТА КАЙБЕР ФИКЕРЛӘР

Укучылар хәтерлидер, «Казан утлары» журналының узган елгы 8 санында М. Госманов, Ш. Мөхәммәдъяров һәм Р. Степанов иптәшләрнең «Яңа ярлык» исемле мәкаләсе басылган иде. Сүз анда Мәскәүдә борынгы актлар саклана торган үзәк архивтан табылган Ибраһим хан ярлыгы турында бара. Дөресен әйтергә кирәк, авторлар зур тарихи әһәмияте булган бу документны матбугат өчен әзерләгәндә күп көч куйганнар. Мәкаләдә ярлыкның табылу тарихы аңлатыла, аның транскрипциясе һәм хәзерге телгә тәрҗемәсе китерелгән, кайбер атамаларга, архаик сүзләргә аңлатмалар бирелгән.

Шулай да, ачыклыйсы урыннар, төрле характердагы төгәлсезлекләр калган әле. Биредә, кыскача гына булса да, шул төгәлсезлекләргә, үзебез бәхәсле дип санаган аерым моментларга тукталып үтмәкче булабыз.

Ярлыкның өченче юлындагы **«йибәргән»** сүзен авторлар, мәсәлән, **«йибәрелгән»** дип ялгыш укыганнар. Шул ук өченче юлның ахырында **«аты: башлыг»** дигән сүз тезмәсе бар. Безнеңчә, бу тезмә шулай ук ялгыш укылган, дөресе — **«алты яшьлек»** булырга тиеш.

«Болардан **билгесез** кем-кем ирсә урамаңларына йөремәсеннәр» дип башланган (VII юл) җөмләдәге **«билгесез»** сүзе хәзерге телгә дөрес тәрҗемә ителмәгән.

Борынгы татар телендә «билге» сүзе **дәлил, таныкъ, рөхсәт хаты** (документы) кебек мәгънәләрне белдергән, әлеге җөмләдә дә ул нәкъ шул мәгънәдә кулланылган.

XI юлда «санлыг» дигән бер сүз бар. Бу — ялгыш, ә дөресе — **«нишанлыг»** (мөһерле печать сугу). Төп нөсхәдә «н» хәрефенә салынган бер нокта һәм «ш» хәрефенә салынган өч нокта, вакытлар узу белән, җуелган, күрәсең. Башка ярлыкларда (мәсәлән, Алтын Урда ханы Әхмәт хан ярлыгында) бу сүз **«нишанлыг»** рәвешендә язылган.

Авторларның **«чүрә»** сүзенә биргән аңлатмалары белән дә килешеп җитеп булмый. Алар: «Чүрә, гадәттә, кол мәгънәсендә йөри. Әмма бу ярлыкта ул **«хезмәткәр»**, **«ирекле ялчы»**, **«хезмәтче»** мәгънәсендә булса кирәк. Әгәр «кол» мәгънәсендә дип аңласак, алпавыт, тарханлык язуы алу белән, үзенең милке — колыннан мәхрүм калган булып чыга. Димәк, биредә бу сүз татар теленә монарчы исәпкә алынмаган яңа эчтәлек белән китерелә», диләр. Безнеңчә, мәсьәлә бик ачык: «чүрә» биредә дә нәкъ «кол» мәгънәсендә кулланылган. Хәйдәр-Гали кол булып саналган тол хатын Гөлбостанны (ихтимал, иренең берәр каһарманлыгы өчендер) һәм аның алты яшьлек улы Мөхәммәт-Газизне азат итә.

Авторлар «саба» сүзендә соңгы «н» хәрефе һәм «ирсәлә» сүзендә соңгы «р» хәрефе төшеп калган булырга тиеш дип дөрес әйтәләр. Ләкин хикмәт очраклы төшеп калуда гына түгел. Борынгы татар телендә мондый очракларда «н» хәрефе язылмаса да, кагыйдә буларак, аны бар дип хисаплаганнар һәм «сабан» дип укыганнар.

Инде ярлыкның кем тарафыннан һәм кемгә бирелүе турында берничә сүз. Текстта да, авторлар биргән аңлатмаларда да ярлык бирүче тагын гелә ачыкланмаган. IX юлдагы текстка карагaнда, Гөлбостанны азат итүче кеше Хәйдәр-Гали-Солтан булырга тиеш кебек. V—VI юлларда Гөлбостанның «әлекке хуҗасы» турында да сөйләнә. Ләкин Хәйдәр-Гали-Солтан белән Гөлбостанның «әлекке хуҗасы» икесе бер үк кешеме, әллә тагын икенче бер хуҗа да булганмы? Анысы билгесез.

Ярлыкны хәзерге татар теленә тәрҗемә итүдә һәм тыныш билгеләре куюда да төгәлсезлекләр очрый. Шулар аркасында, текстның мәгънәсен аңлау нык авырайган. Мәкаләдән аңлашылганча, борынгы актлар саклана торган үзәк архивта бу ярлыкның Артык Иманаев дигән кеше тарафыннан эшләнгән русча варианты да саклана икән. Ни өчендер, авторлар журналда русча вариантны күрсәтмәгәннәр. Ихтимал, кайбер хаталарны һәм бәхәсле урыннарны хәл итүдә русча вариантның да беркадәр ярдәме булыр иде.

Ә. БУЛАТОВ.

# Истэлеклэр

*Арчаның 2 нче урта мәктәбе укытучылары һәм укучылары, Г. Тукайның 80 еллык юбилеена әзерлек уңае белән, шагыйрьнең замандашлары белән очрашуны да планлаштырган булганнар. Шул планны үтәү йөзеннән, әлеге мәктәп укытучысы Солтанова Фахирә Габдулла Тукайны бала чагында күреп белгән Һаҗәр әби Галимуллина белән очрашып, аның шагыйрь турындагы истәлекләрен язып алган. Шул ук көннәрдә ул, берсе хезмәтче, икенчесе асрау булып, әлек Фатих Әмирханның атасы Зариф муллаларда торган кешеләр белән дә очрашкан һәм аларның да әдип турындагы истәлекләрен язып алган. Журналыбызның бу санында без Ф. Солтанова җибәргән шул истәлекләрне урнаштырабыз.*

## Ул бик зиһенле иде

Мин 1884 елда Кырлай авылында туганмын. Минем әнием Кушлавычныкы иде. Аның сөйләвенә караганда, Габдулланың әтисе Мөхәммәтгариф — безнең әбинең энесе булырга кирәк.

Сәгъди абзый Габдулланы Өчиледән алып кайткач, әнинең: «Габдулла миңа кардәш», диюе дә хәтеремдә. Габдулла безгә дә еш килә иде, әни аңа ашарга бирә торган иде. Ипигә май ягып бирүен хәтерлим. Кием-салымнарын да кайчакта әни юып бирә иде.

Габдулла бик зиһенле, шунлыктан әни мине аның белән һич тә хәвефләнмичә җиләккә җибәрә иде. Ул урманның бөтен сукмакларын белә, без бер дә адашмый идек. Урманда йөргәндә аның бер гадәте бар: бездән кача иде дә әтәч булып кычкыра иде.

Урманда җиләк җыйганда да гел авыз эченнән нидер мыгырдап, көйләп йөри һәм савытын да бик тиз тутыра торган иде ул.

Шулай бервакыт урманда яшьләрнең гармун уйнаган тавышлары ишетелде. Шунда Габдулланың миңа: «Әйдә, син әнә теге агач артына, ә мин менә бу агач артына качабыз, алар киткәч, мин сиңа дәшермен, чыгарсың», дигәне хәтеремдә калган.

Җитү кыз булгач, мин Казанга килдем. Кайсы елда килгәнемне төгәл хәтерләмим, 1903—1905 еллар тирәсендә булырга кирәк. Казан урамында Габдулла белән очрашкалап, авыл хәлләрен сөйләшә торган идек. Тик озак сөйләшеп тора алмыйбыз, чөнки мин иремнең көнләшүеннән куркам, ул бик көнче кеше иде. Шунлыктан аны өебезгә дә чакыра алмадым.

Бервакыт Клячкин больницасы яныннан үтеп бара идем, тәрәзә каккан тавыш ишеттем. Борылып карасам, тәрәзәне Габдулла шакый икән. Аннары ул мине кул изәп чакыра башлады. Мин, иремнең көнләшүеннән куркып, тәрәзә янына бармадым. Ул вакытта заманнар икенче иде, дин буенча да тыелганга, ир-ат та көнләшкәнгә, ир туганнар белән очрашкач, сөйләшеп тә торып булмый иде. Шуңа күрә мин тәрәзә янына барырга да курыктым. Ул чакта Габдулла янына бармавыма хәзер бик үкенәм дә бит — ни хәл итмәк кирәк...

ГАЛИМУЛЛИНА ҺАҖӘР.

## Мин аны күтәреп йөрттем

Мин 1889 елда Кырлай авылында туганмын. 17—18 яшьләремдә авылдан Казанга чыгып киттем. Анда Фатих Әмирханның әтиләренә хезмәтче булып кердем. Кучерлык вазифасын да мин үти идем. Фатихны ат белән һәрвакыт мин йөрттем. Ул параличлангач, мин аны кая барса да күтәреп йөртә торган булдым. Дәваланырга Серноводскига да алып бардым. Анда врач аның кулларына, аякларына массаж ясый торган иде. Соңыннан врач массаж ясарга мине өйрәтте, һәм Фатихка массажны мин үзем ясый башладым.

Мин Фатихны Кабан күленә көймәдә йөртергә дә алып чыга идем. Кешеләр: «Синең аны күтәрергә ничек көчең җитә?» дип, бик кызыксынып карап торалар иде.

Фатих тирә-якта үзенең зур укымышлы булуы белән данлыклы иде. Бик күп язды. Шулай бервакыт язып утырганда: «Мәгъсүм, бу китапны язып бетерсәм, безгә синең белән икебезгә җитә», диган иде. Күрәсең, китабы басылгач алыначак гонорары турында әйтүе булгандыр инде.

Коляска ясап биргәч, минем эш бераз җиңеләйде. Фатих коляска белән йөри башлады. Анда да мин күтәреп утырта, күтәреп төшерә, күтәреп өйгә алып керә идем. Хәзер инде кайларга баруыбыз онытылган, ләкин Фатих бик күп йөри, бер дә өйдә тормый, чөнки һаман кая да булса чакырып торалар иде аны.

Фатих янына бик күп язучылар килә һәм аның бүлмәсендә бик озак утыра торганнар иде. Аларның нәрсәләр турында сөйләшүләрен белмим инде, истән чыккан.

*ГАЙНЕТДИНОВ МӘГЪСҮМ.*

## Ул безнең туйга да килде

Мин 1891 елны Казанда Яңа Бистәдә туганмын. Әтием кәвеш тегә иде. Шуның өчен аны Кәвешче Вәли дип йөртәләр иде. Әнием кәләпүш типчи иде.

Әтием-әнием үлгәч — ул вакытларда миңа 13 яшьләр иде булса кирәк — Фатих Әмирханның атасы Зариф муллаларга асраулыкка кердем. Мин аларда 12—13 еллар тордым. Тормышлары бик иркен иде. Ашау-эчү дә бик иркен иде, өс-башны да бик карадылар. Үз гаиләләре кешесе шикелле итеп тоттылар. Абыстай бик уңган, бик булдыклы, бөтен аш-суны үзе әзерли иде. Өстәвенә, 300 ләп кыз баланы да укытты. Миңа да 70 ләп вак балаларны бирә иде. Без кадимчә түгел, җәдитчә укыттык. Ул чорларда Фатих абый Мәскәүдә яши иде. Аннары ул Казанга кайтты һәм, берничә генә ай үтүгә, параличланды.

Ул болай булды: мин иртәнге чәйне әзерләп табын янына утырырга торганда, абыстай: «Бар, Хөсниҗамал, чәйгә Фатих абыеңны чакыр әле, — диде. Мин аның бүлмәсенә кердем — анда юк, парадный ягыннан карадым — анда да күренмәде. Эзли торгач, мин аның бәдрәф алдында чалкан ятуын күреп алдым да, йөгереп кереп: «Абыстай, Фатих абый үлгән», дип кычкырып җибәрдем. Аннары без аны өйгә алып кереп салдык та врач чакырдык. Врачлар аны больницага салырга куштылар һәм ул байтак вакыт больницада ятты.

Соңыннан Фатих абыйның күзләре һәм авызы элекке хәленә кайтты, куллары йөри башлады, ә билдән түбән гәүдәсе бөтенләй хәрәкәтсез калды.

Аның үзенә аерым бүлмәсе булып, без аны «Фатих абый бүлмәсе» дип йөртә идек. Анда аның иптәшләре килә, иң еш килгәне Габдулла Тукай иде. Ул күп вакытын Фатих абый янында үткәрде.

Мулла абзыйлар да килүчеләргә бер дә караңгы чырай күрсәтмиләр иде. Бүлмәдә шау-шу килеп утырган вакытлары да була, тәмәке дә тарткалыйлар, әмма мулла абзый ачуланып бер сүз дә әйтми иде. Ул алар эшенә катнашмады, яшьләрнең яңа фикердә булуларын белә иде, аларны тыймады.

Тукайның, минем белүемчә, өч күлмәге бар иде: ак, кара сатин, кызыл сатин. Аларны мин юып, үтүкләп бирә торган идем. Мин аны бик якыннан беләм.

Фатих абый булмасена ул вакытларда Вафа Бәхтияров, Сәгыйт Сүнчәләй, Кәрим Тинчуриннар да бик еш килә иде. Кайсы елда икәнен хәтерләмим, хәзерге Ботан бакчасына каршы дачада Фатих абый ял итте. Анда да гел әлеге язучылар белән бергә булды. Фатих абый белән Мәгъсүм дә шунда иде. Чөнки аны күтәреп йөртергә, йомышьюлына йөрергә кирәк иде.

Мин Фатих абыйның үз иптәшләре белән газета чыгару турында сөйләшүен хәтерлим. Ул «Әлислах» исемле газета чыгарды. Газета редакциясе хәзерге Тукай урамында мулла абзыйның сенелесе Аппаковалар йортына урнашкан иде, шунда аны һәр көнне Мәгъсүм ат белән илтеп куя, алып кайта иде.

Тагын шул хәтеремдә: мин аның бүлмәсен җыештыра, ана ашарга кертә идем.

Берсендә ул «Хәят» әсәрен язып утыра икән, мин килеп кергәч: «Хөснижамал, китапка синең исемеңне дә кертимме, сине дә языйммы?» диде. Ә мин: «Фатих абый, зинһар, яза күрмә!» дип чыгып киттем. Икенче керүгә ул миңа тыңларга кушты һәм миңа шушы сүзләрне укып та күрсәтте:

Хөснижамал әйтә икән:
— Мин кияүгә барам, — дип.
Әнкәсе аңа әйтә икән:
— Бармагаең, кадал, — дип.

Мин оялып чыгып киттем. Китап басылып чыккач, ул аны миңа тагы укып күрсәтте. 1917 елда булса кирәк, мин ул вакытта Солдат Шакирларда хезмәт итүче Мәгъсүмгә кияүгә чыктым һәм шунда торырга күчтем. Фатих абый безнең туебызга да килде, күп итеп бүләкләр дә алып килгән иде. 5—6 ел вакыт үткәч, без авылга — Кырлайга кайтып киттек. Шуннан соң без Фатих абыйлар белән очрашмадык.

*ГАЙНЕТДИНОВА ХӨСНИЖАМАЛ.*

## СЕЗ ҮЗ ИСЕМЕГЕЗНЕҢ МӘГЪНӘСЕН БЕЛӘСЕЗМЕ?

**Туфан** — көчле ташкын, көчле яуган яңгыр.
**Тәгъзия** — аш бирү, ризыкландыру.
**Тәрҗеман** — тәрҗемәче, тылмач.
**Тәслимә** — тапшыру, бирү.
**Тәнзилә** — ташлама ясау, скидка.
**Тәүзыйх** — ачык итеп аңлату.
**Фазыл** — камиллек.
**Фаиз** — теләгенә ирешүче.
**Фаик** — башкалардан алда торучы.
**Факиһә** — җимеш.
**Фарук** — дөрес белән ялганны бик төгәл аера белүче.
**Фатих** — башлап җибәрүче.
**Фирүзә** — яшел төстәге кыйммәтле таш.
**Фәйрүзә** — асылташ.
**Фәләх** — бәхет, уңыш.
**Фәрзәнә** — галим, укымышлы кеше.
**Фәрид** — тиңдәшсез, бердәнбер.
**Фәсыйх** — матур итеп сөйли белүче.
**Фәттах** — юл ачучы.
**Фәхри** — мактаулы, хөрмәтле.
**Фәһим** — үткен, зирәк акыллы.
**Фөлүс** — вак акча, бакыр акча.
**Хәким** — бик акыллы, белемле кеше.
**Харис** — яклаучы, саклаучы.
**Хатирә** — истә калган вакыйга, хәл, эш.
**Хафиз** — күңелдән ятлаучы.
**Хөршидә** — кояш, көн.
**Хәбиб** — сөекле.
**Хәйдәр** — арслан.
**Хәлил** — якын һәм чын дус.
**Хәлим** — йомшак, сабыр, юаш кеше.
**Хәмит** — мактауга лаек кеше.
**Хәниф** — туры күңелле кеше.
**Хәсән** — күркәм, матур.
**Хөсәен** — гүзәл, яхшы.
**Шакир** — канәгать, шөкер итүче.

# БЕЗГӘ — КЫРЫК ЯШЬ!

Һәркөн иртән хат ташучы редакция өстәленә бер кочак хат китереп сала. Кайдан гына килми ул хатлар! Казан, Сарман, Саба, Уфа, Ташкент, Мәскәү, Норильск, Тын океан... Аларның авторлары колхозчылар, эшчеләр, укытучылар, күп бала үстергән аналар, Совет Армиясендә хезмәт итүче солдатлар. Үзләренең тормышлары, хезмәтләре турында язалар, басылган материаллар турында фикерләрен әйтәләр, үзләрен борчыган мәсьәләләр буенча киңәш сорыйлар. Елның вакытына карап хатларның саны да, эчтәлеге дә үзгәрә тора. Озын кыш бетеп, кояш елмая башлагач, редакциягә дистәләп, йөзәрләп мәхәббәт шигырьләре агыла. Кояш ныграк кыздыра башлагач, мондый хатлар саны сизелерлек кими. Аның каравы халкыбызның дәртле хезмәте, матур тормышы турында язылган хатлар елның ел буена килеп тора. Узган елны гына «Азат хатын» журналы редакциясе ун меңгә якын хат алды.

Укучыларның бер өлеше «Азат хатын» әле күптән түгел, 1958 елдан гына чыга башлаган журнал дип уйлыйлар. Хәлбуки, журналның бай тарихы бар. Моннан нәкъ 40 ел элек, 1926 елның август аенда партиянең Татарстан өлкә комитеты каршындагы хатын-кызлар бүлеге татар телендә хатын-кызлар өчен «Азат хатын» исемле журнал чыгара башлый. Яшь республика тормышында бу шатлыклы вакыйга була.

Татар телендә хатын-кызлар өчен 1913, 1917, 1918 елларда «Сөембикә», «Шәрык кызы», «Азат ханым» исемле журналлар чыгып килгән. Димәк, бу өлкәдә күпмедер тәҗрибә тупланган иде инде. Ләкин татар буржуазиясе чыгарып килгән ул журналлар, Һади Такташ сүзләре белән әйткәндә, «озын кара толымлы, сихри күзле, илаһи фәрештә» кебек милли кызларның милли егетләргә булган гыйшык-мәхәббәтләрен җырлаудан уза алмыйлар. Алар күбесенчә нәфис хәрәкәтле, нәзакәтле курсисткалар, мәхбүбәләр тудыру идеаллары белән яналар, хатын-кызларның мәчеткә йөрү-йөрмәү «проблемаларын» күтәрәләр, революция турында сүз чыкканда «илаһым, артык тирәнәймәсә иде» дип көеналәр. «Сөембикә», «Шәрык кызы», «Азат ханым» кебек журналлардан аермалы буларак, «Азат хатын» журналы эшче-крестьян хатын-кызларына политик тәрбия бирү, хатын-кызларны җәмгыятьнең тигез хокуклы гражданнары итеп тәрбияләү бурычын куя. Партия Үзәк Комитетының эшче-крестьян хатын-кызлар бүлеге журналның беренче санына биргән котлавында журнал «карангылык, наданлык белән көрәшүдә... хатын-кызларның политик белемен арттыру... алардан җәмәгать эшчеләре әзерләүдә... зур корал булырга тиеш», ди.

Журнал чыгару эшен коммунист хатын-кызлар Абруй Сәйфи, Гыйззениса Тажетдинова һәм башка иптәшләр оештырып җибәрәләр. Эш шактый авыр шартларда башлана.

Журналның беренче әдәби сотрудникы, соңыннан редакторы Гөлчирә апа Гафурова, ул көннәрне искә төшереп, болай ди: «Ул вакытта әле һәрбер газета-журнал редакциясе өчен аерым бүлмәләр юк. «Азат хатын» өчен дә «Кызыл Татарстан» редакциясенең бер почмагында Такташ белән икебезгә бер өстәл иде. Штатта фотограф та, машинистка да, рәссам да юк. Типография ерак. Хәзерге Ленин урамыннан Камил Якуб исемендәге типографиягә җәяү йөрибез.

Кыен шартларда эшләргә туры килсә дә, кыска вакыт эчендә журнал зур популярлык казана. Аның битләрендә, Галимҗан Ибраһимов, Муса Җәлил, Абдулла Алиш, Гадел Кутуй, Кави Нәҗми, Әхмәт Фәйзи, Шәйхи Маннур, Хәсән Туфан, Гази Кашшаф, Сибгат Хәким кебек каләм осталарының әсәрләре белән беррәттән, хатын-кызлар арасыннан чыккан яшь каләмнәрнең беренче парчалары да басыла. 15 ел эчендә журнал үз тирәсенә хатын-кызлардан шактый зур актив туплый. Сәрвәр Әдһәмова, Мәршидә Вильданова, Сәрвәр Якубовская, Әминә Бикчәнтәева, Идиал Әминова, танылган журналистларыбыз Мәрьям Дибаева, Галия Гаязова һәм башкалар үзләренең беренче әсәрләрен «Азат хатын» журналына китерәләр.

1941 елда фашистлар Германиясенең илебез өстенә ташланган кара өерләре күп эшләрне, шул җөмләдән «Азат хатын» журналының да эшен өзде. Шактый вакыт чыкмый торганнан соң, 1958 елда журнал яңадан чыга башлады. Бу иҗтимагый-политик

һәм әдәби нәфис журнал илебезнең, республикабызның уңышларын, колхоз-совхоз кырларында, төзелештә, культура, фән өлкәләрендә эшли торган алдынгыларыбызның эш тәҗрибәсен, тормышын яктырту, балаларны Ватаныбызга турылыклы, эш сөючән, белемле, җәмгыятькә файдалы кешеләр итеп тәрбияләүдә ата-аналарга ярдәм күрсәтү, хатын-кызларның күп вакытын ала торган өй эшләрендә файдалы киңәшләр бирү, медицина белгечләренең консультацияләрен урнаштыру бурычын куйды. Тугыз ел эчендә журнал битләрендә бик күп мәкаләләр, очерклар басылды, алдынгы хатын-кызларыбызның эш тәҗрибәсе турында язылды.

«Азат хатын» журналының яңадан чыга башлавына тугызынчы ел. Бер карасаң, әллә ни зур гомер түгел. Ләкин журнал үз тирәсенә хатын-кызлардан шактый күп өметле каләмнәрне туплап өлгерде: журнал битләрендә житмешкә якын хатын-кыз авторның әдәби әсәрләре басылып чыкты. Бу җиде дистәнең бер дистәсе: Сәрвәр Әдһәмова, Ләбибә Ихсанова, Зәкия Туфайлова, Әминә Бикчәнтәева, Мәрзия Фәйзуллина, Сажидә Сөләйманова, Гөлшат Зәйнашева кебек электән үк язып килгән һәм укучыларга таныш исемнәр булса, калганнары барысы да диярлек әдәбият мәйданына путевканы «Азат хатын» журналы битләрендә алдылар.

Шуны да әйтеп үтәргә кирәк, югарыда телгә алынган хатын-кыз язучыларыбызның иҗат активлыклары көчәюдә безнең журналыбызның да күпмедер күләмдә өлеше бар, әлбәттә. Яңа журнал әдәби әсәрләр өчен яңа мәйдан дигән сүз бит ул. Мәсәлән, тугыз ел эчендә «Азат хатын» битләрендә бер Энҗе Мөэминова гына да егерме мәртәбә үзенә урын алган.

Ә яшьләр? Безне аеруча шатландыра торган яңа исемнәр «Азат хатын» журналында беренче әсәрләрен бастырып, әдәбиятта ышанычлы адымнар белән атлап бара алырлык кызларыбыз — Заһидә Гомәрова, Клара Булатова, Салисә Гәрәева, Нәзирә Усманова кебекләр турында куанып сөйли алабыз. Соңгы елларда гына Язучылар союзына член итеп алынган Сажидә Сөләйманова, Энҗе Мөэминова, Мәрзия Фәйзуллиналарның иҗат багажларында «Азат хатын» журналы шактый урын биләп тора. Беренче әсәрләр белән «Азат хатын» аша дөньяга чыккан исемнәр шактый күп, дисәк. Аларның шактыен редакция үзе табып, үзе шефлыкка алып үстерде, дип тә өстәсәк, дөреслеккә хыянәт итмәбездер.

1961 елның җәе иде. Редакциягә бер кыз килеп керде һәм оялып кына безгә шигырьләрен сузды. Беренче шигырен укуга ук каршыбыздагы кызның, язучылар әйтмешли, «өметле» иптәш, ягъни яза ала торган иптәш икәнен аңладык. Бу — төзелештә штукатур булып эшләүче Нәзирә Усманова иде. Журналның чираттагы саны җыелган иде инде. Шулай да без бер мәкаләне төшереп, Нәзирә Усманованың шигырьләрен, кечкенә генә сүз башы һәм үз фоторәсеме белән, журналга урнаштырдык. Аның шигырьләре арасында:

Мастерок белән
Без икәү бергә
Армабыз кебек,
Талмабыз кебек,
Яшәрбез кебек
Җиңеп гомергә, —

дигән юллар да бар иде. Бу юллар Нәзирәнең тормышта үзенә иптәш итеп мастерокны гына түгел, шигъри каләмне дә сайлавы турында сөйлиләр. Һәм менә инде биш ел бүе Нәзирә Усманова безнең белән иҗади элемтәдә яши. Тормышындагы һәм иҗатындагы һәр шатлыгын, һәр борчуын редакция белән уртаклаша. Бу чор эчендә Нәзирә Усманова «Азат хатын» битләрендә ике дистәгә якын шигырь бастырды, Татарстан китап нәшрияты чыгарган беренчә әдәби җыентыкка автор буларак катнашып өлгерде.

Икенче бер яшь шагыйрә — хәзер Чиләбедә эшләүче Салисә Гәрәева турында да шактый күп сөйләргә булыр иде. Минзәлә районы Калмия авылында туып-үскән һәм әле авылыннан беркая да чыгып өлгермәгән ул кызның да әдәби сукмагы «Азат хатын» журналы битләреннән башланды. Без Салисәгә Казанга килергә, университетка кереп, белем алырга ярдәм иттек. Бездә аның дистәләрчә әсәрләре дөнья күрде. Инде хәзер Чиләбедә булса да, элемтәсен өзми, язышып тора ул.

Саба районы Эзмә авылында яшәүче укытучы Заһидә Гомәрова һәм Әлмәт районында яшәүче Клара Булатовалар (хәзер ул Казан университетында укый) нәшриятка үзләренең беренче җыентыкларын тапшырдылар. Аларның ул китапларына кергән шигырьләренең дә күпчелеген укучылар иң элек безнең журналдан укыдылар.

Әгерҗедә яшәүче Һаҗәр Йосыпова бездә өч хикәя бастырып чыгарды. Нефтьче кыз Сария Галиәхмәтова, студенткалар Флера Хәбибуллина һәм Васимә Хәйруллина, укытучы Нурия Муллаева, тегүче-мастер Флера Гыйззатуллина, медсестра Роза Хәлиуллина һәм башка авторларның беренче әсәрләрен укучылар «Азат хатын» аша укып белделәр.

Журналның борын-борыннан килгән бер матур традициясе бар. Редакциянең җаваплы секретарьлары булып шагыйрьләр эшли. Аның беренче секретаре — халкыбызның сөекле шагыйре Һади Такташ иде. Ул киткәч күп еллар танылган шагыйребез Фатих Кәрим эшләде. Бүген редакциянең җаваплы секретаре — яшь шагыйрь Марс Шабаев. Журнал тирәсенә яшь каләмнәрнең тупланууында, әдәби әсәрләрнең мул урын алып торуында бу традициянең әһәмияте, әлбәттә, аз түгел.

Билгеле, бер мәкаләдә генә 60—70 автор турында сөйләп бетерергә мөмкин түгел. Аннары әлегә нибары бер-ике әсәре матбугатта басылып чыккан ул 60—70 авторның һәрберсе дә язучы булып китә алмас, әдәбият сәләтләләрне генә сайлый. Әгәр дә без 60—70 кеше арасыннан дүрт-бише турында ышанып сөйлибез икән, бу — зур эш.

Ләкин безне борчый торган бернәрсә бар. Башлап язучыларыбыз арасында прозаиклар, драматурглар юк диярлек. Хатын-кыз язучыларыбыздан Рәисә Ишморатова белән Гөлшат Зәйнашева гына сәхнә әсәрләре язгалыйлар. Журналга элегрәк матур-матур хикәяләр биргән Һаҗәр Йосыпова, Лена Шәфикова, Фаяза Гатауллиналар да, ни өчендер, сүрелделәр.

Яшь язучы яки яшь шагыйрь, ничаклы гына талантлы булмасын, буш урында, үзлегеннән генә үсеп, заман таләпләренә җавап бирерлек әдәби әсәр иҗат итә алмый. Моның өчен аңа күп укырга, өлкән язучылардан өйрәнергә һәм шулар үрнәгендә талантын үстерергә кирәк. Шуны исәпкә алып, без яшь авторларыбызны күренекле татар язучылары һәм шагыйрьләренең иң яхшы әсәрләре мисалында тәрбияләргә тырышабыз. Журналда даими рәвештә Мирсәй Әмир, Фатих Хөсни, Әмирхан Еники, Ибраһим Гази, Хәсән Туфан, Габдрахман Әпсәләмов, Гомәр Бәширов, Шәйхи Маннур, Сибгат Хәким, Гариф Гобәй, Нәби Дәүли, Сәрвәр Әдһәмова, Ләбибә Ихсанова иптәшләрнең яна әсәрләре басылып тора.

Укучыларыбызны тугандаш халыклар әдәбиятының күренекле проза һәм поэзия үрнәкләре белән таныштырырга онытмыйбыз. Үзбәк шагыйрәсе Зөлфия, башкорт халык шагыйре Мостай Кәрим, кыргыз язучысы Чыңгыз Айтматов һәм башка бик күпләр журнал битләрендә урын тапты.

«Азат хатын» журналын киң Ватаныбызның һәр почмагында диярлек укыйлар. Шулай булгач, Татарстаннан читтә яшәүче өметле каләмнәргә дә безнең белән язышырга мөмкинлек бар. Тугыз еллык тарих нәкъ әнә шул хакта сөйли дә. Башкортстан язучылары Кәтибә Кинҗәбулатова, Фәүзия Рәхимголова, Зәйнәп Биишева, Әлфия Вахитовалар безнең даими авторларыбыз, Мәскәүдән Мәрфуга Шәехова һәм Әширә Кәтиева, Ташкенттан Хәят Җаббарова һәм Кәүсәрия Хәбибуллина, Мордва АССРдан Хафизә Курмаева, Астрахань өлкәсеннән Зөлхәбирә Ишбирдиева һәм башкаларның да әсәрләре журналдан читтә калмады.

Партиянең Үзәк Комитеты журнал чыгу уңае белән җибәргән котлавында: «Журнал эчтәлеге белән, теле белән киң масса укучыларның таләпләренә җавап бирә алса, үзенең ныклы урынын таба алачак», дигән иде. «Азат хатын» журналы, чыннан да, киң масса укучыларның якын дусты, киңәшчесе булып китте. Менә шуңа күрә дә моннан кырык ел элек бер мең данә басылган журналның тиражы бүген 200.000 нән узып китте. Аны илебезнең төрле почмакларында йөз меңнәрчә укучылар яратып укыйлар.

Юбилей көннәренә әзерләнгәндә, журналның иң беренче авторларыннан берсе, Рабига апа Каюмова, «Сезгә ничә яшь?» дип сорагач, шаяртып: «Безгә, «Азат хатын» журналы коллективына, августта нибары кырык яшь тула», — дип җавап биргән иде. Ә кырык ел күпмени ул. Журналның укучылары, авторлары тагын да артыр, аның эчтәлеге тагын да яхшырыр. Моңа барлык мөмкинлекләр бар.

*АСИЯ ХӘСӘНОВА,*
*«Азат хатын» журналы редакторы.*

## СЕЗ ҮЗ ИСЕМЕГЕЗНЕҢ МӘГЪНӘСЕН БЕЛӘСЕЗМЕ?

Шамил — эченә туплаган, җыйган, чорнап алган.
Шафигъ — арага керүче, яклаучы.
Шаһбаз — карчыга, лачын.
Шаһзадә — тәхет варисы.
Шәех — карт, олы кеше, юлбашчы.
Шәкүр — бик шөкер итү.
Шәмси — кояш.
Шәриф — кадерле.
Шәфикъ — шәфкатьле, рәхимле.
Әбрар — изге, яхшы кешеләр.
Әзһәр — ак йөзле, ак чырайлы.
Әкрәм — юмарт, кешене хөрмәт итүче.
Әмин — тыныч, куркусыз.
Әмир — боеручы.
Әндәр — бик сирәк була торган әйбер, хәл.
Әсгад — бик бәхетле.
Әхсән — бик күркәм, бик матур.
Әшрәф — дәрәҗәле, затлы, намуслы.
Өлфәт — аралашу, иплашу, дуслашу.
Җиһан — дөнья, галәм.
Җиһангир — дөньяны буйсындыручы.
Җәвад — юмарт, киң күңелле кеше.
Җәлил — бөек, олы, шөһрәтле кеше.
Җәмал — матурлык, чибәрлек.
Җәмилә — матур, чибәр.
Җәүһәр — кыйммәтле таш, әйбер.
Һади — туры юл күрсәтүче.
Һәдия — бүләк.

# КИТАП КҮЗӘТҮ

## ГАРӘПЧӘ-ТАТАРЧА-РУСЧА АЛЫНМАЛАР СҮЗЛЕГЕ

Бу сүзлекнең[1] төзелү тарихы бик озын. Аны төзү өчен материал җыю эше 1940 елда ук башланган булган. Сугыш елларын һәм сүзлекне төзүчеләрдән К. З. Хәмзин һәм Г. Ш. Сәйфуллин иптәшләрнең язмышларына бәйләнгән объектив сәбәпләрне исәпкә алмаганда, бу сүзлек 12—15 ел буе төзелгән. Ләкин, ничек кенә булмасын, сүзлек хәзер безнең алда. Аның дөньяга чыгуы татар филологиясе өчен зур вакыйга. Ул татар филологларының һәрвакыт кул астында булырга тиешле иң кирәкле сүзлек: ансыз урта гасырларда иҗат иткән татар әдипләренең һәм татар классик язучыларының әсәрләре эченә керү мөмкин түгел. Бу бигрәк тә сугыштан соң үсеп чыккан яшь филологларга карый. Шуны исәпкә алып, сүзлекнең авторлары, татар матур әдәбиятына кергән гарәп һәм фарсы алынмаларының татарча эквивалентын күрсәтү белән генә чикләнмичә, күп сүзләргә матур әдәбияттан оста сайлап алынган иллюстрацияләр (җөмләләр) дә биргәннәр. Шул ягы белән бу сүзлек гадәттәге ике телле сүзлекләр рамкасыннан чыгып киткән һәм аңлатмалы сүзлекләргә якынайган. Сүзлекнең практик әһәмиятен исәпкә алганда, төзүчеләрнең бу алымын хупларга гына кала. Алынмаларның русча эквивалентын бирелү тагын да яхшы, чөнки бу хәл татар классик язучыларының әсәрләрен яки ул әсәрләрнең өзекләрен русчага тәрҗемә иткәндә, тәрҗемәчеләрнең эшен җиңеләйтергә. Бу җәһәттән сүзлекне төзүчеләр зур осталык күрсәткәннәр һәм нык уйлап эш иткәннәр.

Сүзлекнең азагында гарәп һәм көнбатыш Европа телләре белгече М. И. Мәхмүтов тарафыннан язылган «Грамматик белешмә» бирелгән. Сүзлекнең кыйммәтен бу тагын да арттыра.

«Гарәпчә-татарча-русча алынмалар сүзлеге» башкорт язучыларының әсәрләрендә тулып ята, ә инде башкорт шәҗәрәләрендә алар тагын да күбрәк очрый.

Ләкин бу сүзлек татар классик әдәбиятында һәм гомумән иске әдәбиятта кулланылган гарәп һәм фарсы алынмаларын белү өчен генә кирәк икән, дип аңларга ярамый. Ул сүзләрнең бик күп өлеше татарда һәм башкортта берүк дәрәҗәдә көндәлек тормыштагы җанлы телдә дә, әдәби телдә дә адым саен кулланыла. Мәсәлән, **хат, китап, каләм, кәгазь, тәрәзә, келәм, тастымал, хәтта, бәлки, әдәбият, сәнгать, шагыйрь, әсәр, вакыт, заман, хөкем, карар** һәм башка күп гарәп-фарсы сүзләрен кулланып сөйләгәндә, без аларның кайдан алынганын уйлап та тормыйбыз, чөнки андый сүзләр татар теленең лексикасында нык тамыр җәйгән.

Татар әдәби һәм халык теленә килеп кергән гарәп һәм фарсы сүзләренең күбесе, нигездә, элекке заманда гарәп һәм иран (фарсы) цивилизациясе тәэсирендә булган башка төрки халыклары өчен дә уртак. Шул ук гарәп сүзләре фарсы, афган (пушту), таҗик, пакистан, дунган телләрендә дә киң кулланыла.

Татар телендә кулланылган бик күп гарәп һәм фарсы сүзләренең көнчыгыш телләрдә дә шул ук мәгънәдә йөрүе ул сүзләрне интернациональ сүзләр дип атарга нигез бирә. Шуннан чыгып, татар телендә ике төркем интернациональ сүзләр турында сөйләргә мөмкин: беренчесе — Европа цивилизациясе аша килеп кергән интернациональ сүзләр, икенчесе — көнчыгыш цивилизациясе аша килеп кергән интернациональ сүзләр, ягъни фарсы һәм гарәп алынмалары.

Татар теле һәм гомумән татар иле территориаль яктан иң җайлы җирдә урнашкан булган: татар иле дөньядагы ике зур цивилизациянең, ягъни көнчыгыштан борынгы иран-гарәп, ә көнбатыштан, соңгарак, Европа цивилизациясенең килеп очрашкан урынында булган. Татар халкы бу цивилизацияләрнең икесен дә тартынмыйча үзләштергән. Һәм, әйтергә кирәк, башка төрки халыклары арасында Европа цивилизациясе иң беренче булып татарларга килеп кергән.

[1] **Гарәпчә-татарча-русча алынмалар сүзлеге. Төзүчеләре К. З. Хәмзин, М. И. Мәхмүтов һәм Г. Ш. Сәйфуллин. Татарстан китап нәшрияты. 1965 ел. Тиражы 7000 данә. Күләме 45 табак.**

Татарда капиталистик мөнәсәбәтләрнең, бигрәк тә сәүдә капиталының, иртәрәк үсеше исә Европа цивилизациясен үзләштерү белән бергә барган. Шул сәбәпле төрки халыклары арасында татарлар моннан йөз еллар элек үк инде Россиядә экономика һәм культура җәһәтеннән иң алга киткән милләткә әверелгән. Бу хәл, үз чиратында, татар әдәбиятының һәм сәнгатенең Европа культурасының үрнәге белән үсешенә, татар теленең, башка төрки телләренә караганда, иртәрәк фәнни яктан эшләнә башлавына, татар лексикографиясе барлыкка килүгә сәбәпче булган.

Моннан чыгып, яңа басылган «Гарәпчә-татарча-русча алынмалар сүзлеге»н төзүче авторлар татар лексикографиясенең бай тәҗрибәсен һәм традициясен нык исәпкә алганнар, дип әйтәсе килә.

Дөрес, татар телчеләре һәм әдәбиятчылары арасында гарәп-фарсы алынмалары турында төрле карашлар булды. Кайберәүләр ул сүзләрне ислам дине белән бәйләделәр. Нәтиҗәдә, дингә, искелеккә каршы ачылган ут ялкыннары гарәп-фарсы сүзләрен дә яндыра биреп куйды. Күрәсең, биредә гарәп-фарсы сүзләренең килеп керү сәбәпләре ныклы исәпкә алынмаган булган. «Грамматик белешмә»гә язылган кыска гына «Кереш сүз»дә М. И. Мәхмүтов бу сүзләрнең фәкать ислам дине аркылы гына түгел, бәлки борынгы татарларның Урта Азия, Иран һәм башка көнчыгыш илләр белән сәүдә итүе аркасында да килеп керүен әйтеп киткән.

Билгеле, бу турыда ачыграк һәм аерыбрак та әйтергә кирәк иде, чөнки фарсы сүзләренең күбесе татар теленә, шулай ук Урта Азия һәм Кавказдагы башка төрки халыкларының телләренә, һичшиксез, ислам дине таралганга кадәр бик күп заманнар элегрәк килеп кергән, дип әйтергә мөмкин. Әйтик, башкорт тел гыйлемендә хәзер фарсы сүзләренең бер өлеше Урта Азия белән сәүдә итү аша килеп кергән дип карала, чөнки ул сүзләр материаль әйберләрнең атамасын белдерә һәм аларның ислам дине белән берничи уртаклыгы юк. Мәсәлән, **сүмес** (чүмеч), **сыуал** — мичнең бер төре, **тастымал** — фарсыча дәстүрмал (кульяулык) сүзеннән, **сарык, бышым** — аяк киемнәренең төрләре, **сыра** (чыра), **коштабак** — тәүге сүзе гишт (кирпеч) сүзеннән, **сыйнйыр** (чылбыр) — фарсыча зәнҗир сүзеннән, **көкөрт** (күкерт), **келәм, барса** (парча) һәм башка күп сүзләрнең ислам дине белән нинди уртаклыгы булырга мөмкин?!.

Шунысы характерлы, фарсыдан кергән сүзләр арасында хайван исемнәре дә очрый. Мәсәлән: **былбыл, сел-чел** (кош) һ. б. Гарәптән кергән сүзләр арасында хайван исемнәре бөтенләй юк диярлек. Башкорт сөйләшләрендә материаль әйберләрнең исемен белдергән фарсы сүзләре тагын да күбрәк. Бу табигый хәл, чөнки проф. С. П. Толстой үзенең «Древний хорезм» дигән хезмәтендә (25 бит) безнең эраның башларында Урал таулары буенда яшәгән кабиләләр борынгы Кангуй-Хорезм дәүләтенең базарларына җәнлек тиресе китереп сата торган булганнар, дип күрсәтә. Билгеле булганча, борынгы Кангуй-Хорезм дәүләте иран (фарсы) телле ил булган. Башкортстанның Урта өлешендә (Стәрлетамак тирәсендә) безнең эраның III гасырына кадәр иран телле алан кабиләләренең яшәве инде тарихта исбат ителгән хәл.

Борынгы иран цивилизациясенең тәэсире фәкать Урта Азия, Кавказ һәм Идел-Урал буе төрки халыклары белән генә чикләнеп калмыйча, угро-фин халыкларына да барып кергән. Бу телләрдәге иянь (әпәй), **нам** (исем) һәм башка бик күп фарсы сүзләре, һичшиксез, борынгы иран цивилизациясенең гарәп цивилизациясеннән бик күп гасырлар картрак булуы һәм аның чаткылары ерак төньякка кадәр барып житкәнлеге турында сөйли.

«Алынмалар сүзлеге»ндә булган фарсы сүзләренең кайсылары татар теленә һәм аның төрле сөйләшләренә хронологик яктан кайчан килеп керү турында татар телчеләре жентекле, фәнни анализ һәм классификация үткәрерләр, дип ышанырга кирәк.

Соңгы сүз итеп шуны әйтергә кирәк: төзүчеләр тарафыннан бу сүзлек зур мәхәббәт белән эшләнгән, аңа күп көч салынган, һәм ул татар филологиясендә югалмаслык зур бер фәнни хезмәт булып калачак. Татарстан китап нәшрияты аны басып чыгару белән татар культурасы өчен гаять мактаулы эш эшләгән.

**Җ. Г. КИЕКБАЕВ.**
**Башкорт дәүләт университетының профессоры, филология фәннәре докторы.**

—●—

## ӘДӘБИЯТ ТАРИХЫНА МАТЕРИАЛЛАР

*А. Шмаков*

# КӨНЬЯК УРАЛНЫҢ ӘДӘБИ ҮТКӘНЕ

## Карт укытучы янында

Карт укытучы Мөсәлим Әюпович хакында күп тапкырлар ишеткәнем булса да, аның үзен үткән елның көзендә генә күреп сөйләшә алдым. Яше 75 тән ашып китсә дә, хәтере әйбәт икән. Аның күз алдыннан гаҗәеп язмышлар үткән һәм аларның һәркайсы Мөсәлим аганың күңелендә җуелмас эзләр калдырганнар.

Акмулла, Тукай, Гафури, Бабич... Мөсәлим Хәмзин белән кызыксынып киту өчен шушы атаклы әдипләрнең исемнәре дә бик җиткән инде. Мөсәлим Әюпович Хәмзин Курган өлкәсеннән Сафакүл авылында яши. Биредә аңа, ярату һәм хөрмәт йөзеннән, Мөсәлим ага дип кенә дәшәләр. Карт укытучының тормыш юлы чынлап та бик кызыклы һәм революциягәчә чорда түбәннән күтәрелгән башка интеллигентларныкына охшаган. Ялан аяклы малай чагында Мөсәлимне Казандагы Учительская школага җибәрәләр. Хәмзин дә татар культура дөньясына күп кенә күренекле кешеләрне биргән шул мәктәпне тәмамлап чыга. Үз гомерендә аңа күп кенә шәһәрләрдә һәм авылларда булырга, байтак кына кешеләр белән очрашырга туры килә.

Без Мөсәлим аганың кечерәк кенә өендә утырабыз. Тәрәзә артында саргая башлаган бакча. Өлгереп җиткән җимешләр миңа карт укытучының тынгысыз эшчәнлеген хәтерләтә. Ничәмә-ничә күңелләрдә патриотик хисләр һәм хезмәткә мәхәббәт уятkandыр. Ватаныбызга чын-чынлап турылыклы һәм лаеклы ничәмә ничә уллар һәм кызлар тәрбияләгәндер ул! Стенада смычогы каралып, грифы кыршылып беткән скрипка эленеп тора. Скрипка укытучының аерылгысыз юлдашы булган. Бу скрипка аңа, тырышып укуы өчен, мәктәптә бирелгән. Шушы скрипка укытучының кыен хезмәтен җиңеләйткән, аның моңнары балаларның кыерсытылган һәм кырысланган күңелләрендә якты тойгылар уяткан.

Ләкин бүген без Мөсәлим Әюпович белән әдәбият һәм әдипләр хакында сөйләшмәкче идек бит. Алтмыш-җитмеш еллык дәвер тузаны астында калып күмелә башлаган аерым детальләрне, кечерәк-кечерәк вакыйгаларны хәтергә төшерүдә аңа хатыны Фәрзәнә Әмитовна да булышкалый.

Сүз — олы мәгърифәтче, шигырьләре әле дә булса халык арасында телдән-телләргә күчеп йөрүче шагыйрь Акмулла турында.

— Аның әсәрләре, — ди Хәмзин, — дала киңлекләрендә челтерәгән кыңгырау кебек, яңгыравык тавышлы һәм күңелгә якын, кыр чәчәкләредәй саф һәм хуш исләр.

Әлегәчә безнең әңгәмәгә катнашмыйчарак бер читтә басып торган Фәрзәнә Әмитовна да, сүз Акмуллага җиткәч, түзмәде:

— Дөресе дә шул, — диде ул, иренең фикерен раслап. — Шагыйрьнең үзен күргәнем бар минем...

— Әйе, әйе! — ди Мөсәлим Әюпович, горурлана төшеп. — Сөйләп бир әле, Фәрзәнә.

Хатынның йөзендәге җыерчыклар таралып юкка чыккандай була. Күрәсең, бу минутта ул әтисе өендә уздырган бәләкәй чакларын хәтерлидер.

— Буйга озын түгел иде ул, чалара төшкән сакаллы, — дип башлап китте Фәрзәнә ханым. — Мина ул чакта ун яшьләр булгандыр, ә шагыйрьгә — алтмыштан артык. Үзе һәрвакыт бишмәт кия, билендә билбау, башында искерәк кенә гап-гади бүрек, аякларында читек-кәвешләр. Ә күлмәге ап-ак булып истә калган...

Бервакыт, Фәрзәнәнең әтисе Златоуст зимский идарәсендә эшләгән елларда, Акмулла аларның өендә туктала. Бу —шагыйрь тормышының соңгы елында, аның Троицкидан Казанга сәяхәте вакытында була.

— Безгә ул җомга көнне килеп керде,— дип дәвам итте Фәрзәнә сүзен.— Намаз укыды. Күрәсең, ул дин тоткандыр, ә бәлки безнең өйдә эти урнаштырган кырыс тәртипне саклап кына шулай эшләгәндер... Акмулла семьясыз кеше иде. Шунда, өйләнергә уйлыйм, кәләш эзлим менә дип, мине дә шаярткан иде әле.

Фәрзәнә Әмитовна сөякчел куллары белән чаларган башын сыйпап уза, яулык астыннан чыгып торган чәчләрен рәтли:

— Шагыйрьнең юл кибиткасы өч бүлемле иде. Берсендә балта остасына кирәкле эш кораллары, икенчесендә китаплар төялгән, ә уртадагысына ул үзе утыра иде...

Акмулла турында хатыны сөйләгән истәлекләргә Хәмзин үзе нинди дә булса яңалык өстәми, ә менә башка шагыйрьләр турында ул кызыклы гына нәрсәләр белә:

— Мин озак еллар буе Троицкида яшәдем һәм эшләдем. Андагы «Рәсүлия» мәдрәсәсендә Шәехзадә Бабич укыта иде. Ул да бик зур шагыйрь бит. Мин аның шигырьләрендә музыкальлекне яратам. Башкортлар аны үзләренең Пушкиннары дип атыйлар. Бабич 1919 елда һәлак булды. Ул мина Акмулла турында күп кенә нәрсәләр сөйләде, аны, Тукай һәм Гафури белән беррәттән, үзенең укытучысы итеп санавын әйтте...

Хәмзин, фикерләрен бер ноктага җыярга теләгәндәй, бераз вакытка тынып калды, аннан, үзе яшәгән шәһәр белән горурланып, әйтеп куйды:

— Троицк — шагыйрьләр шәһәре. Акмулла шунда яшәде. Гафури, Бабичларның тормышы шушы шәһәр белән бәйләнгән, Әкрәм Галимов шунда эшләде...

Мин карт укытучыга рәхмәтләр укыдым. Үзенең истәлекләре белән ул мина исемнәре Көньяк Урал белән бәйләнгән беренче татар-башкорт язучылары һәм аларның әдәби традицияләре турында кызыклы гына тема тәкъдим итте. Алар хакында тагын да күбрәк беләсем килде.

Үзара килешү буенча, Мөсәлим Әюпович Башкортстандагы танышларына хатлар язарга, Акмулланы, Тукайны, Гафурины һәм Бабичны күреп белгән кешеләрнең истәлекләрен җыярга булды, ләкин ул мина озак вакытлар язмый торды. Күрәсең, үз чиратында аңа да адресатлары тиз генә җавап бирмәгәннәр. Аның хат аша биргән киңәшен тотып, мин чынлап торып урындагы архивларда казынырга, сирәк очрый торган басмаларны актарырга, кыскасы, үземне кызыксындырган тема буенча материаллар тупларга керештем.

Бу мәкалә әнә шушы эзләнүләр нәтиҗәсендә язылды.

## Акмулланы кем үтергән?

Күптән ачылганны кабат ачмас өчен, эзләнүләрне нидән башларга соң? Чиләбедәге җәмәгать китапханәсенең крайны өйрәнү кабинетында табылган материаллар бик аз булып чыктылар. Аның каравы, библиография бүлегендә миңа байтак кына чыганаклар тәкъдим иттеләр. Китапларның күбесе фондта юк иде, аларны Казаннан, Уфадан һәм Свердловскидан алдырырга туры килде. Вакытны югалтмас өчен, мин урындагы архивларга мөрәҗәгать иттем, «Әдәби энциклопедия»не карап чыктым.

Акмулла турында бәләкәй генә биографик белешмә бирелгән. Туган җире — элекке Бәләбәй өязенең Туксанбай авылы, туган елы — 1831, үлгән вакыты — 1895 елның 21 октябре.

Тагын шагыйрь исән чакта аның нибары бер шигыре басылганлыгы, ә үзе үлгәннән соң аның әсәрләреннән төзелгән җыентык чыгу турында әйтелгән. Рус укучысы өчен Акмулла исеме әллә ни күп нәрсә сөйләми. Ә ул кыю һәм талантлы шагыйрь-мәгърифәтче булган, аның тормышы Урал җире һәм аның кешеләре белән тыгыз бәйләнгән. Татарлар, башкортлар һәм казакълар аны, бик хаклы рәвештә, үзләренең уртак әдипләре дип хисаплыйлар, ул үз әсәрләрендә гади халыкның тормышын һәм уй-кичерешләрен дөрес чагылдыра алган.

«Әдәби энциклопедия»нең иске басмасында Акмулланың үз кул көче белән көн

күргәнлеге һәм бөтен мөлкәтенең ат белән арбадан торганлыгы әйтелгән. Хәмзиннәр сөйләве буенча, без инде шагыйрьнең юл кибиткасы турында кайбер нәрсәләр беләбез. Шушы аты һәм арбасы белән ул Троицк тирәсендәге авылларга чыгып йөргән, байлардан һәм муллалардан көлгән, халыкны мәгърифәткә өндәгән, аның көченә ышанган, кешелеклелеккә һәм гаделлеккә дан җырлаган.

Акмулла үзенең озын гомерен күчмә тормыш белән яшәп уздырган, аның әсәрләре тәэсирендә милли язучыларның соңгырак буыннары тәрбияләнгән, ә без халыкның бу талантлы шагыйре турында бик аз беләбез әле. Үзе хакында белүгә караганда, без аның шәкертләрен һәм аның юлын дәвам иттерүчеләрне яхшырак беләбез.

Казакъ чиновнигының доносы белән кулга алынып, Троицк төрмәсенә ябылуы, камерада утырганда да үзен замандашларына караганда күп тапкыр алдан күрүчәнрәк итеп таныткан кыю һәм көчле әсәрләр язуы бүгенге көндә дә Акмулла биографиясенең дулкынландыргыч сәхифәләре булып калмыйлармыни?!

Менә Акмулланың төрмәдә язган һәм «Татар поэзиясе антологиясе»нә кертелгән ике дүрт юллыгы:

Тоткындың, сорасагыз, жае сулай,
Адәми усындайда идәм сынай,
Күрәмсез тирәзәдин мирзаларды,
Үтәде карсымаздан сабай-сабай.

Кәй адәм ун ел ятыр, озак калган,
Эшләре Петербурга озап калган,
Һиммәтле кандай ирләр заегъ булып,
Аягы кисән менән тозакланган.

Акмулланы, төрмә срогын тутырып, Троицкидан Златоуст өязенә кайтып барышлый Миас заводы тирәләрендә үтерәләр. Ничек һәлак булуы әлегәчә ачылып җитмәгән. Бу хакта, юлбасарлар тарафыннан үтерелгән дип, бик томанлы әйтелгән сүзләр генә бар. Архивтан мин бу фаҗигале үлемнең ничегрәк булуын ачыклый торган кәгазьләр таба алмадым. Әмма юлбасарларның талау нияте белән халык яклаучысы буларак даны таралган кешегә һөҗүм итүләренә ышанасы килми. Юлбасарлар, гадәттә, байларны һәм сәүдәгәрләрне үтергәннәр. Шагыйрь исә ярлы булган, аның бөтен байлыгы бер арбага сыеп беткән. Күрәсең, шагыйрьне патша власте һәм аның чиновниклары үтерткәндер, ә юлбасарлар һөҗүме турындагы уйдырма чын үтерүчене яшереп калу өчен кирәк булгандыр.

Халык телендә әлегәчә, Акмулланы рус патшасы үтерткән, дигән риваять йөри. Һәм халыкның бу риваятендә дөреслек тә бар. Мин Мөсәлим Әюповичтан, Акмулланың юлбасарлар тарафыннан үтерелүе дөресме икән, дип сорадым. Ул уйлап та тормастан җавап бирде:

— Әлбәттә, юлбасарлар үтергән. Тик юлбасарлар дигәнебез шул ук патша ялчылары булган. Халык шулай ди.

Акмулла үлә, ләкин аның телләрдән-телләргә күчеп йөргән әсәрләре кала һәм алар 1917 елның Октябренача байларның, руханиларның һәм патша чиновникларының каннарына тоз салып, аларны куркытып торалар.

## Онытылган шагыйрь

Революциягәчә Чиләбедә яшәгән рус шагыйре А. Туркин, яшь шагыйрь Әкрәм Галимов үлгәч, «Голос Приуралья» газетасында болай дип язган: «Мөселман халыкларының тормышы һәм әдәбияты соңгы елларда бик нык алга китте. Белгәнебезчә, Россиядә күп кенә мөселман газеталары һәм журналлары чыга башлады, мөселманнар арасында әдәби исемнәр калкып чыкты, күп кенә мөселман китапханәләре оешты. Болар барысы да гасырлар буе урнаша килгән шартлар аркасында, тегермән ташлары арасында калып, читкә кысып чыгарылган он шикелле, далаларга һәм түбәнлекләргә этәрелгән һәм онытылган, ләкин сәләтле халыкның үз хокуклары, тормышы, алга омтылышы хакында кешеләрчә үз тавышы белән сөйли башлаганлыгын күрсәтәләр». А. Туркин мөселман әдәбиятындагы иң яхшы үрнәкләрнең рус теленә уңышлы тәрҗемәләре булмауны аянычлы хәл дип саный һәм, яшьли үлеп киткән шагыйрь Ә. Галимов әсәрләрен русларның да укый алмавы бик кызганыч, ди. «Шунысы бигрәк кызганыч, —

дип яза Туркин.— ул бит безнен яңашәбездә генә торып яшәде һәм иҗат итте, халкы турында уйлап дулкынланды, ә аны ул бездән әйбәтрәк белә иде. Шагыйрь күпне кичергән халыкның үз баласы иде һәм шуңа күрә аның фикерләре дә үзенчәлекле иде».

Бу мәкалә 1913 елның 15 августында басылган. Аннан соң илле елдан артыграк вакыт үтте. Ә рус укучысы Урал шагыйренең әсәрләрен әле һаман белми. Алар элек тә шагыйрьнең үз милләттәшләренә генә билгеле булганнар, ә хәзер, шагыйрь үлгәннән соң, әлеге әсәрләрнең кабат басылмаулары аркасында, бөтенләй диярлек онытылганнар.

Вакыт шәфкать дигән нәрсәне белми, кайчандыр тормыш юлы буйлап шаулап үткән кешеләрнең эзләрен дә ул кызганусыз юа, юк итә. Әкрәм Галимовның биографиясен язу өчен хәзер төрле җирләрдә таралып яткан аерым фактларны җыярга һәм аларны бер-берләре белән бәйләргә туры килә. Озак эзләнүләр, тикшеренүләр һәм сирәк очрый торган чыганаклар белән танышу нәтиҗәсендә, мин үзенә егерме генә яшь булса да, Троицк шәһәренең культура тормышында шактый зур хезмәт күрсәткән талантлы шагыйрь үткән тормыш юлының әһәмиятле этапларын билгеле күләмдә янадан торгеза алдым.

«Голос Приуралья»дан соң, башкалада чыга торган «Мөселман газетасы» да шагыйрьнең үлемен билгеләп үтә. «Безнең яңа тормышыбыз газаплар аша, коточкыч кыенлыклар белән туа. Көрәсен, ныклап торып аякка басу һәм алга бару юлында безгә күп кенә кыен сынаулар кичәргә туры киләчәктер... Тыныч йокла, яшь шагыйрь. Син безнен бәхетле тормышыбыз таңы атуын көткән идең һәм ул таңның атачагына чын күңелдән ышанган идең. Мөселман дөньясы өстендә аның яктылыгы уйный инде, тиздән без шушы яктылык артыннан шатлыклы кояшның үзен дә күрә алырбыз...»

Әкрәм Галимов үз иҗатында Акмулла, Тукай, Гафурилар традициясен дәвам итә. Ул үзенең Россиядә чыга торган мөселман газеталарында басыла торган шигырьләре белән ишанлык деспотизмын фаш итә, байлар алдында калтырап төшүчеләрдән ачы көлә. Ул драматургия өлкәсендә дә каләм сынап карый. Аның «Май мәсьәләсе яки ахмак мулла» исемле бер пәрдәлек комедиясе бар. Ул шагыйрь үлгән елда Троицк шәһәрендә аерым китап булып татар телендә басылып чыккан.

Бу комедия әле дә онытылмаган. Аны үзешчән сәнгать түгәрәкләре, бигрәк тә авыл сәхнәләрендә, бүген дә булса уйныйлар. Тик авторын гына әйтеп тормыйлар, ул халык авыз иҗаты әсәренә әверелгән.

Ә. Галимов Троицкида чыга торган «Айкап» журналының секретаре һәм шагыйрь Акмулла хөрмәтенә аның исеме белән аталган «Акмулла» журналының даими хезмәткәре булып эшли.

«Акмулла» журналы, Троицк әдәбиятчыларының сатирик органы булып, үзенең характеры белән хәзерге «Крокодил», «Чаян» журналларын хәтерләткән.

Ә. Галимов, яшь кенә булуына карамастан, Оренбургта чыга торган «Шура» журналларында да, Астрахань газетасы «Идел»дә дә еш кына басыла килгән. Үз әсәрләрен ул Чаллы-татар псевдонимы белән биреп барган.

Шагыйрь кайда һәм нинди семьяда туган, аның әдәби иҗат юлы нинди? Троицкига кайдандыр килеп урнашканмы ул, әллә шәһәрнең төп үз кешесеме? Бу сорауларга мин байтак вакытлар җавап таба алмый йөрдем.

Бервакыт, «Ислам дөньясы» журналының 1913 елда чыккан саннарын карап утырганда, күзәтү характерында язылган бер мәкаләгә тап булдым. Казанда чыга торган «Йолдыз» газетасыннан күчереп басылган мәкалә булып чыкты ул. Анда Троицк шагыйренең тормыш юлы һәм эшчәнлеге турында да кайбер мәгълүматлар бар иде. Аның җиденче августта үләнлеген хәбәр иткәннәр. Шагыйрьне соңгы юлга озатуда күп кенә яшьләр катнашкан. Табут өстендәге гасмаларга: «Сөекле шагыйребез Әкрәм әфәнде Галимовка», дип язылган. «Акмулла» һәм «Айкап» редакцияләре үз венокларына: «Яшь язучыбыз һәм шагыйрь Әкрәм әфәнде Галимовка. Авыр туфрагың җиңел булсын», дип язганнар. Ул чакта Троицкида чыга торган рус газетасының редакторы большевик шагыйрь Ф. Сыромолотов та редакциядән махсус вәкил җибәрә. Аларның веногына: «Иртә сулган шагыйрьгә «Степь» газетасы редакциясеннән», дип язылган була.

Каберлектә Вәли Корбанов татар телендә чыгыш ясый, ә «Степь» газетасы вәкиле рус телендә сөйли. Шагыйрьнең үлеме уңае белән «Голос Приуралья» (Чиләбе) һәм «Уральская жизнь» (Оренбург) газеталары да некролог урнаштыралар.

Әкрәм Галимов шигырьләр язу белән генә чикләнмичә, сатирик буларак та

матбугатта актив катнашкан. Троицкида аны аз сүзле, сабыр һәм тыйнак, әмма бик сизгер, алдан күрүчән кеше буларак белгәннәр. Аның җинел һәм матур формада язылган шигырьләре фикер тыгызлыгы белән аерылып торалар. Ул кыска һәм эчтәлекле мәкаләләр яза белгән. «Болар барысы да бу яшь егеткә зур өметләр багларга мөмкинлек бирә иде», дип билгеләп үтәләр газеталар.

Казанда чыга торган «Йолдыз» газетасына язышып торучы укытучы С. Черкасов шагыйрь турында болай дип яза: «Әкрәм әфәнде тумышы белән Кустанайдан иде. Ул Троицкидагы Зәйнулла мәдрәсәсендә укыды. Үзлегеннән уку юлы белән белемен тирәнәйтә барды, рус әдәбиятын да аңлый иде һәм үз гомеренең соңгы көннәренәчә рус теле буенча аерым бер кешенең дәресләренә йөрде. Бер ел эчендә Троицк яшьләре аны яратып та өлгерделәр».

Галимовның әтисе — татар, әнисе кыргыз[1] кызы була.

«Айкап» журналында ул 20 сум хезмәт хакы алып бер елдан артык эшли, ә «Акмулла»дагы шигырьләрен гонорарсыз гына бастыра.

«Ярлы яшәсә дә, ул беркайчан гонорар сорамады. Ярлы тормыш һәм чамадан тыш эшләү аркасында, ул авыруга дучар булды һәм шул ук нәрсә аны каберга дә алып керде. Мәрхүм кыргызча да яхшы белә һәм бу телдә дә шигырьләр, мәкаләләр яза иде. Үзенең «Егетлек җимешләре» исемле җыентыгына ул Тукай шигырьләрен дә кертә. Күптән түгел аның Кустанай картлары тормышын сурәтләп язылган «Май мәсьәләсе» исемле комедиясе басылып чыкты. Мәрхүм хезмәт сөючән кеше иде. Кайбер көннәрдә ул иртәнге бишләргә кадәр «Айкап» конторасында утыра һәм бөтен эшне, хәтта аерым саннарны җибәрү кадәресен дә үзе башкара торган иде. Мескен Әкрәм әфәнде, үзен аңламаган һәм аның талантына тиешле бәяне бирә белмәгән кешеләрнең изүе аркасында, хыялларының берсен дә тормышка ашыра алмыйча вафат булды. Бирелә Г. Тукай сүзләрен китерү урынлы булыр: «Бармыни бездә гомумән чын кеше кадерен белү?!»

Татар һәм башкорт әдәбиятларына нигез салучылар булып танылган, шушы әдәбиятларның алтын фондына кереп калган Акмулла, Гафури, Тукай, Бабич һәм әлегә исеме бик үк билгеле булмаган шагыйрь Әкрәм Галимов бер үк олы юлның аерым этапларын тәшкил итәләр. Чөнки бу юлдан гел олы, танылган әдипләр генә узып тормады бит, арада әдәбиятка чын күңелдән бирелгән, ләкин тегеме, бумы сәбәп аркасында онытылып калган яшьләр дә бар иде. Аларның һәркайсы көченә һәм талантына күрә безнең күп милләтле уртак культурабыз хәзинәсенә үз өлешен кертте.

Без аларның да исемнәрен онытмаска тиешбез. Алары да безнең тарихыбыз, безнең рухи байлыгыбыз лабаса. Татар һәм башкорт язучыларының күбесенең яшьлеге дала шәһәре Троицк белән бәйләнгән һәм аның әдәби тарихында гүзәл сәхифәләр булып торалар. Бу хәл безгә үз шәһәребез белән хаклы рәвештә горурлану хокукы бирә.

## Чиләбе—культура учагы

«Китап — бер буынның икенче буынга васыяте ул», дигән Герцен. Әнә шушы рухи васыятьтән тулырак файдалану теләге белән, кешеләр китапханәләр оештырганнар.

Чиләбе татар-башкорт китапханәсе 1906 елда ачылган. Сакланып калган басма отчетларга һәм каталогларга карап, аның беренче елларда ничек эшләвен, аерым кешеләр бүләк иткән акчага җыелган китаплар фондының байлыгын күз алдына китереп була. Күбесе тарихи һәм дини китаплар. Хәер, рәсми отчетларда шуннан артыгын күрсәтү ярамагандыр инде. Калганын жандармерия кәгазьләреннән тапсан гына...

Бу — Х. Ямашев оештырган «Урал» газетасы чыккан еллар. Газета үз битләрендә бик әһәмиятле политик мәсьәләләрне күтәрә, В. И. Ленин хезмәтләрен басып чыгара. Шуңа күрә ул тиз арада халыкның мәхәббәтен яулап ала, авторитет казана. Редакция шул ук вакытта, газетаның кушымтасы төсендә, Маркс тәгълиматын пропагандалый торган брошюралар да чыгара. Китапханә каршында бер группа булып оешкан «аңлы татарлар», ягъни халыкның революцион өлешен тәшкил итүчеләр, ул брошюраларны татар һәм башкорт хезмәт ияләре арасында тараталар.

Чиләбе дәүләт архивындагы татар-башкорт китапханәсенә кагылышлы документларны актарып карыйк. 1911 елның 8 августында китапханәдә тентү була һәм М. Гафу-

[1] Революциягә кадәрге матбугатта казакъларны да кыргыз дип йөрткәннәр. *Редакция.*

рины байтак кына китаплары конфискацияләнә. Бу хакта жандармнар кулы белән төзелгән беркетмәдән түбәндәгеләрне белергә мөмкин:

«1. «Үги балалар» («Пасынки») — Уфада яшәүче Гафуров әсәрләре, әниләре үлеп ятим калган һәм үги ана кулында газап чигүче балалар турында киная белән язылган хикәя. Алга таба шундый изелү астында яшәүче мескен үгиләр хәлендә аерым шәхесләр генә түгел, ә бөтен бер милләт тә калырга мөмкин. Россиядә яшәүче мөселманнар да шундыйларга керәләр, дигән фикер үткәрелә. 2. «Милләт кайгысы» («Забота о нации») һәм шунда ук «Яшь гомерем» («Моя молодость»). Мөселманнар тормышыннан алып язылган төрле вакыйгаларны сурәтләгәннән соң, автор халыкны берләшергә өнди. Тенденцион эчтәлекле китап. Гафуров әсәрләре».

М. Гафури әсәрләре рәсми төстә тыелган булсалар да, китапханә аларны яңадан таба һәм пропагандалый.

Чиләбе татар-башкорт китапханәсе, Гафури әсәрләре белән рәттән, азатлык өчен көрәшкә өндәүче, революцион фикер таратучы башка язучылар әсәрләрен дә пропагандалауны дәвам итә.

М. Гафури әсәрләрен конфискацияләү хакында төзелгән шул ук жандарм беркетмәләрендә китапханә киштәләреннән үзләренең исемнәре белән үк «тенденциоз эчтәлекле» башка әсәрләр дә алынганлыгы әйтелә. Ләкин, бер яктан жандармерия китапханәдән үзенә ошамаган китапларны ала торса, икенче яктан шул ук китаплар яңадан киштәгә менеп урнашалар, халык аларны һаман укый. Кыскасы, китапханә ут белән уйный. Күрәсең, бу культура учагының эшенә кемнеңдер көчле ихтыярлы кулы житәкчелек иткәндер.

Китапханәдә полиция тентүләреннән соң күп тә үтми «Вакыт» газетасы (Оренбург) Чиләбе китапханәсендәге китапларның каталогын бастырып чыгара. Бу — бик кызыклы документ. Анда, дини китаплар белән берррәттән, М. Гафури һәм башка татар әдипләренең әле генә телгә алынган әсәрләре дә санап кителгән. Әйтерсең, аларга жандарм кулы бөтенләй кагылмаган да.

«Урал» газетасы ябыла, аның нәшире һәм редакторы Х. Ямашев эзәрлекләүләр астында яши. Хәтта язучы Галиәсгар Камалның Казандагы «Мәгариф» кибетеннән дә «Урал» газетасы һәм ул чыгарган брошюралар конфискацияләнә. Ә шул ук вакытта Чиләбе китапханәсендә бу газетаны һәм брошюраларны һаман укыйлар.

Каталог китапханәдә «Урал»ның 1907 елгы саннары бар икәнен хәбәр итә. Каталогтан күренгәнчә, китапханә киштәләрендә рус язучыларыннан Пушкин, Гоголь, Тургенев, Чехов, Горький, Мамин-Сибиряк әсәрләренең Казанда чыгарылган татарча басмалары да байтак була. Шунысы кызыклы, китапханәдә хәтта Л. Толстойның да шактый күп әсәрләре булган. Ә бит нәкъ шул чорда инде реакцион даирәләр Толстойны төрлечә хурлыйлар, аның өстенә һәртөрле юллар белән пычрак атарга маташалар.

Җирле властьлар каршында бу китапханәнең абруе бик түбән була. Жандармерия документларында ул «җирле татар һәм башкорт халыклары арасында фетнә тарату урыны» дип бәяләнә һәм һәрвакыт күзәтү астында тора. Аны берничә мәртәбә ябалар, штрафка тарталар. Һәм бу «Урал» газетасы яки ул чыгарган брошюралар аркасында гына түгел. Китапханәдә В. И. Ленинның да аерым хезмәтләре булган. Мәсәлән, аның РСДРПның берләшү съезды турында доклад (Петербург эшчеләренә хат)» исемле китабы. Сирәк очрый торган бу китапның берсе әле дә булса Чиләбе җәмәгать китапханәсендә саклана. Аңа «Чиләбедәге бушлай эшли торган мөселман китапханә — уку залы»ның штампы сугылган.

Чиләбе большевикларының кайсысы бу китапханәнең эшчәнлеге белән тыгыз бәйләнештә торган соң? Хәзергә шулкадәресе билгеле: китапханәнең мөдире А. Хәкимов тыелган китаплар тотуы өчен 1913 елда хөкемгә тартыла. Ул шәһәр партия оешмасының эшендә актив катнашып килүчеләрнең берсе — укытучы И. В. Мальгин белән бәйләнештә тора. Соңрак бу бәйләнеш шушы китапханәне оештыруда катнашкан Ш. Сәлимов аша тормышка ашырыла (Ш. Сәлимов 1917 елда большевиклар партиясенә керә, Чиләбедә колчакчылар терроры вакытында һәлак була).

Болар барысы да үз вакытында китапханәнең бик зур һәм файдалы эш алып баруы хакында сөйлиләр. Һәм без аларны онытмаска, ә онытканнарын хәтеребездә яңартырга тиешбез. Совет властеның 50 еллык һәм В. И. Ленинның 100 еллык юбилейлары алдында торганда, мондый нәрсәләрне истән чыгарырга хакыбыз юк безнең.




*Касыйм Хәмзин*

# ПРОБЛЕМАЛЫ ДӘРЕС

*Хикәя*

Мәктәп директоры Мохтар Мохтарыч ымлап кына мине үз янына чакырып алды да, кайнатасы алдында тел яшергән борынгы яшь килен шикелле:

— Мәгариф бүлегеннән инспектор килде, Җамали, дәресегезне проблемалы итеп корыгыз, күбрәк күргәзмә әсбаплар булсын. Дәрес планыгыз бардыр бит, булмаса, тиз генә сызгалагыз, — диде.

Күп сөйләшеп тормадык. Мәсьәлә ачык иде. Ул үз кабинетына, ә мин озын коридор буйлап, уйлана-уйлана, класска таба киттем. Тик бер нәрсәне генә төшенеп җитә алмадым: ни өчен Мохтар Мохтарыч чакырылмаган кунакның килүен кисәтеп куйды? Мин, нәрсә, күргәзмә дәрес бирергә тиешме?

Әйе, аның бит өлгереш турында отчет бирәсе бар. Булса соң?

«Ярар, күп лыкылдама, директорның көндәлек планында шулай язылгандыр», — дидем үземә үзем, Мохтар Мохтарычны инспектор һөҗүменнән яклап. Шулай да әлеге кунакның килүе шикләндерә. Мин бүгенге дәресемне ситуацияле проблема нигезендә үткәрү турында уйланып, башымны түбән иеп класска кердем.

5 нче «б» классында борынгы тарих дәресе иде. Кыска гына аңлатма биреп, тиешле сораулар куйгач, «Балалар, җавапны китапның менә шушы битеннән эзләгез, йомгакны үзегез ясыйсыз», — дидем.

Минем әйтүем булды, укучылар, чәчәккә сарган бал кортлары кебек дәреслек битенә иелеп, эзләнә-укый башладылар. Беренче минутта ук класста эшлекле шарт туды, стенада — тарих карталары, таблицалар, дәрес өчен кирәкле картиналар. Дәресемне төрле-төрле юллар белән үтемлерәк, кызыклырак, проблема нигезендә үткәрергә тырыштым.

— Кәбир, такта янына чык, әнә шул картадан Мисырның борынгы шәһәрләрен күрсәт.

— Ә син, Зәкия, әнә теге таблицалардан фиргавеннәрнең пирамидаларын карый тор, иң зур пирамиданың буен, иңен, биеклеген хәтерлә, кинди фиргавеннеке?—дидем

кечкенә генә кызга карап. Зәкия туп-туры басып алга үтте, үзе ул бигрәк тә кечкенә, бигрәк матур, әйтерсең, зур бер магазинның тарәзә арасына ясап куелган курчак.

Такта янына чыккач, ул, табәнәк эскәмиягә басып, әлеге пирамидаларны карый башлады.

Өченче укучыны урыныннан чыгармый гына аягүрә бастырдым да:

— Әйт әле, Камил, мумия нәрсә ул? — дидем.

Укучым торып басты да иләс-миләс як-ягына карана башлады.

«Нәрсә соң ул?» дип, соравымны кире үземә кайтарды һәм тынып калды. Иптәшләренә каранды, янәшә утырган малай иреннәрен җәеп кыймылдатса да, мәгънә чыкмады.

— Утыр, — дидем.

Камилнең күңелсез генә утыруы булды, дәррәү кырык кул күтәрелде. Хәтта табәнәк эскәмиягә баскан Зәкия дә кечкенә генә кулын күтәрде.

— Я, әйтеп кара, — дидем ак чырайлы малайга.

Укучы урыныннан тиз генә торды да пулеметтан сиптергән кебек тезә дә башлады:

— Мумия — ул ташка әйләнгән фиргавен. Эчләрен алалар да кабыгын ислемай, спирт, тоз белән юалар, унҗиде кат акбүзгә төреп киптерәләр, саркофагка салалар да пирамида эченә куялар, ошамаса, чыгарып күмәләр.

Үз нәүбәтләрендә такта янына чыккан укучылар да дүртнә һәм бишкә генә сөйләделәр, башкалар да аптырап тормадылар, үзем дә матур итеп сөйләдем, һәм бөтен эшкә дирижерлык иттем.

Мисыр патшасы фиргавен Тутмос Өченченең яулап алуын бик бирелеп кенә сөйләгәндә, арткы партадан бер кыз килбәтсез кычкырып-чырылдап җибәрде.

— Нәрсә булды, нигә акырасың? — дидем сөйләвемне өзеп.

Кыз кулы белән аркасын уа, рәнҗеп Искәндәргә карый.

— Әнә, җуләр, итек инәсе белән чәнчеп утыра.

Моннан алда, дәрес башланганга күп булса ун-унбиш минут үткән арада, Искәндәр ике күгәрчен очырып, бер кызны кычкыртып өлгергән иде инде. Ул дүртенче класста икс ел, бишенчедә икенче ел утыра. Ярыйсы гына буйлы үзе, кырык икенче номерлы кирзовый итек киеп йөри.

— Ах, оятсыз, бир инәне!

Искәндәр бер дә кызармады, селкенмәде дә.

— Син үзең оятсыз, — диде ул һәм кулына тоткан муштук сыман нәрсәне әйләндерә-әйләндерә карый башлады. Мин, электр тогы суккан кебек, телсез калдым. Нәрсә әйтергә дә белмәдем. Бит уртам, колак яфракларым кызышып китте. Укучылар тавышсыз-тынсыз миңа төбәлгәннәр. Аларның йөзендә ниндидер борчылу сизелә, унбиш яшьлек бер малайның минс хурлавы аларга да кимсетү булып тоелды.

Ни булса да булыр. Мөмкин кадәр катырак тавыш белән:

— Бир инәне! Нах-халл!!! — дидем һәм аяк тибеп куйдым. Искәндәр башын да күтәрмәде, аска караган килеш рәсем ясап утыра бирде, ул элеккедән дә тынычрак иде, һич кабаланмыйча, ашыкмый гына:

— Син үзең нах-хал! — диде. Мин инде хәзер бөтенләй тартадан чыктым, түзәрлек, үземне үзем тотарлык чамам калмады. Иөрәк төбендә нәрсәдер кылт итеп киткәндәй булды. Кан тамырларым кабарды, аяк буыннарым йомшарып китте.

Фиргавеннәр, пирамидалар, мумияләр баштан очты, бөтен план чәлпәрәмә килде. Мин әкрен генә өстәл читенә тотынып урындыкка утырдым.

Балалар бер Искәндәргә, бер миңа карыйлар, мин тавышымны артык күтәрми генә:

— Инәне бир, үзең хәзер үк класстан чык! — дидем.

— Класстан куарга хакың юк, — диде Искәндәр.

— Мин сине укытмыйм, чык класстан!

— Укытмаска хакың юк, уку бездә мәҗбүри.

Сөйләшеп тору мәгънәсез иде, кан тамырларым тагын кабара башлады. Кулыннан тотып чыгарыйм дип, мин Искәндәргә таба атладым. «Мин ир кеше, унбиш яшьлек малайны чыгарырга гына көчем җитәр әле», — дидем күңелемнән.

Ике генә адым атлаган идем, малай урыныннан торды, зур итекләре белән бер парта тактасыннан икенче парта өстенә сикереп тә төште. Мин аның артыннан киттем. Үзе йөгерә, үзе сикерә, үзе: «Куып чыгарырга хакың юк», — дип сөйләнә.

Малай ишек катына бармый, парталар арасында әйләнә, мин идәндә, ул югарыда, озын ботлары белән партадан партага бер генә атлый.

Класс старостасы, миңа ярдәм итү теләге белән, Искәндәрнең юлына аркылы төште.

— Җамали абый, хәзер тотабыз үзен!

Искәндәр: «Якын килмәгез! Урам үзегезне!» — дигән иде, вожатый, звено башлыгы, класс газетасының редакторы, редколлегия членнары, санитарлар күтәрелделәр, аларга калган укучылар да кушылдылар, ике минут эчендә Искәндәрне ишек янына бөгәрләп тә салдык. Ул озын Гулливер шикелле гыжлап тибенә-тибенә идәндә ята, — староста аның өстенә атланган, без, өлешеп, аның кесәсеннән ина белән муштук, папирос, шырпы алабыз. «Массага каршы барма икенче!» — диде староста. Нәкъ шул минутта класс ишеге ачылып китте. Мәктәп директоры Мохтар Мохтарыч белән әлеге инспектор-методист күзләрен уйнатып класска килеп керделәр.

— Бу ни бу? — диде директор.

— Борынгы тарих дәресе, Мохтар Мохтарыч, әлеге Искәндәр Исмәгыйлев, шул... менә, безобразие, фиргавен, бөтен ситуацияне үзгәртте... каһәр...

Директор методистка, ә ул, үз нәүбәтендә, директорга карый.

— Сездә яңа методмы әллә бу, Җамали Җамалиевич, ә? — ди инспектор чәнчеп.

— Әйе, юк, ы... ы...

Староста Искәндәр өстеннән төшәргә өлгермәде. Малайларның кәефе хозур, дәрт кузгалган, ике малай җиңнәрен дә сызганып өлгергән, әгәр дә Искәндәр кузгалса яки килешмәгән берәр сүз ычкындырса, ярсыган әтәчләр шикелле, укытучыны якларга әзер торалар иде. «Масса белән икенче булышма!» — диде староста Искәндәрнең башын идәнгә бөгеп.

Укучылар теләр-теләмәс кенә урыннарына барып утырдылар. Директор, Искәндәрнең никдилеген яхшы белгәнгә, озак сөйләшеп тормады. Ишек ягына күрсәтеп:

— Әйдә минем белән, — диде.

— Ә сез дәресегезне дәвам итегез, — диде миңа, әллә нинди чуар күз белән карап.

— Дәресегез беткәч, директор кабинетына!.. — диде методист.

— Яхшы, Мария Ивановна, аңладым, — дип калдым мин.

Берничә минуттан дәрес үз калыбына салынды, укучылар әле генә булган хәлне оныттылар да кебек. Тик минем башымның кайсыдыр өлешендә, фиргавен сурәтләре белән чуалып, мәктәп кагыйдәсе, ә икенче өлешендә Мохтар Мохтарычның директорлык хокукы, Искәндәр Исмәгыйлев һәм башка шундый тормыш ваклыклары чагылып киттеләр.

—•—

# *Укучылар иҗаты*

*Р. Димская*

## Урал әкияте

### I

Борын-борын заманда бер патша булган.
Порт тирәсе куе яшел бакча булган.
Төрле җимеш пешкән чакта бакчасында
Саклар өчен корал аскан сакчы торган.
    Патшаның бер кызы буланазлы, иркә
    Беркөн болай ди шаян кыз көлә-көлә:
    «Әткәй, беләсеңме миңа нәрсә кирәк? —
    Яңа пешкән җиләк тапсыннар бер чиләк».
Патша кызы, билгеле, үзсүзле бала.
Атасы бу сүзгә бик аптырап кала:
«Кайдан алыйк, кыш бит хәзер, үсми җиләк»,
Кыз тәтелди: «Җиләк кирәк, җиләк кирәк!..»

### II

Чакыралар белгечләрне, галимнәрне,
Бакчачыны, вәзирләрне, хаднмнәрне.
Патша әйтә: «Үтәгез, ди, кызым сүзен.
Асармын, — ди, — юкса һәлак була кызым».
    Киңәшәләр: «Моңа ничек әмәл табыйк?..
    Яңа пешкән җиләкне без каян алыйк?..
    Каян табыйк, җәй түгел бит, кыш бит хәзер...
    Табалмасак асалар бит, нишлик хәзер?!.»

### III

Бакчачының өе тулы бала-чага...
Һәм арада үсә тагын бер кыз бала.
Ул кыз ятим: ата-анасы күптән үлгән.
Үзе үткен, күп укыган, гыйлем белгән.
    Бакчачы карт өйгә кайта хәлсез, телсез.
    Бу кыз сорый: «Бүген нигә син күңелсез?».
    Бакчачы карт балаларын җәлли-җәлли,
    Яшермичә сөйли Сарайдагы хәлне.

### IV

    Яшь кыз утыра төн буена китап белән.
    Уйга чума, ул баш вата хисап белән:
    Укып карый, сынап карый — җиләкләрне
    Ничек өлгертергә дигән исәп белән.
Икенче көн керә кыз карт бакчасына, —
Исе китә бакчачының ак чәченә
Кайгысыннан бакчачының чәч, сакалы
Агарган, ди, йөзе сулган, беткән хәле

«Мин асылсам, балаларым калыр үксез, —
ди бакчачы, үлем кѳтә инде шиксез. —
Кем баласы кемгә тансык, кемгә кирәк?..»
Ә кыз әйтә: «Шулар инде синең терәк.
Без хәзер үк эшкә башлыйк! Чиләкләр тап.
Безгә хәзер кышын җиләк булдыру шарт.
Әмәл таптым, серен таптым китаплардан:
Ашламалап су сибәбез аңа кат-кат...
Карт ышанмый. Ә шатланган бала-чага
Кѳн буена су ташыйлар чаба-чаба.
Акыллы кыз ачы күз яшьләрен бѳркә,
Җиләкләр пешкәнен ѳмет белән кѳтә.

## V

Тѳнгә хәтле су ташыгач хәлдән таеп,
Бакчачының гаиләсе йоклый арып.
Йокламый тик сәләтле кыз гына бары,
Йоклый патша, йоклый кызы, йоклый халык...

## VI

Иртә белән ни күрсеннәр: кояш балкый,
Әллә кайчан торган инде шәһәр халкы.
Бар да патша Сараена табан атлый:
Бала-чага, хатын-кызлар, яше, карты.
Патша сабырын җуя — вакыт үтә, үтә...
Ә үзсүзле патша кызы җиләк кѳтә.
Бакчачы карт һәм үги кыз, тотып чиләк,
Китерәләр шунда яңа пешкән җиләк.
Бакчачыны кѳчкә генә таный халык:
Ул картайган, йѳзе сулган, үзе арык.
Патша әйтә: «Менә, кызым, сиңа җиләк,
Рәхәтләнеп туйганчы аша, бер чиләк!»

## VII

Ә бакчачы: «Тукта, түзсен беразга, — ди, —
Башта рәхмәт әйтсен менә бу кызга, — ди, —
Җиләкләрне ул ѳлгертте бакчабызда —
Кыш кѳнендә җиләк булды синең кызга.
Әгәр, шаһым, сезгә бала булса кыйммәт, —
Безнең ѳйләргә дә бала — газиз зиннәт...
Инде мине эшемнән син азат ит, — ди, —
Сиңа хезмәт итү — безгә газап тик, — ди. —
Синең кызга кыш кѳнендә җиләк тансык,
Тик ятудан нишләргә дә белми ярсып...
Яшәү ѳчен азык табу ансат түгел,
Ашау ѳчен яшәү безнең максат түгел!»

— — ✦ — —

# Укучылар сүзе

Өлкән язучыбыз Гариф Гобәйнең «Коръән серләре» исемле повесте журналыбызда басыла башлау белән редакция исеменә һәм авторга укучылардан хатлар килә башлады. Хат авторларының күбесе «Коръән серләре»н мактап, аның бик кирәкле һәм файдалы әсәр булуын әйтеп язган. Кайбер хатларда исә бу повесть белән килешмәү сизелә, автор адресына әйтелгән усал гына сүзләр дә очрый. Соңгысы аңлашыла, әлбәттә. Диннең нигезе саналган, динчеләр алла үзе иңдергән дип исәпләгән «Коръән»не башыннан ахырына кадәр фаш иткән бу повестьны әле һаман да дингә ышанучыларның яратмавы бик табигый (дөрес, хатларда алар динле булуларын әйтмиләр, яшерәләр; ләкин хатның эчтәлеге мәгълүм дәрәҗәдә моны сиздереп тора).

Без бу санда укучыларыбызның «Коръән серләре»нә карата язган берничә хатын урнаштырабыз.

Мин — революциягә кадәр кадими мәдрәсәдә алты ел муллалыкка укыган кеше. Ә революциядән соң совет мәктәпләрендә кырык ел укытучы булып эшләдем һәм шул ук вакытта халык арасында атеизмны пропагандалау белән дә шөгыльләндем. Хәзер мин пенсиядә. Ләкин һаман да, халык алдында лекцияләр укып, атеизмны пропагандалавымны дәвам итәм.

Әле шушы көннәрдә районыбыздагы татар авылларында «Коръәннең чын йөзе» дигән темага лекцияләр укып кайттым. Бу эштә миңа язучы Гариф Гобәйнең «Коръән серләре» исемле повесте бик нык ярдәм итте. Лекцияләремдә мин аның бу әсәреннән дә мисаллар алып сөйләдем һәм соңыннан тыңлаучыларның үзләренә дә аны укып чыгарга тәкъдим иткәч, аларның күбесе:

— Укыдык, бик яратып, теләп укыдык! — дип җавап бирделәр.

В. И. Ленин: «Атеизмны пропагандалау буенча бу массаларга бик күп төрле материал бирергә, аларны тормышның төрле-төрле өлкәләреннән алынган фактлар белән таныштырырга кирәк, аларны кызыксындыру, аларны дини йокыдан уяту, аларны төрле яклардан, төрле-төрле ысуллар белән селкетеп алу һ. б. ш. өчен, аларга тегеләй дә, болай да якын килергә кирәк»[1], дигән иде.

Менә шул җәһәттән килеп карaганда, Г. Гобәй бу повестен язып бик әйбәт иткән дияр идем мин.

Халыкны дини хорафатлардан арындыру өчен, лекцияләр уку, брошюралар бастырып чыгару белән беррәттән, «Коръән серләре» кебек әсәрләрне дә күбрәк язарга кирәк. Андый әсәрләрне халык кызыксынып укый һәм шул ук вакытта диннең асылын да ачыграк аңлый төшә.

Х. ВАХИТОВ,
Свердловск өлкәсе.

●

Мин, «Казан утлары» журналын чын күңелем белән яратып укучыларның берсе буларак, шушы хатым аша язучы Гариф Гобәйгә рәхмәт әйтергә телим. Аның «Коръән серләре» исемле повесте минем өчен аеруча кыйммәтле, чөнки бу «серләр» миңа бик зур йогынты ясадылар. (Башка укучылар өчен дә шулайдыр дип уйлыйм.) Миңа 28 яшь. Моңа кадәр миңа Коръән «серләре» белән танышырга туры килмәгән иде әле, ә дини китапларны изге бер хезмәт дип аңлый идем. Ул китапларның никадәр агуларлык дәрәҗәдә начар икәнлекләренә ышанып та җитми идем.

Менә нинди икән ул дини китаплар! Әкиятнең әкияте! Гариф Гобәй бу әсәрендә диннең агу икәнлеген шул кадәрле урынлы һәм нигезле исбат иткән, аны укыгач, мин тормышымда бер баскычка югарырак күтәрелгәндәй булдым.

С. МӘСӘЛИМОВ,
Пермь өлкәсе.

---

[1] В. И. Ленин. Әсәрләр. Дүртенче басмадан тәрҗемә. Казан. 1963 ел. 214 бит.

Шушы көннәрдә язучы Гариф Гобәйнең «Коръән серләре» дөньяга килеп бик яхшы итте. Әле ахырын уку бәхетенә ирешкән юк, ләкин хәзердән үк әйтергә була: язучы бик тә изге эш эшләгән. Аңа рәхмәттән башка сүзебез юк. Бу повесть фәнни-атеистик әдәбият кытлыгын каплады, дисәк тә хата булмас.

Повесть материалларының берелеше белән дә мактауга лаеклы, бик ансат укыла. Инде Татарстан китап нәшрияты аны зуррак тираж белән китап итеп чыгаруны да тизләтсә, тагын да яхшырак булыр.

**Д. МӘҺДИЕВ,**
журналист.
Башкортстан, Мәчетле районы,
Б. Устьинское авылы.

●

Кадерле редакция!

Мин сезнең «Казан утлары» журналына ел саен язылып киләм һәм яратып укыйм. Узган елларда «Ак чәчәкләр» романын бик кызыксынып укыдым, ә быел сез «Коръән серләре» дигән нәрсә бастырасыз, шуны укып барам. Безнең авыл җирендә хәзер мәчет тә, чиркәү дә юк, Коръән турында уйлаган кеше дә юк. Казанның үзендә мәчетләр бардыр. Сез ул язмаларны шунда илтеп бирегез, бездә аны укучы кеше юк. Безнең бит татар язучылары бик күп, төрле хикәяләр яки кешенең күңелен тарта торган очерклар яза алмыйлармыни? Кадерле редакция, мин сездән үтенеп сорыйм, узган елдагы шикелле, «Ак чәчәкләр» кебек яхшы язмалар бастырсагыз иде. Бу муллалар, аллалар турында «Азат хатын»да да, «Казан утлары»нда да укып, туеп беттек инде.

Сәлам белән, **ХАТИМ ШӘЙДУЛЛИН.**
Мамадыш районы.

●

Гариф Гобәйнең «Коръән серләре»н көчәнеп-көчәнеп булса да укып барам. Тарихи моментларны ялгыш бирү турында сүз иkенче тапкыр куелыр. Әлегә мин аңламаганы: Коръән сүрәләрен татар телендә бирүендә. Янымда Саблуков Коръәне, Крачковский Коръәне, татарча — руби логать, ләкин, автор күрсәткән аятьнең Коръәндәге кайсы аятькә туры килгәнен табу читен. Бу аятьләрнең исемнәрен татарчага әйләндерүдән максат нәрсә икән? Укучының башын әйләндерүме, яисә укучыга җиңеллек ясаумы?

Әгәр автор аять, бит номерларын чагыштыруга теләүче кеше тапсын өчен язса — ул чагында, аять исемнәре гарәпчә бирелеп, бит номеры күрсәтелергә кирәк иде. Ул булмаганда, аны бирүнең ни кирәге бар? Автор, бәлки, һәр кешедә Баранов сүзлеге бар дип уйлый торгандыр. Әле ул булганда да, өстәвенә, өстәлеңдә русча-татарча сүзлекнең булуы шарт. Г. Гобәйгә тәүсия: аять исемнәрен гарәпчә бирергә. Татарчасы бик кирәк дип саный икән, ул вакытта җәя эчендә күрсәтсен.

**ӘХӘТ БУЛАТОВ,**
Татарстан китап палатасы директоры.

●

Без, әдәбият сөючеләр, бу журналны бик яратып укыйбыз. «Казан утлары» исеме бирелгәч, безнең аңа мәхәббәтебез тагын да арта төште. Бу елда журналны алучылар саны артты. Ләкин безне журналда басылган кайбер нәрсәләр канәгатьләндерми.

Алыйк Г. Гобәйнең «Коръән серләре» повестен. Ул повесть түгел. Гобәй безне наданнар һәм сукырлар ди торгандыр. Алай икән, ул ялгыша. «Коръән серләре» повесте әдәпсез сүзләр белән тулган, ул оятсыз сүзләрне укыйсы килми. Коръәнне исә без укый белмибез, укыганны ишеткәнебез дә юк, шулай булгач, аның турында язып торуның кирәге дә юк. Хәзер исә «Казан утлары» юк нәрсә белән көрәшә түгелме соң? Картаеп беткән карт-карчыклар аз-маз динне беләләр икән, алар аны укыган. Аларның вакыты узган инде. Безне дингә өндәүче юк. Без хәзерге заман культурасына сокланабыз. Без илдә коммунизм төзүчеләр. «Казан утлары» — матур әдәбият, без аны яратабыз, укыган саен үсәбез, культурабыз үсә, эшкә, яшәргә дәртебез арта. Без дин белән көрәшүне туктатырга дигән фикергә килмибез. Көрәшергә кирәк. Органы булырга тиеш. Ул органның журналы, лекторлары эшләсеннәр. Ә безгә тормышка өндәүче матур әдәбият кирәк. Аны укыган саен укыйсы килә, укыган саен эшлисе килә.

«Казан утлары» әнә шундый көчле ут булсын ул.

Бер төркем журнал укучылары.
Казан.

# ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ ЯҢАЛЫКЛАРЫ

## УРТАК ШАГЫЙРЕБЕЗ — УРТАК БӘЙРӘМЕБЕЗ

Тукай — теге яки бу уңайда искә алына, ихтирам ителә торган язучы гына түгел, ә тарих белән, һәр яңа буын белән бергә алга атлаучы гражданин һәм көрәшче. Ул, социалистик революция аша безнең чорга күчеп, тормышның зур сынауларын бергә кичергән замандашыбыз. Ул хаклы рәвештә халык арасында яши һәм аның көр тавышы көн саен безгә ишетелеп тора...

Габдулла Тукайның тууына 80 ел тулуга багышланган бәйрәм көннәрендә республикабызның үзәк газеталары әнә шулай яздылар. Әйе, гражданин һәм көрәшче Тукай безнең якын дустыбыз һәм сердәшчебез, сөелеп укыла торган замандаш шагыйребез. Тик бер безнеке генә түгел, ул илебез территориясендә яшәүче барлык халыкларның уртак шагыйре, уртак горурлыгы.

Әле Бөек Октябрь революциясенә кадәр үк Идел буенда, Урта Азиядә һәм Кавказда яшәүче күп халыклар Тукай иҗатын үз итеп, яратып кабул иттеләр. XX йөз башы төрки әдәбиятларын заман, чор тудырган яңалык элементлары белән баетуда Тукай турыдан-туры һәм актив рәвештә катнашты. Көнбатыш Европа һәм классик рус әдәбияты ирешкән казанышларны Урта Азия, Кавказ халыклары безнең Тукай иҗаты аша үзләштерделәр. Соныннан, аның иҗатының бәрәкәтле йогынтысы тәэсирендә, ул әдәбиятларда Тукайны үзләренә остаз иткән күп кенә күренекле әдипләр күтәрелде.

Октябрь революциясеннән соң узган ярты гасыр вакыт эчендә Тукай иҗатына булган мәхәббәт кимемәде генә түгел, ә күп тапкырлар артты, аның иҗаты яңа географик киңлекләргә чыкты. Хәзер ул бөтен СССР халыкларының, прогрессив кешелек дөньясының яраткан шагыйрьләреннән санала. Аның исеме дөнья әдәбиятының иң күренекле вәкилләре белән янәшә куеп йөртелә.

Менә шуңа күрә дә сөекле шагыйребезнең 80 еллыгы гаять тантаналы шартларда зур итеп билгеләнеп үтелде. Республика газета-журналларында ел башыннан бирле Тукайга багышланган материаллар басылып килде, радио һәм телевидение күп санлы тапшырулар оештырды.

Үзәк газета-журналларның апрель һәм июнь айларында чыккан саннарында Тукайның тормыш юлы һәм иҗат мирасы хакында күп кенә кызыклы мәкаләләр басылды.

Казан, Мәскәү һәм тугандаш республикаларның китап нәшриятлары Тукай әсәрләренең юбилей басмаларын, бүгенге язучыларның һәм әдәбият галимнәренең татар халык шагыйре турындагы яңа китапларын чыгардылар.

Апрель, июнь айларында туган илебезнең бөтен почмакларында Габдулла Тукайның тууына 80 ел тулуга багышланган тантаналы кичәләр һәм митинглар, фәнни конференцияләр һәм җыелышлар уздырылды.

## МӘСКӘҮДӘ ТУКАЙ КӨННӘРЕ

Билгеле булганча, Габдулла Тукайның тууына 80 ел тулуга багышланган юбилей тантаналары июнь аена — Татарстан бәйрәменә калдырылган иде. Тантаналы кичәләр ватаныбыз башкаласы Мәскәүдә башланып китте. 21 июнь көнне Чайковский исемендәге Концерт залына тугандаш республикалардан килгән күренекле шагыйрьләр һәм әдәбият белгечләре, партия-совет оешмаларының җаваплы эшчеләре, шәһәр хезмәт ияләре җыйналды. Юбилей тантаналарына катнашу өчен, Мәскәүгә республикабызның күренекле сәнгать осталары, Культура министрлыгы вәкилләре, М. Әмир, Ә. Исхак, Х. Госман, М. Гайнуллин, Б. Гыйззәт, Ә. Маликов, М. Фәйзуллина һәм Р. Гатауллиннар составында язучылар делегациясе дә килгән иде.

Кичәне, Тукай иҗатының иҗтимагый әһәмияте турында кыскача кереш сүз белән, М. Горький исемендәге дөнья әдәбияты институты профессоры Л. Климович ачып җибәрде. КПССның Татарстан өлкә комитеты секретаре М. Вәлиев Габдулла Тукайның тормыш юлы һәм иҗат эшчәнлеге турында доклад ясады. Ә. Исхак, Р. Моран, С. Липкин, С. Муканов һәм башка чыгыш ясаучылар Тукайга багышлап шигырьләр укыдылар, аның иҗатының бөеклеге турында сөйләделәр. Соңыннан, Татарстан артистлары көче белән, зур бәйрәм концерты бирелде.

22 июньдә шундый ук бәйрәм кичәсе язучыларның Үзәк йортында татар телендә уздырылды.

Кичәне Татарстан язучылар союзы председателе Мирсәй Әмир ачты. Әхмәт Исхак бөек шагыйрьнең тормыш юлы һәм үлемсез әсәрләре турында сөйләде.

Сабит Муканов, Әхмәт Ерикәй, Әдип Маликов, Мәрзия Фәйзуллина, Рәдиф Га-

тауллин, Такен Алимкулов һәм башка язучылар үзләренең чыгышларын халыклар дуслыгы жырчысы Габдулла Тукайның якты истәлегенә багышладылар.

## КАЗАН КУНАКЛАР КАРШЫЛЫЙ

Тукай юбилеен билгеләп үтү өчен, республикабыз башкаласына ватаныбызның бөтен почмакларыннан, чит илләрдән бик күп кунаклар: күренекле язучылар, шагыйрьләр һәм тәрҗемәчеләр, әдәбият галимнәре һәм тәнкыйтьчеләр, үзәк нәшриятларның һәм газета-журналларның җаваплы хезмәткәрләре килде. Алар арасында күренекле казакъ әдибе, академик **Сабит Муканов**, күренекле үзбәк шагыйре, академик **Гафур Голәм**, РСФСР язучылар союзы секретаре **Франц Таурин**, Мәскәү шәһәрендә яшәүче гарәп язучысы **Сәхип Җамал**, Финляндия галиме **Гомәр Даһир**, танылган Мәскәү шагыйрьләре һәм тәржемәчеләре **Михаил Львов**, **Семен Липкин**, **Владимир Туркин**, **Виктор Харчев**, **Рувим Моран**, әдәбият белгече **Азиз Шәриф**, Башкортстан язучылар союзы председателе **Назар Нәҗми**, күренекле башкорт әдипләре **Сәйфи Кудаш** һәм **Сәгыйт Агиш**, Чувашстанның халык шагыйрьләре **Петр Хузангай** һәм **Яков Ухсай**, Мари АССРдан **Миклай Казаков**, удмурт шагыйре **Гай Сабитов** һәм башкалар бар иде.

Кунаклар Габдулла Тукайның тууына 80 ел тулуга багышланган юбилей тантаналарында, фәнни конференция утырышларында катнаштылар, шагыйрь исеме белән бәйләнгән урыннарда, Татарстан дәүләт музеенда оештырылган күргәзмәдә булдылар, Куйбышев мәйданындагы Тукай һәйкәленә, шагыйрьнең Яңа бистәдәге каберенә чәчәкләр, веноклар куйдылар, шәһәребезнең тарихи истәлекләре белән таныштылар, Дербышка поселогында сабан туе карадылар, Иделдә йөзделәр.

Юбилейга килгән кунакларга һәр җирдә зур кадер-хөрмәт күрсәтелде.

## ФӘННИ КОНФЕРЕНЦИЯЛӘР

Журналыбызның 6 санында СССР Фәннәр академиясенең Казан тел, әдәбият һәм тарих институтында Габдулла Тукайга багышланган фәнни конференция уздырылуы һәм ул конференциядә тыңланган докладлар турында без укучыларыбызга хәбәр иткән идек инде. Июнь аенда шундый тагын ике конференция үткәрелде.

22 июньдә Мәскәүдә В. И. Ленин исемендәге үзәк китапханәнең конференц-залында М. Горький исемендәге дөнья әдәбияты һәм СССР Фәннәр академиясе Казан тел, әдәбият һәм тарих институтларының берләштерелгән гыйльми советы булып узды. Анда Казан дәүләт университеты профессоры Х. Госманның «Татар поэзиясе тарихында Тукайның урыны», М. Горький исемендәге дөнья әдәбияты институты фәнни эшчесе А. Вәлитованың «Тукай гуманизмының чыганаклары», Казан тел, әдәбият һәм тарих институтының өлкән гыйльми эшчесе Г. Халитның «XX йөз башы татар әдәбиятында герой проблемасы» исемле докладлары тыңланды. Берләштерелгән гыйльми советта Л. Климович «Тукай дөньяга карашының кайбер мәсьәләләре», А. Шәриф «Тукай һәм Сабир», Т. Нуртазин «Тукай һәм казакъ әдәбияты», Н. Павлов «Тукай һәм Иванов» дигән темалар буенча хәбәрләр белән чыктылар.

СССР Фәннәр академиясенең Казан институтлары конференц-залында уздырылган фәнни конференция берничә көн дәвам итте.

Конференциягә Үзбәкстан, Әзербайҗан, Казагыстан Союздаш республикаларыннан, Башкортстан, Чувашия, Мари Автономияле республикаларыннан һәм Мәскәүдән күренекле әдәбият галимнәре, тәнкыйтьчеләр килде. Фәнни конференциядә СССР Фәннәр академиясенең Казан тел, әдәбият һәм тарих институты, Казан дәүләт университеты, Казан дәүләт педагогия институты галимнәре катнашты.

Халкыбызның бөек шагыйре Габдулла Тукайның тууына 80 ел тулуга багышланган фәнни конференциядә барысы 20 дән артык доклад һәм хәбәрләр тыңланды. **Р. И. Нафиговның** (Казан дәүләт университеты) «Габдулла Тукайның иҗтимагый-политик карашлары», **С. Сафуановның** (Уфа тел, әдәбият һәм тарих институты) «Габдулла Тукай һәм башкорт әдәбияты», **И. Сәгыйтовның** (Үзбәкстан ССР Фәннәр академиясенең Каракалпак филиалы) «Татар һәм каракалпак культура бәйләнешләре өлкәсендә Тукайның роле», **Е. Владимировның** (Чуваш педагогия институты) «Габдулла Тукай һәм революциягә кадәрге чуваш шагыйрьләренең типологик бәйләнешләре мәсьәләсенә карата», **Л. Каюмовның** (Ташкент дәүләт университеты) «Габдулла Тукай һәм үзбәк поэзиясе», **Ф. Хатиповның** (Башкорт дәүләт университеты) «Габдулла Тукай сатирасының фәлсәфи нигезләре», **А. Мирахмедовның** (Әдәбият һәм тел институты, Баку) «Габдулла Тукай — «Мулла Насретдин» журналының фикердәше», **И. Нуруллинның** (Казан дәүләт университеты) «Татар әдәбиятында мәгърифәтчелек мәсьәләсенә карата», **Р. Башкуровның** (СССР Фәннәр академиясенең Казан тел, әдәбият һәм тарих институты) «Хәзерге татар поэзиясендә Тукай традицияләре», **Г. Хөсәеновның** (СССР Фәннәр академиясенең Уфа тел, әдәбият һәм тарих институты) «Габдулла Тукай традицияләре һәм Сәйфи Кудаш иҗаты», **И. Надировның** (СССР Фәннәр академиясенең Казан тел, әдәбият һәм тарих институты) «Габдулла Тукай һәм халык җырлары» исемле докладлары катнашучыларда аеруча зур кызыксыну уятты.

## БӘЙРӘМ БҮГЕН

25 июнь көнне шәһәребез хезмәт ияләре, республиканың һәм киң илебезнең бөтен районнарыннан килгән кунаклар Муса Җәлил исемендәге татар дәүләт опера һәм балет театрына — Габдулла Тукайның тууына 80 ел тулуга багышланган тантаналы юбилей кичәсенә җыелдылар. Сәхнәдә сөекле шагыйребезнең чәчәкләр белән бизәлгән зур портреты. Президиумда тугандаш республикалардан һәм күрше өлкәләрдән шушы тантанага килгән кунакларыбыз, күренекле татар язучылары, пар-

тия-совет оешмаларының җаваплы эшчеләре, хезмәт алдынгылары... Тантананы КПССның Татарстан өлкә комитеты секретаре иптәш М. Вәлиев ача. Ул Казан хезмәт ияләрен бүгенге тантанага килгән кунаклар белән таныштыра, кунакларга Татарстан халкының кайнар сәламен тапшыра.

Күренекле шагыйребез, Тукай премиясе лауреаты Сибгат Хәким татар халык шагыйренең бай иҗат мирасы, аның иҗатының чыганаклары, Тукай поэзиясенең татар совет шагыйрьләренә булган бәрәкәтле йогынтысы турында сөйләде. Тантаналы җыелышта чыгыш ясаган иптәшләрдән күренекле казакъ әдибе, академик Сабит Муканов, күренекле үзбәк шагыйре, академик Гафур Гolәм, РСФСР язучылары союзы секретаре Франц Таурин, күренекле башкорт язучысы Сәгыйт Агиш, күренекле татар шагыйре, Тукай премиясе лауреаты Хәсән Туфан, Мәскәү шагыйре Семен Липкин Габдулла Тукай иҗаты, татар әдәбияты хакында күп җылы сүзләр, изге теләкләр әйттеләр.

Тантаналы кичәнең икенче бүлегендә Татарстан сәнгать осталары көче белән зур концерт бирелде. Концертта Габдулла Тукай әсәрләре һәм аңа багышланган әсәрләр башкарылды.

## БЕР АВЫЛ — КЫРЛАЙ, ДИЛӘР

26 июнь көнне бәйрәм тантаналары безгә бөек Тукайны биргән Казан артында — Кырлайда дәвам итте. Юбилейга килгән кунакларның күбесенең бу якларда әле беренче тапкыр булулары. Шуңа да карамастан, Кырлай һәркемгә күптән, бала чактан бирле таныш урын кебек тоелды. Хәер, моңа әллә ни гаҗәпләнерлек тә түгел: һәркем Тукайның гүзәл Казан артын мәңгеләштергән әкият-поэмаларын, шигырьләрен укыган, хыялында гына булса да, булачак шагыйрь ялан тәпи йөргән Кырлай урамнарын, Кырлай урманнарын буйлаган.

Кырлайлылар, Арча районы хезмәт ияләре киң илебезнең төрле почмакларыннан килгән кадерле кунакларны ипи-тоз, якты йөз белән каршыладылар. Ачык һавада, Тукай һәйкәле янында зур митинг булды. КПССның Арча райкомы секретаре Х. Зәйнуллин Тукай юбилеена килгән кунакларга район хезмәт ияләренең кайнар сәламен тапшырды. Митингта Тукай иҗатының бөеклеге, дөньякүләм әһәмияте турында речьләр белән С. Муканов, Г. Голәм, М. Львов, Н. Нәҗми, Я. Ухсай, А. Шәрифләр чыкты. Алар әдәбият дөньясына Тукай кебек шагыйрьне биргән татар халкына тирән мәхәббәт хисләрен белдерделәр. Арча районы үзешчәннәре көче белән куелган концертта Тукай шигырьләре, аның сүзләренә язылган музыкаль әсәрләр яңгырады.

Митинг һәм концерттан соң, кунаклар, Кырлай китапханәсенә кереп, андагы Тукай музее белән таныштылар, истәлек язулары калдырдылар. Ахырдан Тукай йөргән эзләр буйлап уздылар, мәшһүр Кырлай урманында булдылар. Кырлайдагы тантана чын мәгънәсендә халык бәйрәменә әйләнде.

## ШАГЫЙРЬЛӘРГӘ ҺӘМ НӘШРИЯТ ХЕЗМӘТКӘРЛӘРЕНӘ — МАКТАУ ГРАМОТАЛАРЫ

Татар халык шагыйре Габдулла Тукайның иҗат мирасын пропагандалауда күрсәткән хезмәтләре өчен, Татарстан АССР Верховный Советы Президиумы тугандаш халыкларның күренекле әдипләрен һәм нәшрият хезмәткәрләрен Татарстан АССР Верховный Советы Президиумының Мактау грамоталары белән бүләкләде. Бүләкләнүчеләр арасында юбилейга килгән кунакларыбыз **Сабит Муканов, Гафур Голәм, Петр Хузангай, Сәйфи Кудаш**, СССР язучылар союзы консультанты **Хава Хөсәенова**, Мәскәүдәге «Детская литература» нәшриятының СССР халыклары әдәбияты редакциясе мөдире **Галия Кәримова** һәм күренекле казакъ шагыйре **Җакан Сыздыков**, кыргыз шагыйре **Камчы Юнысов**, Максим Горький исемендәге дөнья әдәбияты институтының гыйльми эшчесе, профессор **Люциан Климовичлар** бар.

## ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫНЫҢ ӘЛМӘТ БҮЛЕГЕНДӘ

Май аенда Әлмәт нефть районнарында яшәүче язучылар һәм сәнгать осталары җыелышы үткәрелде.

Җыелышта КПССның Әлмәт шәһәр комитеты беренче секретаре, XXIII съезд делегаты В. В. Ермаков әдәбият алдына партия куйган бурычларга тукталды, съездда алган тәэсирләре турында сөйләде. Фикер алышуларда язучылардан Г. Ахунов, Ә. Маликов, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, Әлмәт театрының баш режиссеры Габдулла Юсупов КПССның Әлмәт шәһәр комитеты секретаре Сания Хәкимова һәм башкалар катнашты.

* * *

7 майда Әлмәтнең 16 нчы мәктәбендә ата-аналар һәм өлкән класс укучылары өчен әдәби-музыкаль кичә үткәрелде. Кичәдә язучылардан Г. Афзал, Ә. Маликов, С. Сөләйманова, Г. Ахунов үзләренең яңа әсәрләрен укыдылар. Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Габдулла ага Юсупов патриот шагыйрь Муса Җәлил турында истәлекләр сөйләде.

Әлмәт татар дәүләт театры артистлары Т. Кичүбаев, Г. Кичүбаева, Л. Солтанова һәм башкалар татар шагыйрьләренең әсәрләрен, алар сүзләренә язылган җырларны башкардылар.

* * *

Бүлекнең 11 майда үткәрелгән чираттагы утырышы Саҗидә Сөләймановаының «Казан утлары» журналында басылган «Язылмаган җырлар» поэмасын һәм «Азат хатын» журналында басылган «Уйлар-юллар» исемле шигырьләр циклын тикшерүгә багышланды. Чыгыш ясаучылардан Г. Афзал, Г. Ахунов, С. Кальметов һәм башкалар Саҗидә Сөләйманова әсәрләренең уңышлы һәм кимчелекле якларын күрсәттеләр.

# Алдагы саннарда:

**Х. Сарьян. Эткәм һөнәре. Повесть. Ахыры.**

**С. Рафиков. Кояшлы иртә. Романнан өзек.**

**Г. Таҗетдинов. Үлемнән яшәүгә. (Дахау лагеренда). Документаль повесть.**

**Ш. Хөсәенов. Зөбәйдә — адәм баласы. Комедия.**

**Хикәяләр.**

**Г. Хуҗи, Ш. Галиев, З. Нури, Р. Гатауллин, Б. Сөләйманов, Б. Хәлимов шигырьләре.**

**Ленинград шагыйрьләре — бездә кунакта.**

**Ш. Руставелиның тууына 800 ел.**

**Г. Сабитов, Ш. Максудова, И. Надиров очерклары.**

**Ф. Мусин. А. Расихның иҗат портреты.**

**Әдәби тәнкыйть мәкаләләре.**

**Рецензияләр.**

**Җырлар.**

**Хатлар.**

Җаваплы редакторы **Рафаэль Мостафин**

Редколлегия: **Хәй Вахит, Ибраһим Гази, Әмирхан Еники, Гази Кашшаф, Шәйхи Маннур, Габдрахман Минский, Сибгат Хәким, Нил Юзиев**

Производствога бирелде 16/VI-1966 ел. Басарга кул куелды 22/VII-1966 ел. ПФ 15036. Кәгазь форматы 70×108¹/₁₆. Учетн.-изд. табак 12,2. Басма табак 10(14). Тираж 35.000 экз. Заказ Н-861.
Бәясе 40 тиен.

ТАССР Министрлар Советы каршындагы Матбугат идарәсенең Камил Якуб исемендәге матбугат комбинатында басылды. Казан, Бауман урамы, йорт 19, 1966 ел.

Бәясе 40 тиен
Цена 40 коп.

Индекс
73210

*Ежемесячный литературно-художественный*
*и общественно-политический журнал*

**КАЗАН УТЛАРЫ**

*(Огни Казани)*
ОРГАН СОЮЗА ПИСАТЕЛЕЙ ТАТАРИИ